**Энҗе чәчтем — энҗе җыям**
**Ай колакланса, ни булыр?**

# Халык афоризмнары

• Беренче китап •

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 398
ББК 82.3 (2Рос=Тат)-6
А 11

Редколлегия:

*К. М. Миңнуллин* (сериянең баш редакторы),
*Җ. Х. Кәлимуллин*, *Ф. И. Урманче*

Төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы

*Х. Ш. Мәхмүтов*

Рәссамы *Л. С. Золондинова*

ISBN 5-7761-0829-4
© «Мәгариф» нәшрияты, 2002

## КЕРЕШ

*Татар халык афоризмнары дигәндә фольклорның кечкенә күләмле жанрлары күздә тотыла. Аларга тирән һәм үткен фикерне җыйнак, сурәтле итеп әйтеп бирү хас. Шуңа күрә дә мондый әсәрләрне еш кына* ***хикмәт энҗеләре***, ***алтын бөртекләр***, ***фикер җәүһәрләре*** *кебек шигъри исемнәр белән атап йөртәләр.*

*Татар халкының афористик иҗаты үзенең жанрлар составы ягыннан шактый бай һәм күптөрле. Аларның безгә иң яхшы танышлары —* ***мәкальләр*** *һәм* ***табышмаклар****. Әмма болардан тыш әле тагын* ***канатлы сүзләр, әйтемнәр, җор сүзләр, юраулар (ышанулар), сынамышлар, алкышлар, каргышлар, антлар, әзер җаваплар, үртәвечләр, тизәйткечләр*** *дип йөртелә торганнары да бар. Мондый әсәрләр бигрәк тә үзләренең тышкы төзелешләре (кыскалыклары, сурәтлелекләре, ритмлы һәм рифмалы булулары) белән бер-берләренә шактый якын торалар. Әмма шул ук вакытта аларның һәркайсының үзенә генә хас булган сыйфат-билгеләре дә күзәтелә. Әйтик, мәкаль тормыштагы фактларга һәм вакыйгаларга бәя бирә, төрле-төрле хәлләрдә үзеңне ничек тотарга өйрәтә. Табышмак кешенең тапкырлыгын, зирәклеген, фикерләү сәләтен үстерүгә ярдәм итә, бер үк вакытта күмәкләшеп күңел ачу чарасы да булып тора. Алкышлар, антлар, каргышлар магия-тылсым белән бәйләнгәннәр. Юраулар һәм сынамышларга киләчәккә прогноз ясау роле йөкләнгән. Җор сүзләр, әзер җаваплар, үртәвечләр күбрәк кешеләрне көлдерү максатын алга сөрәләр, сөйләмне бизиләр, аны җанландыралар.*

*Без кайбер афористик жанрларның төп вазифаларын күрсәтеп үттек. Әлбәттә, аларның башка өстәмә вазифалары да бар. Мәсәлән, шул ук мәкальгә, бәяләү, өйрәтүдән тыш, күрәзәлек кылу, магиячелек тә, сөйләмне бизәү, күркәмләү дә чит түгел...*

*Татар фольклорындагы афористик жанрлар һәм аларның вазифалары турындагы күзәтүләрне кыскача түбәндәге таблицада күрергә мөмкин. Һәр жанрның төп вазифасы «+», өстәмә вазифалары «•» билгесе белән күрсәтелә.*

*Таблицада татар халык афоризмнарының байлыгы һәм төрлелеге бик ачык чагыла. Шуңа күрә дә*

*«Энҗе чәчтем — энҗе җыям» сериясендә аларга ике китап багышлау кирәк дип табылды. Бу беренче китапта алкышлар, каргышлар, антлар, әзер җаваплар, юрау-ышанулар, сынамышлар, табышмакларның иң яхшы үрнәкләре урын алды, санап үтелгән жанрларның һәркайсы турында кыскача мәгълүмат бирелде.*

# Сөйгәнгә — алкыш, сөймәгәнгә — каргыш

Халык афоризмнарының бер ишләре тормышта турыдан-туры магик вазифа башкара. Аларда сүзнең тылсым көче ярдәмендә табигатьтәге «ияләргә», төрле чирләргә, дус яки дошманга тәэсир итү, яхшылыкка каршы изгелек кылу, явыз затларның зыян-зарәтеннән котылу кебек максатлар алга сөрелә. Шундый жанрларның берсе — **алкышлар**, ягъни изге теләкләр. Алар кеше тормышында әһәмиятле вакыйгалар булганда, шатлык-куаныч килгәндә, уңышка ирешкәндә һәм башка шундый очракларда хуплау, теләктәшлек белдерү йөзеннән әйтеләләр. Әйтик, берәр кеше өстендә яңа кием күргәндә: «*Җылы тәнеңдә тузсын!*» — диләр. Берәр төрле эш башкаручылар яныннан: «*Алла куәт бирсен!*» — дип узалар. Юлга чыгучыларны: «*Йөргән аягың савапка бетсен!*» яки «*Юлың ак сөттәй булсын!*» кебек сүзләр белән озатып калалар.

Алкышларга капма-каршы булган **каргышлар** — дошман тарафка адресланган яман теләкләр. Алар шулай ук каршы якның каргышын үзенә кайтару өчен дә хезмәт итәләр. Әйтик, берәү икенче кешене: «*Бәхетеңне йотсаң иде!*» — дип каргый, тегесе «*Каргышың казык башына*!»— ди. Борынгы кешеләр, алда әйтелгәнчә, мондый теләкләрнең көченә, нәтиҗәсенә чын-чынлап ышанганнар. «*Алкыш алган — аман**, *каргыш алган — тәмам*» кебек гыйбарәләр әнә шуны раслый.

«Алкыш» һәм «каргыш» атамалары төрки телләрдә бик күптәннән кулланылып киләләр: Йосыф Баласагунлы үзенең «Котадгу белек» («Бәхетле булу белеме») исемле поэмасында (1069—1070) болай язган:

Киши эдгү атын көр алкыш булур,
Атыкмыш эсиз өлсә каргыш булур.

Ягъни изге исеме аркасында кеше алкыш ала, яман аты чыккан кеше каргыш ала.

Борынгы кульязмаларда алкыш-каргышларның аерым үрнәкләре дә теркәлеп калган: «*Агылыңта йылкың болсун*!» (Абзарыңда терлегең булсын!), «*Тәңри каргышы аның үзә*!» (Аңа Тәңре каргышы төшсен!) һ. б.

Магик вазифа башкара торган афоризмнарның тагын бер төре — **антлар**. Болары,— бер яктан, үзеңнең хаклыгыңны, гаепсезлегеңне раслау, икенче яктан, бирә торган вәгъдәңнең ныклыгына, бозылмаслыгына ышандыру өчен әйтелә торган гыйбарәләр. Әгәр ант итүченең сүзе ялган булып чыкса, аның башына коточкыч җәза-газаплар төшәргә тиеш була: «*Ике күзем чәчрәп чыксын*!», «*Җир йотсын*!» һ. б. Ант текстлары каргышларга бик якын тора: төп аерма шунда — алар кешенең үз исеменнән, беренче заттан биреләләр, һәм җәза да ант итүченең үзенә адреслана. Мәсәлән, «*Кулы корысын*!» яки «*Кулың корысын*!» — каргышлар, «*Кулым корысын*!» — ант.

Антлар —шулай ук бик борынгы жанр. Әле моннан 1200—1300 еллар элек язылган ядкярләрдә «*Ант антыкмышы талуй эгүздә теринрәк ол*» (Ант итү елга-диңгезләрдән тирәнрәк ул) кебек гый-барәләр очрый. Ягъни ант бирү — шулкадәр авыр һәм катлаулы бурыч. Шуңа күрә дә ант иткәндә, Кояшны, Тәңрене, Икмәкне, Тимерне һ. б. изге нәрсәләрне шаһитлыкка чакырганнар. Төрле магик хәрәкәтләр башкарганнар. Мәсәлән, кылычны ант итүче каршына аркылы куеп антыңны бозсаң, «*бу күк керсен, кызыл чыксын*» ди торган булганнар. Мондый сүзләр «тимер сине үтерсен, кызыл каныңны чыгарсын» дигәнне аңлаталар.

Ант итүне икенче төрле «**ант эчү**» дип әйтү дә бар. Мондагы «эчү» сүзе элек туры мәгънәсендә кулланылган. Үзара ант, вәгъдә алмашучылар, бармакларын кисеп, кымызлы касәгә каннарын тамызганнар да шуны эчеп куя торган булганнар. Шуннан соң ант үтәлеше мәҗбүри канун хөкеменә кергән.

Бүгенге җәмгыятьтә ант борынгыдагыча мөһим роль уйнамый, без аңа күбрәк гадәт буенча гына мөрәҗәгать итәбез. Ләкин урынлы-урынсыз ант итеп, аның ныклыгы, катгыйлыгы турында уйламау һич тә хуплана алмый. «*Ант — акыллыга каты, җүләргә — уен*»,— ди халык. Мондый бәя хәзер дә көчендә кала.

Бу бүлектә сезнең игътибарыгызга изге теләкләр, яман теләкләр һәм антларның кайбер үрнәкләре тәкъдим ителә.

**ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР**

Авызыңа бал да май, артыңа колын тай.
Авызыңа баллы җау*.
Авызыңа каз мае.
Авыр туфрагы җиңел булсын.
Авырлыгым шунда калсын.
Авырлыкка — җиңеллек.
Аз булса да, күп итеп ал.
Ай йөре дә сау йөре.
Ай рәхмәт төшкере, кулыңа гөлләр үскере.
Айга — айлык, миңа — саулык.
Акылыңнан куан.
Алгы итәгеңне бала бассын, арткы итәгеңне мал бассын*.
Алды-арты хәерле булсын.
Алла әҗерен бирсен.
Алла куәт бирсен, җаныңа саулык бирсен.
Алла рәхмәтеңдә булсын.
Алла сакласын, кара елан чакмасын.
Алла ярдәм бирсен.
Алладан кайтсын.
Алланың бар иткере.
Армый эшләгез! — Сары май тешләгез!*
Арты килүле булсын!
Ару үлем, ак кәфен!
Аруга тару бул!*
Атын мин куштым, яшен Алла бирсен*.
Ахыры хәерле булсын.
Аш булсын.
Ашың-чәең тәмле булсын.
Аягың җиңел булсын.
Аяк-кулың сызлаусыз булсын, күңелең сырхаусыз булсын.
Аяклары төкле* булсын.
Әй уңгыры, бер башың мең булгыры*.
Әйткәнең фәрештәнең «амин» дигәненә туры килсен.
Әрвахлар рухы шат булсын.
Бай, бәхетле бул.
Бай булгыры!
Балдан рәхим итегез, майдан авыз итегез, дөньяда балдай татлы, майдай тук булып гомер итегез*.
Башыңа дәүләт яусын.
Бәйрәм мөбарәк булсын, мәҗлес түгәрәк булсын!
Бәйрәмнәр котлы булсын, тормышлар хутлы булсын.
Бер кулың — майда, бер кулың балда булсын.
Бер урынына ун булсын, эшләрең гел уң булсын.
Бәла-казаларыннан сакласын.
Бәрәкәт яусын.
Бәхете аягына чолганса иде*.
Бәхетенә тәүфыйгы булсын.
Бәхетең алдыңа сайрап кунсын.
Бәхетең яр булсын.
Бездән кайтмаса, Ходайдан кайтсын.
Гаип* хәзинәләреннән бирсен.
Гомерләре озын булсын, бала-чагалары мул булсын, абзар тулы мал, авызлары май да бал булсын.
Гомереңә бәрәкәт бирсен.
Гүрең якты булсын.
Гыйшыклары кайнар булсын, гомерләре матур узсын.
Дәүләт кошы башыңа кунсын.
Дәүләт өстенә дәүләт яусын.
Дәүләтең артсын.
Дәүләтең белән картай.

Дәүләтең ташсын, башыңнан ашсын, михнәтең качсын.
Дөньяларың тигез булсын, балаларың игез булсын.
Елларга иминлек бирсен.
Җылы тәнеңдә тузсын.
Игелек күр!
Игенгә бәрәкәт, җанга саулык.
Игенегез уңсае, минем буе булсае.
Изге җаннардан булсын.
Изге сәгатьтә!
Ил ашасын, йөз яшәсен.
Исән йөреп, сау кайт.
Исәнлеккә-саулыкка, тазалыкка-байлыкка.
Йөз яшә, йөзем аша.
Йөзең ак булсын.
Йөргән аягың савапка бетсен.
Йөргәнеңдә юлың уң булсын, Хозыр ата* юлдашың булсын.
Картлыкта рәхәтлеген бирсен.
Керер юлларын киң итсен.
Киемең тузсын, үзең үс; киемең — чүплек башына, үзең — кияү куенына.
Кимәгәнне киеп булыр, кигәне өстеңнән төшмәсен.
Килен килбәтле булсын, сүзе ширбәтле булсын.
Кияве — сиңа, бүләге — миңа.
Котлы аягың белән!
Котлы булсын!
Кул артың җиңел булсын.
Кулың-аягың сызлаусыз булсын.
Кулыңнан кинән.
Күргәнгә күркәм сабырлык бирсен, күрмәгәнгә күрсәтмәсен.
Малыма килсә килсен, башыма килмәсен.
Малыңның игелеген күр.
Маңгаең йолдызлы булсын, бүркең кондызлы булсын.
Мәзәгегез* түгәрәк булсын.
Мине сөендергән өчен Ходай сине сөендерсен.
Морадыңа ireш!
Мөбарәк булсын!
Насыйп кылсын!
Нахагыннан, хагыннан Ходай сакласын.
Өйләнүең уң булсын, башы-ахыры шул булсын.
Өстәүле мал булсын.
Өстеңдә тузсын.
Рәхмәт төшкере, дәүләт иңгере.
Рәхмәт яугыры!
Сигез оҗмахның ишеге сиңа ачык булсын, теләгән оҗмахыңа кер.
Сиңа Ходай өмет итмәгән җирдән бирсен.
Сиңа — юл котлыгы, миңа — өй котлыгы.
Соң булса да уң булсын.
Суы сарыксын, үзе калыксын*.
Тагы йөз ел тор.
Тамгаң ай булсын, нәселең бай булсын.
Тансыгына кансын*.
Тапканың таш булсын*, тамагыңа аш булсын.
Ташкаябышсаң көмеш булсын, туфракка ябышсаң алтын булсын.
Тәңре ярдәм итсен.
Тел төбеңә сары май.
Тигез гомер итегез.
Тиңе белән булсын.
Төкле аягың белән.
Туйлар мөбарәк булсын, яшьләр башына бәхет кунсын, өйләре бала белән тулсын.
Туйлары котлы булсын, нигезләре ныклы булсын.
Түбәсенә туклык, тамырына ныклык*.

Түшәге-ястыгы йомшак булсын, кич ятканда кабарып торсын.
Тыныч йокы, татлы төш!
Узгынчы авыру булсын.
Улыңның, кызыңның игелеген күр.
Урыны җәннәттә булсын.
Утның күңеле көр булсын.*
Фәрештә колагына төш булсын*.
Фәрештәнең «амин» дигән сәгатенә туры килсен.
Хәере белән булсын.
Хәерле бәрәкәт бирсен.
Хәерле каза булсын, калганы таза булсын.
Хәерле сәгатьтә!
Хәерле сәфәрләр бирсен.
Хәерле төн!
Хәерле юл!
Хәтерең бар булсын.
Ходай ак тормышлар бирсен.
Ходай сиңа җиде оҗмахның түрен бирсен.
Ходай тел ачкычлары бирсен.
Ходай язмасын! — Язса да бозсын.
Эшкә уңлык! — Җаныңа саулык.
Эшләрегез уң булсын. — Уңышлар бергә-бергә булсын.
Юлларыңа ак җәймә.
Юлы ак, гомере озын булсын.
Юлың ак сөттәй булсын.
Юньле-юсыклы* кеше булсын.
Яткан җирең мамык булсын.

## ЯМАН ТЕЛӘКЛӘР

Авызың белән әйт, борының белән тарт*.
Авызыңа таш  тыгылсын.
Авызыңнан җил алсын, илтеп куеныңа салсын.
Актык көнең булгыры.
Алганың эчеңне тишеп чыксын.
Алдаганның анасы үлсен.
Алла каберен якын итмәсен.
Алла кашында тоткын булсын.
Алланың каты каһәре суккыры.
Алланың каһәре төшсен.
Алланың ләгънәтләре яусын.
Алтмыш өйле Көтернәс алты өйгә калса иде*.
Антың башыңа җитсен.
Арпаң-көрпәң аш булсын, тамагыңа таш булсын.
Атавыңа чыксын*.
Атаңа ләгънәт — авызыңа таш.
Аты коргыры.
Ахирәттә алдыңда булсын.
Ахирәттә ике кулым якаңда булсын.
Ач-ялангач йөрмә, ир рәхәте күрмә.
Ашаганың аш булсын, тамагыңа таш булсын.
Ашаткан ашларым, иткән яхшылыкларым тотсын.
Аягыңны бәддога сугып, ике тубыгың тиң корышсын.
Әфсен-төфсен, башың бетсен.
Башы түбән дөмеккере.
Башы йөзтүбән килгере.
Бәддога төшкере.
Бәхетеңне йотсаң иде.
Безне бутаганның эче-бавыры буталсын.

Бerең ике булмасын, йортың-караң калмасын.
Бирәне сапкыры.
Бугазы ертылгыры.
Бугазына аркылы килсен.
Бугазына пычак кергере.
Бугазыңа таш булып утырсын.
Гомерең кыска булгыры.
Гүрдән гүргә сикерсен.
Гүрендә дуңгызы үкерсен.
Дөмегеп кат.
Дөнья йөзе хәрам булсын.
Зәхмәт кагылгыры.
Җаның җәһәннәмгә олаккыры.
Җәзасын тартсын.
Җен алгыры.
Җир тотсын аны.
Җирдә кортларга азык булып яткыры.
Җиттем дигәч җимерел, куандым дигәч куырыл.
Җылы авызыңнан җылы куеныңа.
Җылы тамагыңа кара таш.
Игелек йөзен күрмә.
Ике күзе тиң чыксын.
Ике күзең чәчрәп чыксын.
Йөзе аска килгере.
Йөзең йөзтүбән килсен.
Йөзең кара булгыры.
Кадалып киткере.
Каргышың карга башына.
Каргышыңа — каргышым.
Каһәр суккыры.
Котырган этләр ялагыры.
Кулы корышсын.
Кулы череп аккыры.
Кулың авызыңа җитми утыргыры.
Кырык чөе* кырылып бетсен.
Күз яшем тотсын.
Күзе тишелеп чыккыры.
Күзең күмер булсын.
Күмәч төсен күрмәгәре*.
Күргәнең-күрмәгәнең шул булсын.
Күрми күмер булсын.
Ләгънәт кенә сукса иде.
Миең чергере.
Миннән алсын, сиңа бирсен.
Муеннары сынгыры.
Муеның астына килеп, кәкрәеп катсаң иде.
Мур* кыргыры.
Нәләт төшкере.
Өмете киселгере.
Өне тыгылгыры.
Пычак кергере.
Сәгатьлек әҗәл тигере.
Такта чәй орсын*.
Тамагыңа сөяк булып кадалсын.
Тамагыңа таш кергере.
Тамагыңа тимрәү калкып, телеңә төер чыккыры.
Тартышып ят.
Тары кебек чәчелеп кит.
Тәгәрәп җан биргере.
Тәгәрәп үчкере.

Телең корышып, өзелеп төшкере.
Телең чергере.
Телеңә тилчә төшсен.
Телеңә чуан чыккыры.
Тиреңне курага* җәйсеннәр.
Токымың коргыры.
Торараташ булып катсын.
Урты шартлагыры.
Урынын җиде кат җәһәннәмдә кылсын.
Утырыр җиреңне ут алсын.
Уты-суы бер көн булсын.
Үз кадагыңа кадал.
Үз каргышың үзеңә.
Үзе дә бала күрмәсен*.
Үләт ялагыры.
Хатын казасын күр.
Чыңрак* үтә кит.
Чәнчелеп киткере.
Шайтан алсын.
Шайтаныма олаксын.
Эчең чыккыры.
Эчеңә бирән ояласын.
Эчеңә пычак кергере.
Эчеңә таш булып утырсын.
Эчеңне тырнасын.
Ялгызлыкта җаның чыксын.
Яшен бирсә дә, көнен бирмәсен.
Яшем төшсен.
Яшь башыңа куанма.
Яшьлеген яшен суксын.

**АНТЛАР**

Айдыр әгәр.
Анамның имезгән сөте хәрам булсын.
Ант орсын.
Әби-бабаңа, ата-анаңа, җиде буын балаңа зыян салсам, кулым корысын.
Баскан җиремнән китәлмим.
Валлаһи газим.
Дөньядан сәгатьсез китим*.
Дөньялардан имансызлар үтим.
Җаным кабыргама килсен.
Ике иңем, бер түбәм.
Ике күзем кояшны күрмәсен.
Ике күзем чәчрәп чыксын.
Икмәгем орсын.
Икмәк өстендә әйтәм.
Икмәк чыраен күрмим.
Икмәкнең бөртеген күрергә мохтаҗ булыйм.
Икмәктер газим.
Иманым көфер китсен.
Иманымнан җөда булыйм*.
Ипи йөзен күрмәскә риза.
Ипи орып үтерсен.
Кадалыплар китим.
Кара тәүбә, ак тәүбә.
Кашык каным калганга кадәр.
Коръән алып ант итәм.
Коръән орсын.
Кояш йөзен күрмим.

Кулымны кисәргә бирәм.
Күзләрем маңгаемда булмасын.
Кызарып чыккан кояштыр.
Менә ак сакалым.
Менә табын өстендә әйтәм.
Менә тырнак очым.
Сары май тамагыма торсын.
Сыртым көйсен.
Тамагыма таш булып кадалсын.
Телем корысын.
Тораташ булып катыйм.
Төкер битемә, сүзем чын булмаса.
Утырган урынымнан тормыйм.
Чукынып китим.
Шартлап китим.
Шатлык йөзен күрмим.
Шушы урында җир упсын.
Шушы якты дөньяны күзем күрмәсен.

II БҮЛЕК

# Юраганың юш булсын, курыкканың буш булсын

Кеше һәрвакыт киләчәккә күз төбәп яши, алда үзенниләр көтүе турында уйлана, шушы хакта төрле фаразлар кора. Халык иҗатындагы афористик жанрларның кайберләре нәкъ менә шундый максатка хезмәт итәләр. Алар арасында **юраулар** аеруча үзенчәлекле урын алып тора. Теге яки бу рәвешчә юрау өчен, башлыча халыкның бик борынгы ышанулары, хорафатлары нигез булып торганга күрә, жанрны тагын **ышанулар** дип атау да бар. Ләкин аңа артык киң гомумиләштерү хас. Шуңа күрә дә **юраулар (ышанулар)** яки **юрау-ышану** рәвешендәге кушма исем куллану жанрның асылына күбрәк туры килә шикелле.

Юрау-ышануларда ясала торган прогноз иҗтимагый тормыш хәлләренә, хуҗалык итүгә, гаилә-көнкүрешкә, кешенең тән тереклегенә һ. б. өлкәләргә җаелә. Прогноз ясау өчен җирлек булып, әйткәнебезчә, элеккеге гореф-гадәтләр, йола-ритуаллар хезмәт итә. Мәсәлән, «*Көтү килгәндә алдан кызыл сыер килсә — көн кояшлы булыр, әгәр дә кара сыер килсә — көн болытлы булыр*» дип юраганнар. Аның тамырлары бик еракка барып тоташкан. Әүвәлге заманнарда яңгыр теләгәндә, корбанга — кара сыер, аяз теләгәндә кызыл сыер чалганнар. Монда «охшаш охшашны тудыра» дигән гомеопатик тылсым принцибы кулланылган: кара сыер — кара болытны, кызыл сыер кызыл кояшны чакыра, дип уйлаганнар.

Әлбәттә, жанрга бәя биргәндә, без аңа хорафат, кара ышану дип түбәнсетеп карарга тиеш түгелбез. Чөнки юраулар да — халык күңеленең көзгесе, аның уй-теләкләрен, хыял-өметләрен, шатлык-куанычларын гәүдәләндергән әсәрләр. Гади генә тормыш күренешләреннән дә халык нинди дә булса яхшылык галәмәте табарга тырышкан. Әйтик, берничә кеше үзара сөйләшеп утырганда, арадан берсе: «*Ай битем кычыта»,—* дип куйды, ди. Шундагы икенче берәү бу сүзләргә җавап йөзеннән: «*Битең кычытса, сине сагыналар икән»,—* дип, аның күңелен күтәреп, дәртен почмакландырып җибәрә. Мондый характердагы юрау-ышанулар, күркәм бер гадәт сыйфатында, хәзерге көндә дә телебездә актив кулланылышта.

Татар халкының әхлакый йөзе, рухи байлыгы турында сүз барганда, аның кунакчыллык сыйфаты бик еш мактап телгә алына. Бу тема юрауларда да киң чагылыш тапкан. Көнкүрештә очрап торган әллә нихәтле билгеләрне халык кунак киләсенә юрый, шуларга карап кунак көтү куанычын кичерә: «*Мәче битен юса, кунак килә*», «*Ак таракан төшсә, кунак киләсенә*», «*Самавыр озак кайнаса, кунак килгәнен көтә*» һ. б.

Сүз дә юк, ышанулар киләчәкне юраганда барысын да ал да гөл итеп кенә күрсәтмиләр. Алар арасында нииндидер куркыныч, хәвеф-хәтәр, кайгы-хәсрәт килү ихтималын искәртә торганнары да байтак. Мәсәлән, «*Йортта эт җир казыса — мәет, чикерткә сызгырса — янгын*» дип шомлану бар. Мондыйларга сукырларча ышану кешене хафага, өметсезлеккә төшерергә, хәтта аның тормышын фаҗигагә дә алып барырга мөмкин. Бүгенге күзлектән чыгып караганда әлеге ышанулар беркатлылык булып тоелса да, халык үз вакытында алар ярдәмендә кешеләрне сизгерлеккә, уяулыкка, сакланып, уйлап эш итәргә өйрәтү максатын

да күздә тоткан. Гомумән, юрау-ышанулар халык педагогикасында әһәмиятле урын алып торалар. Яшь

буында үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, пакьлек, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә халык бу төр әсәрләрдән киң файдаланган. «Әгәр шуны эшләсәң, шундый хәл була» дип, төрле ямьсез гадәтләрне кисәтү өчен, ул кайбер ышануларга аңлы рәвештә бераз «шагыйрәнә ялган» да кушкалаган булырга охшый. Мәсәлән, «*Өстәл сөрткәндә чүп калдырсаң, киявең шадра була, имеш*», «*Чит кеше мендәрендә йокласаң, чәчең коела*», «*Яшь баланы тәрәзә төбенә бастырып каратсаң, кәтүк* булып кала*».

Юрау текстлары, кагыйдә буларак, шарт һәм нәтиҗә өлешләреннән торалар, «шул булса, шул була» дигән формулага туры киләләр. Әмма кайбер ышанулар турыдан-туры раслау рәвешендә бәян ителәләр: «*Абзар иясе яраткан атларының ялын үрә*», «*Ай нуры киндер агартуга яхшы*» һ. б.

Юраулар өчен бик күптөрле билге-галәмәтләр нигез булып тора: табигатьтәге яшерен көчләргә, мифик затларга, бәхетле һәм бәхетсез көннәргә, аерым хайваннар һәм кошларның, агачлар һәм үләннәрнең, ташлар һәм металларның тылсымына ышану, кешенең тән төзелешендәге үзенчәлекләр, төш күрүләр һ. б. Бу бүлектәге әсәрләр әнә шундый тематик төркемнәр буенча биреләләр.

## МИФИК ЗАТЛАРГА, ТАБИГАТЬ КӨЧЛӘРЕНӘ, АЕРЫМ ЕЛ, АЙ, КӨННӘРГӘ КАГЫЛЫШЛЫ ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Абзар иясе яраткан атларының ялын үрә.
Ай яктысында ут яндырмый җеп эрләсәң, аны өй иясе чуалтып бетерә.
Атна кич тырнак кисмәскә — эт тырнагы чыга.
Аш-суның өстен ябарга кирәк — шайтаннар юына.
Әгәр Елкы елы* килсә, ул елны орыш-сугыш күп булыр.
Боз яуганда тәрәзә аша тимер ташласаң, боз явудан туктый.
Дуңгыз елы* килсә, угылларга саусызлык тияр, ләкин соңы яхшы булыр.
Елан елны* өйләнмиләр — бәхетле булмыйсың.
Җәй көне боз яуса, ишегалдына пумала ташлыйлар — боз туктый.
Җиде төн уртасында абага чәчәген ашасаң, кеше күзенә күренмисең икән.
Җир өстендә ут күренсә, ул урынга хәзинә күмелгән була, имеш.
Имеш, күк кабагы* ачылуын күргән кеше бәхетле була.
Иртәнге сәгатьтә җырласаң, бәхетсез буласың.
Кич белән егылсаң, зәхмәт кагыла.
Кич кешегә акча бирсәң, бәхет китә.
Кич чишмәгә суга төшәргә ярамый.
Кичтән ишек ачып мәче кертергә ярамый — шайтан керә.
Койрыклы йолдыз — афәткә.
Кояш баеганда йокларга ярамый — бәхетең кими, ди.
Кура иясе атны яратмаса, атланып йөреп тирләтеп бетерә, кыйный, ашатмый икән.
Кырык көнгә кадәр баланы ялгыз калдырырга ярамый — җен алыштыра.
Өй иясе йон эрләгән тавыш чыгарса, хуҗаны баета, чабата үргән тавыш чыгарса — бөлдерә, имеш.
Сишәмбе тынгысыз көн: кер юарга, тырнак кисәргә, юлга чыгарга ярамый.
Суга сокланып карасаң — тота. «Бу су каты икән, салкын икән»,— дияргә кирәк.
Убыр ут булып күренә: тәгәрәп бара-бара да чәчелеп китә, аннан тагын юл ала.
Ут сызгырса, ерактан хәбәр килә.
Утка төкерсәң, авыз кутырлый.
Чәршәмбе көн кигән кием өстеңдә тузмый, ди.
Шимбә көн тырнак кисәр булса, ул кешенең зәхмәте китәр.
Шимбә көн юлга чыгарга, эш башларга ярамый.
Шүрәле кешене кытыклап үтерә.
Шүрәле судан шүрли.*
Яшен аткан шайтан урманга төшсә — убыр, суга төшсә — су анасы, җиргә төшсә, албасты була, ди.
Яшен «җенгә сугам» дип суга икән.

## ТӨРЛЕ АГАЧЛАР, ҮЛӘННӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Артыш агачыннан җен курка.
Давыл чәчәген* өзсәң, давыл чыга.

Каенны өй янына утыртсаң, кайгы була, имеш.
Киндерне суккан вакытта кытыршы калдырсаң, киявең шадра булыр.
Киткән кызга гөл бүләк итмиләр.
Куш җиләк ашасаң, игез бала табасың.
Күз тимәсен өчен, бала кулына miләш агачы бәйлиләр.
Ут чәчәген* өйгә кертсәң, янгын була.
Ялгыз агач янына шайтан оялый — яшен вакытында аңа якын барырга ярамый.

## ХАЙВАННАР, КОШЛАР, БӨҖӘКЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Авылда янгын булса, йорттагы мәчене карарга кирәк: әгәр янгын йортка килмәс булса, мәче тыныч кына утырыр. Әгәр куркыныч килсә, мәче чыгып качар.
Ак таракан төшеп түргә таба барса, кунак килә.
Әгәр козгын җиргә төшеп, канат кагып, өч ягына карап коркылдаса, изгелеккә булыр.
Әгәр мәче ишек тупсасына утырып битен юса, кунак килә. Әгәр икенче урынга күчереп куйгач та битен юуны дәвам итсә, куна килә.
Балыкны тоткач санарга ярамый: бәрәкәте бетә.
Бәла-казага каршы әтәч тавык булып кычкыра.
Беренче сыерчыкны күргәч, җирдәге кар суы белән йөзне сыпырырга кирәк: шулай итсәң, сипкел бетә.
Елан аягын* күргән бәхетле була.
Елан дисәң — елата, камчы дисәң — тик ята*.
Җиде еллык кисеркә чакса, име табылмый, ди.
Ишегалдына кара елан керсә — бәхетсезлеккә, ак елан керсә — яхшылыкка, диләр.
Ишектән мәче белән бергә чыксаң, юл уңмый.
Йортта эт җир казыса — мәет, чикерткә сызгырса — янгын, таракан качса — ачлык.
Каз өмәсеннән чыгып киткәндә тастымалны хуҗа башына салып чыксаң, киләсе елга каз күп уңа, имеш.
Кәлтә елан үлә торган кешене генә чага икән.
Козгын тау башына барып коркылдаса, дошман киләсенә.
Козгын түбәндә ясанып утырса, бу кешегә караклар килер.
Көтү килгәндә алдан кызыл сыер килсә, көн кояшлы булыр, әгәр дә кара сыер килсә — болытлы булыр.
Күгәрченнең йомыркасын алсаң яки оясын ватсаң, өй түбәсенә ут ташлап китә икән.
Мәче битен юса, кунак киләсенә.
Саескан тәрәзәгә кунса, кунак килә, ди.
Сөтне кояш баегач кешегә бирергә ярамый — сыерның сөте кими.
Умарта башына ак таш йә сөяк куйсаң, корт аерганда еракка сармый, диләр.
Хайван сатканда йонын йолкып калырга кирәк: токымы китмәсен дип.
Чыпчык тәрәзәдән килеп чукыса — кунак көт.
Эт уласа, бәхетсезлек була.
Юл аркылы кара мәче чыкса, юлың уң булмый.
Юлга чыкканда эт очраса, юл уңа.
Яз көне беренче тапкыр пар сыерчык күрсәң — парлы буласың.
Ярканат канаты белән берәр кешегә кагылсаң, ул сине ярата башлый, ди.
Яшен сугып пожар чыкса, кара сыер сөте сибәргә кирәк.
Яшь балага сыерчыклар, киек казлар тел һәм аяк алып килә, диләр.

## КЕШЕНЕҢ ТӘН ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ ФИЗИК ХАЛӘТЕНӘ КАГЫЛЫШЛЫ ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Арка тибрәнсә, хурлык булыр.
Ашаган вакытта киерелсәң, үсми каласың.
Ашаганда телең тешләсәң, кунак ачыгып килә, имеш.
Аягы йонлы — мал-туардан бәхетле булыр.
Әгәр иякнең уң ягы тартса, яхшылык күрер.
Баланың кул бармаклары аерылып торса, юмарт буласы.
Бәхетле буласы бала карындыгын* башына киеп туа, имеш.

Беләге миңле — уңган булыр.
Битең кызышса, димәк, сине яманлыйлар.
Борын очы кычытса, күчтәнәч килә.
Җилкә чокыры тирән кеше ялганчы була.
Җилкә чокырында су торса, кеше уңган була.
Ике каш арасы ерак булса: кызлар — еракка кияүгә китә, егетләр — ерактан ала.
Ирене калын кеше юаш була, ирене нечкә — усал була.
Каш тартса, каш-күздән якын туганың белән күрешәсең.
Керфегең озын булса, гомерең кыска булыр.
Кеше кулындагы сөялне санарга ярамый — үзеңә чыга.
Колагы каты — саран, колагы йомшак — юмарт.
Колагың чыңласа, димәк, сине сөйлиләр.
Колак яфрагы йомшак бала гыйлемгә һәвәс.
Кулы каты егет карт хатын ала, имеш.
Күз кабагының уңы тартса — яхшылыкка, сулы тартса — начарлыкка, өсте тарса — шатлыкка, асты тартса — кайгыга, диләр.
Күз кычытса — елыйсың.
Кытыгы килгән кеше көнче була, ди.
Миңе битендә булса, мәхәббәтле була.
Очкылык тотса, сине берәрсе исенә төшереп сөйләгән була.
Өстәл астында аягыңны селкеп утырсаң, җен чакырасың, имеш.
Сул кулның уч төбе кычытса — акча чыга, уң кулның уч төбе кычытса — акча керә.
Табан астың кычытса — юлга чыгасың.
Тел очың тартса — ерактагы кешең белән сөйләшәсең.
Теш иртә чыккан бала зирәк була.
Теше сирәк булган кешенең авызында сүз тормый.
Тырнак өстендә кисәк-кисәк аклар хасил булса, яңа кием киясең.
Уң балтыр тартса, авырлыклар күрүгә дәлил.
Уң чигәң кысса — мактарлар, сул чигәң кысса — хурларлар.
Чәч үргәндә толымга эләкми калса, юл була.
Чәче йомшак кешенең табигате дә йомшак.
Чәчеңне үргәндә озын чәчең торып калса, хат килә.
Яшь баланың казык теше алдан чыкса — усал була.
Яңагыңа таянып утырсаң, ятим каласың, имеш.

## ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШ ФАКТЛАРЫНА НИГЕЗЛӘНГӘН ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Ашаган сыныгыңны калдырсаң, иптәшең ташлар.
Ашап утырган чәйгә икмәк кисәге төшсә, кунак килә.
Әгәр берәрсе ашый торган икмәк кисәген онытып икенчесенә үрелсә, «кемдер ашыгып килә» дип юрыйлар.
Бал белән авызланганның* теле татлы булыр, май белән авызланганның теле йомшак булыр.
Баш киемен мунчала итеп идән юарга ярамый — башың түбәнчелеккә төшәр.
Бирәчәк нәзереңне* үтәмәсәң, култык астыңа эт имчәге* чыгар.
Берәр җиргә барырга чыккач, кире кермә — юлың уңмый.
Ботка пешергәндә болгаткан калагыңны ялама — киявең таз булыр.
Бусагага утырсаң, үсми каласың.
Бусагага утырсаң, ярлы буласың, диләр.
Бусаганы атлап керергә кирәк, басып керсәң, өстеңнән сүз китмәс.
Ерактан килгән күчтәнәчне ашасаң, гомерең озыная, имеш.
Җиледән* атлап узарга ярамый — аяксыз калырсың.
Идән себергәндә артыңда чүп калдырсаң, киявең карт булыр.
Идәнгә пычак төшсә, ир кунак килә.
Ишек астына ат дагасы кадаклап куйсаң, аяк арасыннан өйгә шайтан керми, ди.
Ишектән кергәндә итәк кысылса, кунак килә.
Казан өстеннән ашасаң, фәкыйрьлек килә.
Караңгыда ашама — киявең карак булыр.
Каршыңа буш чиләкле кеше очраса, юлың уңмый.
Кашык төшеп китсә, хатын-кыз кунак килә.

Кеше кулыннан энәне тотып алма — дошманлашырсың.
Киемне сул ягы белән төреп куярга ярамый — бәхетең киреләнеп килми торыр.
Кисеп, өеп куйган икмәк ишелеп төшсә, кунак килә.
Кискән икмәкне ишеккә каратып куярга ярамый: имеш, чыгып китә, ди.
Көзгегә карап җырласаң, сүз ишетәсең.
Көйгән әйбер ашаган кеше аюдан курыкмый, ди.
Көянтә аркылы атлап чыксаң, кыярак* дигән шеш чыга.
Кулны югач, юеш килеш селкергә ярамый: шайтан ярала.
Күмер таптасаң, нахак сүз ишетерсең.
Матча турына ятсаң — саташасың.
Мич шауласа, яхшы хәбәр килә.
Нигез балчыгын кешегә бирмиләр — йортың таркала.
Өстәл почмагына утырган кеше җиде ел өйләнә алмый, ди.
Өстәл сөрткәндә чүп калдырсаң, киявең шадра була.
Самовар, озак кайнаса, кунак көтә.
Типкә* типмә — балаң елак булыр.
Тоз түгелсә, кычкырыш була.
Үз күчтәнәчеңне ашасаң, гомерле буласың.
Чәй ясаганда чәе артса, ул кеше бәхетле була.
Чиләк кара-каршы бәрелсә, яңгыр ява.
Чит кеше мендәрендә йокласаң, чәчең коела.
Чүп өстеннән чыгарга ярамый — өстеңә начар сүз әйтәләр.
Эскәтергә бит сөртсәң, биткә оят килә.
Юлга чыкканда буш чиләкле кеше очраса, юл уңмый.
Яше тулмаган баланы көзгедән каратырга ярамый: сакау була.

## ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫНА КЕРГӘН КАЙБЕР ЮРАУ-ЫШАНУЛАР

Айгыр тимрәве* булса, чәршәмбе көнне айгыр кебек кешнәп, язу карасы сөртергә кирәк.
Арпа* дисәң — арта, бодай дисәң — бетә.
Балага күз тимәсен дисәң, башта — уң, аннан сул аягын карарга кирәк, имеш.
Балага күз тимәсен өчен, аның башлыгы эченә миләш агачы яфрагы яки чыбыгы тегеп куялар.
Балага күз тимәсен өчен, маңгаена күмер белән сөртәсең яки артыш агачын кисеп, аны беләгенә тагасың.
Бизгәк авыруы белән авырган кешене бик каты куркытсаң, бизгәге кача, ди.
Бил авыртса, беренче күк күкрәгәндә җирдә ауныйлар.
Бүре уты* чыкса, бүре кебек улап, кызыл әйбер белән уасың.
Елан карагы* булса, үлгән еланны кайнар суга салып, шуның парына күзне томалап утыралар.
Ипи шынасы* булса, баланы көрәккә бәйләп мичкә тыгып алалар.
Кулга яки башка җиргә сөял чыкса, чикерткәдән тешләтергә кирәк.
Күз тигән кешене гөмбә белән төтәслиләр.
Күзгә арпа чыга башлагач та пычак күрсәтсәң, куркып чыкмый, имеш.
Муен авыртканда ата казга сәлам бирсәң төзәлә, имеш.
Суык тотса* курыксын өчен, бәхерниса* күрсәтәләр.
Теш бакасын*, имләгәндә бака казанына су салып, шуны өчкә бүлеп йоталар.
Теш сызламасын дисәң, табаныңны мунчада кырык бер тапкыр чабарга кирәк.
Төнлә белән сөяләңне айга күрсәтеп: «Менә минем чәчәгем, бармы синең чәчәгең?» — дип мактансаң, ай аны ала икән.
Үз күләгәсеннән куркып авырган кеше терелми, ди.
Чәчәк чире чыккан баланы тавык йоны мендәренә яткырсаң, чәчәге юкка чыгар.
Чуан дисәң — чыгам, ди, коры ботак, дисәң — корый.

## ТӨШ ЮРАУ ҮРНӘКЛӘРЕ

Агым су аша йөзеп чыксаң, кайгыдан арынасың.
Әгәр төшеңдә бодай күрсәң, сөенеч булыр.
Әгәр төштә сары май* күрсәң, чир килер; катык йә сөт күрсәң, кулыңа хәләл мал керер.
Коедан су алганны күрсәң, кияүгә чыгасың.
Мәет турында төш күрсәң, өңдә дә мәет була.

Төшеңдә бакыр акчалар алсаң, нахак сүз ишетәсең.
Төшеңдә бал корты күрсәң, хәләл мал насыйп булыр.
Төшеңдә еласаң — шатланасың.
Төшеңдә куян, каз күрсәң, бер туганың килә.
Төшеңдә тавык күрсәң, хәрам малдан өлеш тияр.
Төшеңдә тауга менсәң, бәхетле булырсың.
Төшеңдә чи ит, йомырка күрсәң, авыруга була.
Төшеңдә шикәр һәм бал күрсәң, ил арасында олы дәрәҗәле буласың.
Төшеңдә яшеллек күрсәң, тиз килә торган шатлык.
Төштә ак әйбер — шатлык, кара әйбер — кайгы, кызыл әйбер — кыстау, яшел әйбер — озын гомер.
Төштә ак тун кисәң, байлыгың күп була.
Төштә атка атлану — мәртәбәгәирешү.
Төштә болганчык су — көтелмәгән күңелсезлек; саф, чиста су — яхшы хәбәр.
Төштә гармун тавышы ишетсәң, хәбәр була.
Төштә җеп эрләсәң, ерак җирдән якын кешең килә.
Төштә карчыга күрсәң, ил эчендә мәртәбә казанырсың.
Төштә көзгегә карау яки яңа аяк киеме кию — тормышка чыгу.
Төштә сәмруг кош* күрсәң, олуг мәртәбәле булырсың.
Төштә солы яки карабодай күрсәң — авыру.
Төштә су керү — елау.
Төштә суны көймә белән кичсәң, башка илгә барасың.
Төштә төрле җепләр күрү — юлга чыгу.
Яңа урында беренче мәртәбә йокларга яткач, түбә тактасын санап йоклыйлар: «Әйбәт төшләр, дөрес төшләр керсен»,—дип.
III БҮЛЕК

# Ай колакланса — аязга

Юрау-ышанулар кебек үк, киләчәккә прогноз ясау өчен хезмәт итә торган тагын бер афористик жанр бар. Ул — **сынамыш**. Ләкин бу жанрлар арасында бик җитди ике аерма күзәтелә. Беренчедән, әгәр юраулар иҗтимагый һәм шәхси тормышның барлык өлкәләре буенча үткәрелсә, сынамышларның кулланылыш сферасы бик чикле. Алар бары тик киләчәктә нинди һава торышы көтелүен һәм ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышының ничек булачагын чамалау максатын гына күздә тоталар.
Икенче аерма шунда: юраулар башлыча хорафатка, әйберләр һәм күренешләр арасындагы тышкы охшашлыкка корылган булалар. Сынамышларның нигезендә исә табигать дөньясындагы күптөрле сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ята. Бу әйтелгәннәрне мисаллар өстендә карап үтик. «*Мәче башлы ябалак кычкырса, ашлык начар булыр*» дип юрау бар. Монда халыкның бу сәер коштан, аның ямьсез тавышыннан шомлануы күренә. Ә игенченең шомланулары, аңлашыла ки, ашлык уңмауга, ачлыкка барып тоташа. Ябалак ул инде һәр елны кычкыра торгандыр, ләкин уңыш ел саен түбән булмый бит. Кыскасы, монда без кара ышануга корылган юрауны күрәбез. Тагын «*Чыңгырау торна биегән җирдә иген булмый*» дип тә әйтәләр. Ләкин монысы инде хорафат түгел,
ә сынамыш, ул кат-кат тәҗрибә белән нигезләнгән. Чыңгырау торналар яңгырсыз, кызу елларда гына киләләр икән. Димәк, корылык булгач, әлбәттә инде, иген уңмаган.
Прогноз ясау өчен сынамышларда табигать дөньясындагы төрле-төрле билге-галәмәтләр файдаланыла: күк җисемнәренең ничек күренүе; табигать күренешләренең нинди характерда булуы; ел фасыллары, аерым айлар йә көннәрнең ничек килүләре; үләннәр, куаклар, агачлардагы төрле үзгәрешләр; хайваннар, кошлар, бөҗәкләрнең үз-үзләрен тотышлары һ. б.
Бу тематик төркемнәр эчендә «тере барометрлар» сынамышларның төгәллегенә шактый зур ышаныч тудыралар. Чөнки хайваннар, кошлар һава торышының якында булачак үзгәрешләренә аеруча сизгерләр. Хәзерге вакытта кешеләр, 600 төрле тереклек иясенең үз-үзен тотышына карап, һава хәлләрен алдан ук билгели алалар. Еш кына бу эш җитди фәнни нигезгә корыла. Алма-Ата шәһәре сейсмологлары, махсус биологик полигон оештырып, анда тотылучы бурсыклар, еланнар, байбаклар һәм хәтта чәүкәләр ярдәмендә җир тетрәүләрне алдан белеп тору мөмкинлекләрен өйрәнәләр. Япониядә шушы юнәлештә крокодиллар белән тәҗрибәләр үткәрелә. Бу хайваннар, кагыйдә буларак, тыныч яшәргә яраталар. Инде алар үкерә-кычкыра башласалар, кимендә 5—6 сәгатьтән соң 150 километр чамасы радиуста җир тетрәү яки вулкан ату ихтимал икән.
Билгеле инде, мисалларны ерак иллардән китереп, без үзебезгә «якташ» хайваннар һәм кошларның

(ат, сыер, сарык, эт, мәче, әтәч, торна, карлыгач һ. б.) «синоптиклык сәләтләренә» күләгә төшерергә җыенмыйбыз. Алар турында бу бүлектә күп кенә сынамышлар урын алган.

Агачлар һәм үләннәр дә һава үзгәрешләрен сизүдә җан ияләреннән әллә ни калышмыйлар. Һәр агачның, шулай әйтергә яраса, үз холык-гадәтләре бар. Халык чыршы агачында күркәләр күп һәм эре булуны уңыш әйбәт булырга юрый. Чөнки бу агач, үз кәүсәсендә дым күпме булуга карап, аны ел дәвамында бик «акыллы» файдалана. Дым күп икән, язын күркәләрне дә күп җибәрә. Шуларга карап, игенче әле чәчү алдыннан ук туфракта дымның күләме турында үзенчәлекле сигнал ала.

Сынамышларда ике күренеш арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре турыдан-туры түгел, ә өченче бер күренеш аркылы чагылырга да мөмкин. Мәсәлән, «*Карлыгач түбән очса, яңгыр булыр*» диләр. Карлыгач яңгыр якынаюын үзе сизми. Хикмәт шунда: бу кош һавада очып йөрүче бөҗәкләр белән туклана.

Ә яңгыр алдыннан, һаваның дымлылыгы арту сәбәпле, бөҗәкләрнең «очу аппаратлары» авырая, алар югары күтәрелә алмыйлар. Нәтиҗәдә, бөҗәкләрне эләктерү өчен, карлыгачка да түбәндә очарга туры килә.

Әлбәттә, хәзерге вакытта — көндәлек һәм айлык прогнозларны билгеләүдә куәтле һәм сизгер техника кулланылганда — халык сынамышлары бу җәһәттән җитди роль уйнамыйлар. Алар безгә, гамәли яктан бигрәк, халыкның табигать дөньясына шагыйрәнә карашын гәүдәләндергән фольклор җәүһәрләре буларак кыйммәтле.

## ҺАВА ТОРЫШЫ НИЧЕК БУЛАЧАГЫН СЫНАУ

### Күк җисемнәре, табигать күренешләре буенча

Ай колаклы булса, суык булыр — кыш көнендә; әмма җәй көне колаклы булса, яңгыр булыр.
Ай тирәсендә алка кебек булса, җил булыр.
Ай очы белән туса, көннәр явымлы булыр.
Ай тулы вакытта саф һәм якты ялтырап торса, һава яхшы булыр.
Ай утырып туса, аяз булыр.
Ай чалкан туса — аязга, кырын туса — явымга.
Аяз буласы булса, томан тамчы-тамчы юеш булыр.
Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.
Әгәр кояш баегач һава кызарса, бер-ике көннән һава бозылыр.
Әгәр яңа ай нечкә күренсә, ай буена ачык һава булыр.
Әгәр яңа ай саргылт булып калын күренсә, бөтен ай юеш булыр.
Әүвәлге карны күрсәткәч, кырык көннән кар ятыр.
Беренче күк күкрәү көннәр җылына башлауга булыр.
Бер рәттән өч-дүрт мәртәбә күк күкрәсә, һава бозылыр.
Болыт кыйблага таба барса — көн аязырга.
Болытлар бер-беренә каршы килсә, һава бозылып, яңгыр булып торыр.
Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.
Болытлы көнне кояш кисәк-кисәк кыздырса, кич — яңгыр.
Вак яңгыр томалап ява башласа, һава озакка бозылыр.
Җәй көне йолдызлар бик чекерәеп ялтырап торса, һава коры һәм эссе булыр. Кыш көне шулай булса, көннәр суык булыр.
Җидегән йолдыз карасу булып күренсә, яңгырлы булыр.
Җил кояш артыннан килсә, көн аяз булыр.
Җил кояш баешы тарафыннан килсә, һаман яңгыр китерер.
Җилгә каршы яуган яңгыр каты давыллы булыр.
Иртә белән болытлы булып, кояш чыкканда аязса, ул көнне яңгыр булмас.
Иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы килер.
Иртән кояшны томан капласа, аяз булыр.
Йолдыз атылса, җил булыр.
Йолдызлар ачык күренсә, көн яхшыра, тонык күренсә, яңгыр яки кар ява.
Йолдызлар куе күренсә, аяз булыр.
Кайсы якта йолдызларның нуры озынрак күренсә, җил шул яктан булыр.
Кич аяз булып та, йолдызлар аз күренсә, яңгыр булыр.
Кояш агарып чыкса, шул көнне һәм киләсе көнне дә аяз булыр.

Кояш баеганда кызыл булып күренсә, җил булыр.
Кояш баердан элек югары вакытта һава кызарса, шул кич үк һава бозылыр.
Кояш батканда аяз булып, төньягыннан салкынча җил булса, кырау булыр.
Кояш баткач та караңгылык төшсә, яңгыр булыр.
Кояш колакланып чыкса, салкын булыр.
Кояш кызарып чыкса, яңгыр булыр. Кыш көне шулай чыкса, салкын булыр.
Кояш тирәсендә нурлар югары чагылса, буран булыр, түбән чагылса, салкын булыр.
Кояш томан вакытында чыкса, көндез бөркү булыр.
Кояш чыкканда багана кебек нурлар күренсә, суык булыр.
Кояш чыкканда зуррак булып күренсә, яңгыр көтәргә кирәк.
Кояш чыккач та болыт астына керсә, яңгыр булыр.
Күк болытлар арасында ак болыт булса — боз булуга.
Күк иртә күкрәсә, яз иртә килер.
Кыйбла ягыннан эре болытлар чыкса, яңгыр булыр.
Кыш көне кояш тирәсендә алка кебек булса яки кояш колаклы булса, бик суык булыр.
Салават күпере бик югары булса — аяз, бик түбән булса — яңгырлы.
Салават күпере бөтенләй түгәрәк күренсә, яңгыр булыр.
Салават күпере суга төшсә, явымнар күп була.
Салават күпере яңгыр яуганда өч булып чыкса, бөтен атна яңгыр булыр.
Салават күпереның ике башы да суга төшсә, яңгыр булыр, ике башы да тауда булса — аязга.
Салават күпереның яшеле бик ачык яшел күренсә, көн яңгырлы булырга галәмәт. Әгәр кызылы бик ачык кызыл күренсә, җилле булырга галәмәт.
Туган ай дугалы булса, давыл булыр.
Һава озак ачык булып торса, яңа ай белән яңгыр булыр.
Һава яңгырлы һәм юеш вакытта күктә аксыл төсле болытлар йөрсә, аязлыкка галәмәт.
Чык тиз кипсә, яңгыр булыр.
Ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы, юеш булыр.
Яңа ай белән җил булса, бөтен ай буена җил булыр.
Яңа айның очлары нәзек күренсә, салкын булыр.
Яңгыр кире кайтып ява башласа, бик куәтле булыр һәм боз да булыр.
Яңгыр тамчысы су өстендә эре булып күбекләнеп торса, янә яңгыр булыр.
Яңгырлы вакытта куәтле җил чыкса, һавалар яхшы булачагын белгертә.

## ЕЛЛАР, ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ, АЙЛАР, КӨННӘР, ТӘҮЛЕКНЕҢ ТӨРЛЕ ВАКЫТЛАРЫ БУЕНЧА

Август аенда аяз булса, көз пычрак булыр.
Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр.
Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшыга килә.
Әгәр җәй көне төшлек тарафыннан җил килсә, һава яхшы булыр. Кыш көне булса, көн җепшек булыр.
Беренче кар көндез яуса — кыш салкын, төнлә яуса — җылы була.
Беренче мартка кадәр кара карга күренсә, кар тиз китәр.
Беренче мартта урамда су күренсә, язгы ташуда су күп килер.
Беренче октябрь. Бүген кар күренсә, кырык көннән кар күренер. Бүген җил көнчыгышыннан булса, кыш суык булыр.
Гыйнвар унында бәс тотса, җәй яңгырлы килә.
Җәй көне яңгыр болыты аксыл күренсә, боз явар.
Җәй көне һава аксыл сары булып күренсә, аяз булыр.
Егерме бишенче июльдә кырау булса, кыш суык булыр.
Елан елы* җылы була, Сыер елы* суык була, Дуңгыз елы* коры була, Балык елы* явым була.
Илҗен көн* өйләдән элгәре — җәй, өйләдән соң — көз.
Июль. Егерме бишендә кырау булса, кыш суык килә.
Кич һава җылынып китсә, яңгыр галәмәте.
Көз озын килсә, яз соң килер.
Көзнең ахырларында түгәрәк-түгәрәк вак боз яуса, кыш суык булыр.
Ләү елы* килсә, ул ел явымлы булыр.
Май егерме берендә яңгыр булса, көз яңгырлы булыр.
Март башы көн тавык эчәрлек су булса, яз яхшы килә.

Ноябрь тугызында бәс булса — суыкка, томан булса — җылыга.
Сентябрь аяз — кыш салкын.
Тычкан һәм Елан елларында һава җылы булыр.
Унбишенче февральдә көн җылы булса, яз яхшы була.
Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коргак була.

## УТ-СУ, ТАБИГАТЬТӘГЕ ҺӘМ КӨНКҮРЕШТӘГЕ ӘЙБЕРЛӘР БУЕНЧА

Ага торган суга аркылы яуса, яңгыр тиз туктар.
Ашлык урганда урак күгәрсә, яңгыр булыр.
Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.
Буадагы су кимесә, өч көннән яңгыр галәмәте.
Җилсез һавада төтен җиргә таба төшсә, яңгыр галәмәте.
Кайнаган самоварның борыны тыгызланса — көн суыта, бушаса — җылыта.
Кое суы кими башласа — яңгыр галәмәте, арта башласа — аязга.
Кыш көне җепшек буласы булса, тоз юеш булыр.
Кыш көне утның кызулыгы еракка җитсә, салкын булыр.
Мичтә утын шартлап янса, көннәр җылытырга булыр.
Мичтәге ут кызыл булып янса, көн салкын була.
Морҗадан чыккан төтен туры булып өскә менсә, көн аяза, суыта. Әгәр төтен җиргә ятса, көн җылыта.
Сабан тимере җиргә кергәч, салкыннар булыр.
Самоварның борыны кысанайса, буран булыр.
Су күбекләнеп акса, тиз яңгыр булыр.
Утын сызгырса, көн суытыр.
Чыра пырылдап янса, буран була.
Явым буласы булса, тоз даим юешләнеп торыр.
Яна торган чыраның уты атылып төшсә — салкын булуга галәмәт.

## ҮЛӘННӘР, КУАКЛАР, АГАЧЛАР БУЕНЧА

Ашлык урганда салам шартлап сынса, яңгыр булыр.
Әгәр көз көне каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласалар — ел җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласалар — ел салкын килә.
Балан чәчәк атканда, балык сикерә.
Зирек агачы башлап яфрак ярса, җәй яңгырлы һәм җылы була, ә каен агачы башлап ярса, җәй корылыклы була.
Имәндә чикләвек күп булса, кыш каты килә.
Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була.
Кузгалак күп булса, кыш җылы булыр.
Суган кабыгы калын булса, кыш салкын була.
Урган камылдан су чыкса, яңгыр явар.
Урман җилсез шауласа, яңгыр булыр.
Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласалар, яз тиз килә.

## ХАЙВАННАР, КОШЛАР, БӨҖӘКЛӘР БУЕНЧА

Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.
Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.
Ала карга агач башына кунса, яз тиз, җиңел килер, җиргә кунса — озак килер.
Апрель аенда торна кычкырса, ел яхшы килә.
Ат аягын тибенсә, яңгыр булыр.
Ат юлга ятса, буран булыр.
Әгәр кырмыска биек түмгәк ясаса, кыш суык килер.

Әгәр тәкәрлек һәм бытбылдык биек җиргә оя ясаса, җәй яңгырлы булыр.
Әрлән өненә печән-салам күп ташыса, кыш салкын булыр.
Бака корыга чыкса, яңгыр була.
Балыклар су өстендә уйнасалар, яңгыр була.
Болыт килгәндә әтәч кычкырса — көн аязырга.
Бүген мәче тырнаша: буран булыр.
Елан яки кәлтә кояшта кызынсалар, тиз яңгыр булыр.
Каз авызын шакылдатса, рашкы* явар.
Каз башын канат астына тыкса, салкын була.
Казлар суда чумып-чумып уйнаса, яңгыр була.
Карга, чәүкә түбәннән очса, кар ява.
Карга җилгә каршы утырып кычкырса, яңгыр булыр.
Кечкенә кошлар һавага биек күтәрелсә, аяз булыр.
Кичен бака кычкырса, көн җылы була.
Кортлар ояны иртә сыласалар, кыш иртә килә.
Кояш баегач әтәч кычкырса, көн аяз булыр.
Көз көне пәрәвез очса, көз яхшы килә.
Көз көне тычкан-күсе күп булса, кыш җылы килер.
Күке бака тавышы чыгарып кычкырса, яңгыр булыр.
Кыслалар судан корыга чыксалар, һава бозылыр.
Кыш көне мич астында чикерткә кычкырса, көн җылытыр.
Мәче башлы ябалак кычкырса, суыклар башланыр.
Мәче борынын яшереп йокласа, көн суыта.
Песи мич башына менеп ятса — суык; идәнгә, җиргә ятса — җылы буласы.
Песи тәрәзәдән карап торса, көн яхшыга булыр.
Сентябрь башларында тавыклар каурыйларын коя башласалар, ел суык була.
Сөлек төптә ятса, аяз булыр. Әгәр судан корыга чыгарга үрмәләсә, тәүлеккәчә яңгыр булыр.
Суык буласы булса, төлке эт кебек өрер.
Сукыр чебеннәр күзгә кереп йөдәтсәләр, яңгыр булыр.
Сыер арт аягын калтыратса, салкын булыр.
Сыер сауганда сөт шаулап күбекләнсә, яңгыр булыр.
Тавык бер аяк белән басып торса, өй түбәсенә очып менсә — суык булыр.
Тавыклар озак йокламаса, яңгыр була.
Тартай, бүдәнә кычкырса, яңгыр булыр.
Тилгән кычкырса, озак аяз булыр.
Торна биесә, һава җылыныр.
Тычканнар, күселәр ояны тирән казыса — кыш суык.
Умарта кортлары оядагы ярыкларны калын сыласалар, кыш салкын була.
Үрдәкләр суда кагынып кычкырсалар — яңгырга. Әгәр суда шыпырт кына торсалар, яшен булыр.
Черки-чебеннәр киле төйгән кебек уйнаса, аяз, һава яхшы булыр.
Чыпчыклар агач очына кунсалар, көн салкын була, түбән ботакларына кунсалар, җил чыга.
Эт аунаса: кышын — буран, җәен тузан, җил була.
Эт үлән ашаса, бик озак яңгыр булыр.
Яңгыр алдыннан күркәләр җиргә аунар, кагыныр.
Яңгыр буласы булса, карлыгач бик түбәнтен очар.
Яңгыр буласы булса, кырмыска оясына таба йөгерешер.
Яңгыр яуганда әтәч кычкырса — яңгыр туктауга.

**КЕШЕ ӘГЪЗАЛАРЫ БУЕНЧА**

Арка сызласа, буран булыр.
Борын томауласа, яңгыр булыр.
Кеше авырайса, явым була.
Колак кычытса, яңгыр яки кар ява.
Көндез йокы басса, буран булыр.
Кул коргаксыса, явым була.
Теш сызласа, һава бозылыр; яңгыр йә буран булыр.
Уч төбе кычытса, кар яки яңгыр ява.
Яшь бала бик еласа, яңгыр булыр.

## АШЛЫК, ЯШЕЛЧӘ, ҖИЛӘК-ҖИМЕШ УҢЫШЫ НИЧЕК БУЛАЧАГЫН СЫНАУ

### Күк җисемнәре, табигать күренешләре буенча

Әгәр беренче кар вак булса, кар тиз китмәс, җәй яңгырлы булыр, ашлык, печән яхшы уңар.
Әгәр боз өстенә боз катса, ашлыкка галәмәт.
Әгәр Иделдә кисәктән боз катып, кыш та кисәктән булса, ашлык бик уңар.
Җәй көне гел томан булса, гөмбә күп булыр.
Беренче күк күкрәү кыйбла ягыннан булса, иген уңар.
Боз кытыршы булып туңса, иген уңар.
Еллар чыклы булса, бал күп булыр.
Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас.
Кар кояш белән кипсә, бодай уңар.
Кыш башында беренче кар авыр булса, орлык авыр булыр, тук булыр.
Кыш көне бәс күп булса, агач җимешләре уңар, бал күп булыр. Әгәр бәс күп булып, агач ботаклары салынса, һәртөрле җимешләр һәм ашлыклар булыр.
Күк күкрәүдән элек яшен яшьнәсә, ачлык булыр.
Сабан сөргәндә ярмалы балчык чыкса, ул җирдә ашлык уңар.
Салават күпере элек күренгәндә кайсы яктан күренсә, шул яктагы ашлык уңар.
Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.
Томан күп төшсә, җимеш уңар.
Һавада аҗаган уйнаса, иген уңар.
Чана юлы соңга калса, ашлык уңар.
Яз көне елга кырыйларында боз калса, ашлык уңмас.
Яз көне елгаларда су артмаса, ашлык уңмас.
Яз көне тамчы бозлары озын булса, сабан ашлыгы озын булыр; әгәр кыска булса, сабан ашлык кыска булыр.
Яз көне урамнарда кар элегрәк китсә, карабодай яхшы булыр.
Яшен күп булса, баланны кырау алыр.

### Еллар, ел фасыллары, айлар, көннәр буенча

Алтынчы гыйнварда салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр. Әгәр җылы булып, кар яуса, һәр ашлык уңар.
Әгәр ябалак кар яуса, борчак белән чикләвек уңар.
Апрель актыкларында җылы яңгырлар булса, игеннәр яхшы булыр.
Апрель алтысында аяз булса, җәй коры килер; болытлы булса, ашлык уңарга булыр.
Әгәр беренче мартта тәрәзәләргә боз катса, бу елны кыяр уңар.
Барс елы* — байлык, Тычкан елы* — баллык, Куй елы* — кытлык, Куян елы* — йотлык*.
Беренче гыйнварда көн җылы булса, арыш уңар; җил булса, тары уңар; томан булса, солы уңар.
Беренче мартта буран булса, карабодай уңар.
Беренче сентябрь көнне җил булса, киләсе ел ашлык начар булыр.
Декабрь. Егерме бишендә агачларны бәс тотса, алдагы җәй иген уңар.
Декабрьнең утыз берендә төнлә йолдызлар еш күренсә, ашлыклар уңар; шулай ук бәс булса да, ашлыклар уңар.
Егерме өченче апрельдә иртә белән чык күп төшсә, карабодай уңар.
Ел башы буласы төнне кичен һәр ашлыкның саламын кар астына куеп, бер атнадан алып кара: кайсы ашлыкның саламы бүрткән, озын булса — шуны күбрәк чәчәргә кирәк.
Искечә беренче сентябрьдә күк күкрәсә, киләсе ел ашлык уңар, ләкин көз озак килер.
Июнь өчесендә булса төшлектән җил — сабан ашлыгына килә ел.
Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.
Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.
Кыш сыкы булса, җәй алма була.
Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.
Май ае салкын булса — игенгә туклык.
Май алтысында булса чык — ул ел кыярга тук.
Майның яңгырлы булуы иген-печәнгә файда, җимешкә — зыян.
Март башы көн кояшлы булса, яшелчә уңа.
Мартның әүвәлге шимбәсендә кар яуса, чикләвек һәм карабодай уңар.
Марттагы кар бакча җимешенә бик ярар.

Ноябрь кар өрә — галәмгә ашлык китерә.
Тычкан һәм Елан елларында бал күп булыр.
Февраль икесендә иртә белән кар — ашлык иртә чәчкәне уңар; кич белән кар яуса — гаҗәп түгел соң чәчкәне уңса.
Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар.
Мартта кояш карны нык кыздырып эретә башласа, картлар: «Быел кар астына ут иртә керде, иген яхшы булыр»,— диләр.

### Үләннәр, куаклар, агачлар буенча

Августта кара әрем тамырының тармаклары юан булса, киләсе ел арыш яхшы булыр.
Борчакны суга салып кара: әгәр су өстендә вак күбекләр булса, быел борчак яхшы уңар.
Җәй көне миләш уңса, арыш яхшы булыр, шомырт уңса, арыш начар булыр.
Имән чикләвеге күп булган елны кыш җылы килә һәм алдагы җәй — туклык.
Каен агачында бөресе күп булса, тары бик уңар.
Карама агачында чәчәк булса, карабодай уңар.
Кузгалак көпшәсе юан булса, киндер бик уңар.
Кура җиләге дә, каен җиләге дә күп булса, киләсе елга арыш яхшы булыр.
Кура җиләгенең элек өлгергәне эре булса, ашлыкның иртә чәчкәне уңар.
Миләш уңган елны арышны күп чәчәргә кирәк: уңышы күп булачак.
Ногыт борчагы биек булса, киндер бик уңар, сабан ашлыгы да уңар.
Чикләвек агачында бөре күп булса, солы уңар.
Чыршы күркәләре башында булса, ашлыкны иртә чәч, әгәр дә төбендә булса — соң чәч.
Шомырт уңган елны ачлык булыр, алма уңган елны туклык булыр.
Яз көнендә урманда зәңгәр чәчәк күп булса, ашлыкны кырау алмас, карабодай бик уңар.
Яфрак җиргә капланып төшсә, иген булырга галәмәт.

### Хайваннар, кошлар, бөҗәкләр буенча

Әгәр бүреләр көзгәчә улый башласалар, киләсе ел ашлык булмас.
Әгәр карга ябыгып килсә, ашлык уңар.
Әгәр тавыкның беренче йомыркасы бер әчмуха* килсә, уңыш яхшы була.
Әтәчләр өзлексез кычкырсалар, ашлык уңар.
Бытбылдык кычкырган ел иген була; тартар кычкырса, иген булмый.
Кара каргалар ояга утырса, өч атнадан чәчүгә чыгарга кирәк.
Кәккүк яз көне агачлар яфрак яргач та кычкырса, ачлык булыр.
Көз чүмәлә төбендә тычканнар җыелса, икмәк кыйммәт булыр.
Күк күкрәүдән элек торна кычкырса, туклык булыр.
Кыр казлары яз көне биектән очсалар, сабан ашлыгы бик уңар, түбәнтен очсалар, ашлык гадәтчә булыр.
Кыр тычканнары күп булса, ашлык начар булыр, йорт тычканнары күп булса, ашлык яхшы булыр.
Кырмыска түмгәгенә таяк тыккач, кырмыскалар таяк башына кадәр менсәләр, җитен озын булыр.
Озынборыннар яздан ук югары болгансалар, солы бик уңар.
Сыерчык килгәндә чуар булса, карабодай уңар.
Сыерчыклар иртә килсә, сабан ашлык уңа, соң килсә — арыш уңа.
Сыерчыктан алда тургай килсә, туклык булыр.
Тавыклар оя басарга соң утырып иртә торсалар, ачлык булыр.
Тартай күп булса, печән күп булыр.
Торна кар барында килсә, тары, борчак уңар.
Үрдәкләр түбән очса, тары уңар.
Шомыртка көя төшмәсә, сабан ашлыгы начар була.
Яз көне балык тотканда алабуга белән юрша күбрәк тотылса, бодай, арпа, арыш, борай уңар.
Яз көне терлекләр башлап көтүгә чыкканда авызларына үлән яки тамыр кабып кайтсалар, терлекләргә ул җәй азык начар булыр.
IV БҮЛЕК

## Әзер җаваплар

Халык телендә теге яки бу сорауга каршы әйтелә торган **әзер җаваплар** бар. Мәсәлән, — *Ни эшли? — Тире җыеп, кун эшли*. Күренә ки, әзер җаваплар, сораулары белән бергә, шигъри калыпка салынган, ритмлы, рифмалы текстлар хасил итәләр һәм халык афоризмнарының үзенчәлекле бер төре булып саналалар.

Әзер җавапларны, кешеләр очрашып үзара хәл-әхвәл сорашкан чакларда, еш ишетергә туры килә. (*—Кая барасың? — Каен башына; — Нихәл? — Сине күргәч бетте хәл; — Бүген ялдамы әллә? — Ялда да, койрыкта да* һ. б.) Бу мисаллардан да ачык аңлашылганча, әзер җавапларның аеруча киң таралган вазифасы — куелган сорауның асылына җавап бирми калу, сүзне төп мәсьәләдән читкә алып китү. Моның сәбәпләре төрлечә булырга мөмкин: йә сорау үзе урынсыз, мәгънәсез була; йә җавап бирүченең серне чишәсе, чын хәлне белдерәсе килми. Әйтик, эшең бик уңышлы чыкмаганда берәрсе: «*Булдымы?*» — дигән сорау белән җаныңны борчый икән, аңа әзер җавап бар: «*Булды дигәндә койрыгын борды*».

Борынгы заманнарда сунарга яки башка кәсепкә чыгучылар үзләренең кая һәм ни өчен баруларын нык яшерә торган булганнар, чөнки урман, кыр, су ияләренең зыян салуларыннан курыкканнар. Ауланган киекләр саны да сер итеп тотылган. Юкса кул арты китә дип шомланганнар. Беренче «әзер җаваплар»га, күрәсең, әнә шундый җитди вазифалар йөкләнгән булгандыр. Тора-бара гына алар шаярту, күңел ачу өчен хезмәт итә башлаганнар.

Сөйләмдә әзер җаваплар куллану өчен нинди дә булса сорау бирелүе мәҗбүри түгел. Аларны төрле әңгәмә, бәхәс вакытларында да күп ишетәсең. Каршы якның урынсыз дәгъваларын, нигезсез дәлилләрен, юк-бар сылтауларын кире кагу, аларга исең китмәгәнне күрсәтү өчен әзер җавап шактый эффектлы чара булып тора. (*—Оят! — Өй-ат Мәкәрҗәдә* кыйбат, барып алырга ерак; — Ул сиңа үпкәләгән.— Үпкәләсә, үпкәсе бавырыннан ерак китмәс әле* һ. б.)

Әзер җавапларда рифма тудыру өчен **омонимнар** аеруча еш файдаланыла. Болар — язылышлары һәм әйтелешләре бердәй, әмма мәгънәләре бөтенләй башка булган сүзләр. Әйтик, **ач** — боерык фигыль (ишекне ач) һәм сыйфат (ач кеше). Элек, кызлар аулак өй уздырганда, егетләр ишеккә килеп сорыйлар икән:

— Ач!

Өй эченнән кызларның әзер җавабы ишетелә:

— Ач булсаң, туеп кил!..

Кайчакта сүзләрнең әйтелешендәге охшашлык якынча була. Аларны шартлы рәвештә сөйләм омонимнары дип атап булыр иде. Мәсәлән, **оялам** сүзен, бик тиз әйтелгәндә, **өй алам** дип ишетергә мөмкин. Берәр кеше нинди дә булса тәкъдимгә каршы «оялам» дип җавап кайтарса, тәкъдим ясаучыга шаяртып алу өчен менә дигән җай ачыла:

— Өй алырга монда өй сатучы юк әле!

Сөйләмдә нинди вазифа үтәп килүләренә карап, әзер җавап текстларын ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

Аларның бер ишеләре, инде әйтелгәнчә, куелган сорауның төп максатыннан читкә алып китәләр, сүз уйнату, җорлану шәбенә чын мәгълүматларны хәбәр итүдән котылып калалар. Икенчеләре җавап бирүчегә адресланган урынсыз шелтәләрне, гаеп ташлауларны кире кагарга ярдәм итәләр. Бу бүлектәге афоризмнар менә шушы ике төркемгә аерып урнаштырылды. Текстлар диалог формасында, ягъни һәм сорау, һәм җавап өлешләрен саклап бирeләләр.

## СОРАУНЫҢ АСЫЛЫННАН ЧИТКӘ КИТҮ

— Аңладыңмы?
— Аңлавын аңладым, төшенә генә алмадым.

— Ә мин нишлим?
— Ни теләсәң, шуны эшлә, тешең булса, телең тешлә.

— Белдеңме?
— Белдем, колагыма элдем, берсеннән керде, берсеннән чыгып китте.

— Булдымы?
— Булды дигәндә койрыгын борды.

— Бушлаймы?
— Бушлай сыер гына мышнай.

— Бүген ничәсе?
— Кадер кичәсе.*

— Бүген ялдамы әллә?
— Ялда да, койрыкта да.

— Дәлеше?*
— Дәлеше кабак бәлеше.

— Иеме?
— Ие, иемәсәң бие.

— Исәнме?
— Исән булмасам, әллә син врачмы?

— Исәнме?
— Ә үзең  кисәүме?

— Ишетмәдем, ни дисең?
— Базарда колак саталар, ди. Барып ал дим.

— Кайда?
— Былтыргы кар астында.

— Кайда?
— Каербидә.
— Кайдан килдең?
— Кайдырмый тау астыннан.

— Кайчан?
— Бозау агачка арты белән менгәндә.

— Кайчан?
— Карт алаша тай булганда.

— Кайчан?
— Качкан көнне иртән.

— Кайчан?
— Качып барганда.

— Кайчан?
— Кояш тискәре яктан чыкканда.

— Кайчан?
— Кызыл кар яугач.

— Кайчан?
— Дөянең койрыгы кайчан җиргә тияр, шунда.

— Кайчан?
— Язган булса яз көне, кушкан булса кыш көне.

— Кайчангача?
— Яз сорамаска, көз түләмәскә.

— Картаюлар ничек?
— Карт аю урманда гына була ул.

— Кая барасың?
— Каен башына.

— Кая барасың?
— Каерып салырга.

— Кая бардың?
— Кайманга — катык ашарга.

— Кая бардың?

— Эт туена кода булып бардым.

— Кем?
— Каян белим, кулын куеп китмәгән.

— Кем?
— Кем дигәннең кече улы.

— Кем?
— Кем дигәннең үзе, маңгаенда ике күзе.

— Кем малае син?
— Кемән улы Кемәнетдин малае.

— Кыйммәтме?
— Акча белән башма-баш.

— Мәгънәсе?
— Мәгънәсе — капка баганасы.

— Ни булган?
— Пешкән шалкан чи булган.

— Ни хак?
— Хак ярым хак, пот ярым борчак, бер кием чабата, калганы акчалата.

— Нигә карыйсың?
— Күңелемә ярыйсың.

— Ник?
— Син ни әйтер икән дип.

— Ник чәй эчмисең?
— Чәй белән кытай битен юа, ди.

— Нихәл?
— Сине күргәч, бетте хәл.

— Нихәл?
— Хәл иминлек, акча меңлек, алыштырырга вак юк.

— Нихәл?
— Хәл йөзгә җитә, кул тезгә җитә.

— Нихәл?
— Хәл хәер, ярлы баер, бай бөләр, иманасын кем түләр?

— Ни хәл?
— Шөкер дигән көн бар, бер салмалык он бар.

— Нихәл?
— Хәл хәлвәт, киндер күлмәк, ыштан бурлат, киткәннәр урлап.

— Нихәл?
— Юк шөкергә тук шөкер.

— Ничек эшләр?
— Эшләр — шак-шок итә тешләр.

— Нишли?
— Ат булып кешни, сыер булып мөгри.

— Нишли?
— Тире җыеп күн эшли.

— Нишлисең?
— Дуңгыз дагалыйм.
— Нишләп?
— Шулай шәп.

— Нишләп яту?
— Тик яту белән бик тату.

— Нәрсә?
— Тозлы кыяр-кәбестә.

— Оялмыйсыңмы?
— Өй алып, мунча сатканым юк.

— Саумысыз?
— Сау булмасак, әллә баш очыбызда ясин чыкмакчы* буласызмы?

— Сәбәбе?
— Сәбәбе — карабодай сәнәге.

— Сәгать ничә?
— Кичәгечә.

— Сиңа ничә яшь?
— Яшьне ат базарында гына сорыйлар.

— Сөенчесенә ни?
— Сөенчесенә уң колагың үзеңә.

— Сөйгәнең кем?
— Койрыклы җен, үземә әрәм, кешегә хәрам.

— Суны нигә күп ташыйсыз?
— Киптерәбез.

— Туйганыңны кайдан беләсең?
— Син күземә ике булып күренәсең.

— Үсәсезме?
— Үсәбез: тәбәнәк җиргә баш тия.

— Хәлләр ничек?
— Ал да гөл, калганын үзең бел.

— Хәлләр ничек?
— Алда гөл, артта кычыткан.

— Хәлләр ничек?
— Ат мөгезе кебек.

— Хәлләр ничек?
— Син сорама, мин әйтмим.

— Хәлләр ничек?
— Хәлләр бишни*, сезнеке нишли?
— Хәлләр ничек?
— Хәлләр изге, тегеләр генә бизде.

— Хәлләр ничек?
— Хәлләр имин, кешегә тимим.

— Хәлләр ничек?
— Шөкерле-бөкерле, һаман бер төрле.

— Чибәрме?
— Чибәр: күрсәң гайрәтең чигәр.

— Читтә ничек соң?
— Читнең чите корсын.

— Шулаймы?
— Шулаен ул шулай да, ярый ла эш барып торса уңайга.

— Шуннан?
— Шуннан утырган да шуган, тауга түбән булган.

— Эш хакы күпме?
— Айга утыз көн, йокы үзеңнән.

## УРЫНСЫЗ ТӘКЪДИМ, ҮПКӘ-ДӘГЪВАЛАРНЫ КИРЕ КАГУ

— Алып җибәр!
— Алырга акчаның күзенә ак төшкән әле.

— Арыдым.
— Арсаң ат ялла, үзең җәяү бар.

— Ач!
— Ач булсаң, туеп кил.

— Ачуым килә.
— Ачуың килсә, борыныңны тешлә.

— Ачуым килә.
— Синең ачуың, минем аякчуым*.

— Ашаган җиренә сыер да кайта.
— Кайтуын кайта да, аның сөтен савып калалар шул.

— Әү!
— Авызың дәү.

— Барыбер.
— Барыбер булса, ишектән йөрми тәрәзәдән йөрерләр иде.

— Беләм.
— Белүен беләсең дә, кыңгыр сибәсең.
— Беләм.
— Син белгәнне без белгән, калганын чөйгә элгән.

— Беләм.
— Син белгәнне мин чабата башына элгән.

— Беләм.
— Син белгәнне мин чормага меңгереп элгән.

— Беләм.
— Син белгәнне мин белеп оныткан.

— Беләм.
— Үзең беләсең, эт күк өрәсең.

— Буе кечкенә.
— Буй белән Агыйдел буйлыйсы юк әле.

— Бәхил түгел.
— Бәхилең бәке астына, үзең сәке астына.

— Гафу ит.
— Гафуың белән сату ит.

— Гыйшык.
— Гыйшыгын гыйшык та, бишмәт тишек.

— Егылам.
— Егылсаң, җирдән түбән китмәссең.

— Елый.
— Еласа, кашы-күзе кара булыр.

— Җүләр!
— Иманаңны кем түләр.

— Иренәм.
— Ирengәнне тиз иргә бирәләр.

— Иртә бит әле.
— Иртә булса, соң булмаска әйбәт булыр.

— Иртәгә.
— Иртәгә үз киявем дә килә.

— Ишетерләр.
— Ишетмәгәйләре тагын. Күз күрер өчен, колак ишетер өчен бирелгән.

— Кечкенә бит.
— Тиресен текмәгән, үсәр әле.

— Килешми.
— Килешкәне килендә.

— Килешми.
— Килешкәне килешкәч.
— Китә.
— Киткән китсен, җәһәннәмгә тикле юл ачык.

— Китәм.
— Китсәң, килгән юлыңа киртә кормаган.

— Китәм.
— Китсәң, килгән юлыңа юкә үсмәгән.

— Кулымны кисәргә бирәм.
— Кулыңны түгел, башыңны кистерсәң дә ышанмыйм.

— Куркам.
— Курыкма, бүре түгел — ашамас.

— Кызык.
— Бер табак сызык.

— Көнләшәм.
— Көнләшкән көндәшлеккә барсын.

— Күз тияр.
— Аңа ике күз тигән инде, бүтән күз тимәс.

— Мин синнән элек туган!
— Син элек тусаң, мин белеп туган.

— Мин үзем дә белекле.
— Белеклесен белекле дә, борын астың җелекле.

— Минем сүз өскә чыкты.
— Сүзең өскә чыкты: һавада очып йөри, үзең генә аста калдың.

— Озак!
— Тиз тумагансыңдыр әле.

— Озатыйм!
— Рәхмәт, үзем генә озаермын.

— Оялам.
— Өй алырга, монда өй сатучы юк әле.

— Оят!
— Өй ат булса, күптән җигеп китәр идек.

— Оят!
— Өй-ат Мәкәрҗәдә* кыйбат, барып алырга ерак.

— Сәлам!
— Саламыңа печән.

— Телең корыр!
— Минем телем болай да бик коры, селәгәем агып тормый.

— Тизрәк йөр!
— Оча белмим инде, аяк белән йөрим.
— Туйдым.
— Туйсаң тәүбә кыл.

— Уңган.
— Уңганның койрыгы туңган.

— Уф, алла!
— Арсаң ат ялла.

— Үпкәләгән.
— Үпкәләгәнгә үпкә ашаталар.

— Үпкәләгән.
— Үпкәләгәннең өенә барыш.

— Үпкәләгән.
— Үпкәләсә, мәче үпкәсе ашасын.

— Үпкәләгән.
— Үпкәләсә, үпкәсе бавырыннан ерак китмәс әле.

— Хуш!
— Сөйләшкәндә безне дә куш.

— Ышанмыйм.
— Ышанмасаң, үзең карган.

— Юк.
— Юкка мин үзем дә тук.

— Язык булыр.
— Язык казык башына.

— Язык!
— Язык казык башында, җырлап торчы каршымда.

— Ярамый.
— Ярамаган — дөньяга яралмаган.

— Ярамый.
— Ярамаса, юынырсың.

— Ярар!
— Ярасы юк, ярылган да, ямалган да.

— Яхшылык итмәкче була.
— Яхшылыгы — яхшы ат түгелдер әле, атланып чаба алмассың.
V БҮЛЕК

# Тапкырларга — табышмак

**Табышмак**, исеменнән үк аңлашылганча, тыңлаучылар алдына нинди дә булса билгесез бер әйберне яки күренешне эзләп табу бурычын куя. Жанрның тагын **йомак** (яки **җомак**) дигән атамасы да бар. Монысы нәрсәнедер яшерү мәгънәсендә кулланылган **йому** фигыленнән ясалган.

Төзелешләренә карап, табышмаклар үзләре берничә төргә бүленәләр. Аларның бер ишләре эзләп табылырга тиешле әйберне сурәтләп-тасвирлап бирә, сүзләр ярдәмендә аның рәсемен ясый. Шул рәсемдәге аерым билгеләр һәм сыйфатлар буенча без табышмакның җавабын эзләп табабыз.

«*Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай*» дигән табышмакны тикшереп карыйк. Аның җавабы нәрсә

булырга мөмкин? Иң элек беренче сыйфатка — билгесез әйбернең шар кебек йомры булуына игътибар итик. Андый әйберләр байтак: кабак, миләш, шалкан һ. б. Ләкин «кабак» дигән җавап табышмакта күрсәтелгән икенче сыйфатка туры килми. Чөнки аның эче кызыл түгел, ә сары. Миләш йомры да, кызыл да, әмма ул өченче сыйфатка җавап бирми. Безгә эче түгел, бәлки татлы әйбер кирәк. Шушы рәвешчә фикер йөртеп, дөрес җавапның «карбыз» икәнлегенә төшенү кыен түгел.

Табышмакларда әйберне тасвирлап күрсәтү өчен күп кенә сурәтләү чаралары файдаланыла. Алар арасында аеруча еш кулланылганы — **метафора**. Бу үзе грекча сүз, «күчерү» дигән мәгънәне белдерә. Метафора булып килгән сүзне һәрвакыт күчерелмә мәгънәдә аңларга кирәк. «*Башы тарак, койрыгы урак*» дигән табышмакта әтәч турында «койрыгы урак» дибез икән, бу — кемдер аның койрыгын кисеп алган да, шуның урынына урак бәйләп куйган дигән сүз түгел.

Инде сорау туа: сүзне болай күчерелмә мәгънәдә куллану, ягъни аңардан метафора ясау өчен нинди шарт кирәк? Төп шарт — ике әйбер арасында охшашлык булырга тиеш. Әтәч койрыгы һәм урак, кикрик һәм тарак — тышкы формалары белән бер-берләренә нык охшыйлар. Йозак белән эт арасындагы охшашлык — алар икесе дә өй саклыйлар. Шуңа таянып, табышмак «эт» сүзен «йозак» дигән күчерелмә мәгънәдә кулланa: «*Кечкенә генә эт, өрми дә, җибәрми дә*» (йозак).

Метафоралардан тыш, табышмакларда **чагыштырулар** да еш очрый. Алдарак тикшерелгән мисалда без карбызның формасы белән шарга, төсе белән канга, тәме белән балга чагыштырылуын күреп узган идек.

Кайчакта табышмакта эзләнелә торган әйбернең материалы, ягъни аның нәрсәдән ясалган булуы телгә алына. «*Тимергә каен үскән*», монда тимер — балтаны, каен аның сабын аңлата.

«*Ары лап-лап, бире лап-лап, сөңге саплап, киез каплап*» дигән табышмак элекке заманда чабагач белән ашлык сугу процессын сурәтли. Картинаны күз алдына ачыграк китерү өчен, авыз ияртемнәре файдаланылган. *Лап-лап* — чабагач белән сукканда чыга торган аваз.

Алдарак әйткәнебезчә, хәзер карап узылган мисалларның барысы да безнең күз алдына әйбернең сурәтен, рәсемен китереп бастыра. Шуңа күрә мондый табышмакларны **сурәтле табышмаклар** дип атап булыр иде. Болардан тыш, әле тагын **сорау-табышмаклар** һәм **арифметик табышмаклар** да була.

Сорау-табышмакка дөрес җавап табу өчен, анда куелган сорауның хәйләсен, четерекле ягын сизеп алырга кирәк.

«*Шалканны кайчан чәчәләр?*» дигән табышмакка кайбер балалар «яз көне», «көз көне», «җир кипкәч» кебек җаваплар бирәләр. Бу табышмакка исә дөрес җавап мондый: «Шалканны беркайчан да чәчмиләр, аның орлыгы гына чәчелә». Әгәр сабын һәм су белән бик үк дус булмаган берәр малайга: «Колагың шалкан чәчәрлек булган»,— дибез икән, монда да шалкан үзе түгел, бәлки аның орлыгы гына күздә тотыла. Юкса шалкан малайның колагына ничек сыйсын, ди?

Димәк, мондый мисалларда «шалкан» сүзе икенчел («орлык» дигән) мәгънәдә кулланыла. Ә менә табышмак әйтүче кеше үзенең соравында «шалкан»ның беренче, төп мәгънәсен күздә тоткан икән. Әгәр ул: «Шалканны чәчәләрме?» — дип сораса, без әле аның тел төбенә җиңелрәк төшенер идек. Ләкин сорау «Кайчан чәчәләр?» дип куела. Безнең бөтен игътибарыбыз шушы «кайчан»га юнәлә. Мондый сорау алмашлыклары җавап эзләүчене саташтыру, «эздән яздыру» өчен кертелә.

Сорау-табышмаклар кебек үк арифметик табышмаклар да еш кына хәйләгә корылган булалар. Мәсәлән, мондый табышмакны алыйк: «*Бер ботакта 12 карга утыра иде. Аучы шуларның икесен мылтыктан атып төшерде. Ботакта ничә карга калды?*»

Сезнең кайберләрегез, озак уйлап тормыйча: «Ун»,— дип җавап бирәчәк. Һәм бу, билгеле, дөрес түгел. Ботакта бер карга да калмый. Икесе җиргә егылып төшә, калганнары куркып очып китәләр. Мондый чакта коры арифметик гамәлләр белән мавыкмаска, ә табышмакның шартын күз алдына китереп, бераз зиһенне эшләтергә кирәк була.

Югарыда санап үтелгән төрләрдән тыш, табышмакларның тагын **мәзәк** һәм **әкият** формасында иҗат ителгәннәре дә була. Табышмаклар рәтенә гадәттә **шарадалар** һәм **метаграммаларны** да кертәләр. Шарада нинди дә булса сүзнең иҗекләре аңлаткан мәгънәләрне әйтеп, шул сүзнең үзен табуны сорый. Мәсәлән, «Беренче кисәге — сыеклык, икенче кисәге — Татарстандагы елга, кушып укысаң — табигать күренеше». Җавап: суык (су + Ык). Метаграммада исә билгесез сүзнең хәрефләре алмаштырып барыла һәм шуның нәтиҗәсендә мәгънәнең ничек үзгәрүе әйтелә:

Күл буенда шаулармын,
«Ш» белән мине язсаң.
Ат муенында булырмын,
«Т» белән алыштырсаң.

Җавабы — *камыш* һәм *камыт*. Мондый төр табышмакларны күбесенчә шагыйрьләр һәм укучы балалар үзләре иҗат итә.

Табышмак — халык иҗатының бик борынгы жанры. Аның килеп чыгуын фольклорчы галимнәр

элекке замандагы яшерен тел күренеше белән бәйләп аңлаталар.

Борынгы кешеләр табигать дөньясын җанлы итеп күз алдына китергәннәр. Аларның ышануынча урман-кырларда, елга-күлләрдә ниндидер акыллы затлар яшәгән. Болар, янәсе, кешеләргә төрлечә зыян кылып торганнар. Менә шул «дошман көчләрне» алдау, алардан чын ниятләрен яшерү өчен, кешеләр «үзләре генә белә торган» яшерен телдән файдаланганнар. Борынгы аучы, хайваннарны да кеше сөйләмен аңлый, дип уйлаган. Шуңа күрә ауга чыгар алдыннан хайваннарны һәм коралларны үз исемнәре белән атау тыелган. Имештер, хайваннар ишетәләр дә, куркыныч килгәнне сизеп, качып китәләр икән. Ә инде аларны башка төрле **алмаш исемнәр** белән атасаң, мондый хәл булмый һәм ау уңышлы чыга икән. Мәсәлән, куянның — «*озын колак*», «*кыр тәкәсе*», «*чал тәкә*», аюның «*көрән*», «*бабай*», еланның «*майлы каеш*», «*җиз камчы*» кебек алмаш исемнәре халык телендә бүгенгәчә сакланып калган.

Яшерен тел һәм табышмак жанры өчен уртак нәрсә шул: алар икесе дә әйберне үз исеме белән атамыйча, аны башка исем белән алмаштыралар. Кайчакта бу алмаш исемнәр аларның һәр икесе өчен дә бер үк булып чыга. Мисал өчен куян турындагы «*Чал тәкәдә мөгез юк*», елан турындагы «*Юл өстендә майлы каеш*» дигән табышмакларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Борынгы заманнарда табышмак үзе дә, яшерен тел кебек үк, сихер-тылсым, табигатьтәге «ияләрне» буйсындыру, юашландыру чарасы булып хезмәт иткәндер дип уйлыйлар.

Хезмәт процессында кешенең тормыш серләренә торган саен тирәнрәк төшенүе, табигать көчләрен инде хыялда түгел, ә чын-чынлап буйсындырырга өйрәнүе нәтиҗәсендә, борынгы ышануларның җирлеге югала. Яшерен тел һәм аның белән бәйләнгән табышмакларның баштагы тылсымчылык роле акрынлап юкка чыга. Табышмак сүз сәнгатенең үзенчәлекле бер төре буларак үсеп китә. Халык аңа күңел ачу, юаныч чарасы итеп карый башлый.

Табышмак — үзенең төп асылы белән шигъри әсәр. Дөрес, аның чәчмә формадагы үрнәкләре дә бар. Ләкин алар күп түгел. Өстәп шуны да әйтергә кирәк: хәтта бер генә юлдан торучы текстларның да күбесендә шигырьгә хас сыйфатларны табарга мөмкин. Мәсәлән, «*Бер көзгедә ун өлге*» (тәрәзә), «*Бер үгезгә өч мөгез*» (сәнәк).

Фольклор жанрлары бер-берләреннән формалары ягыннан гына түгел, эчтәлекләре буенча да аерылып торалар. Әйтик, әкиятләр безне хыял-фантазия дөньясына алып китәләр. Бәетләрдә исә тормышта булып узган билгеле вакыйгалар турында сөйләнелә. Җырлар кешенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын белдерәләр. Табышмакка килсәк, ул тормыштагы конкрет әйберләрне һәм күренешләрне сурәтли. Әйтик, тактадагы ботак эзен яки идән себеркесен, энә белән җепне яки сыер мөгезләрен махсус рәвештә тасвирлауны башка бер генә жанр да максат итеп куймый.
Ә табышмак аларның гаҗәп тапкыр шигъри сурәтләрен тудыра: «*Өй башында дранча, дранча саен бер акча*», «*Ишекле-түрле яшь килен йөри*», «*Башы корыч, койрыгы җитен*», «*Кәкре агачта кар тормас*».

Табышмак чишкәндә бер кагыйдә бар: әгәр җавап эзләүче сүзнең нәрсә хакында баруын абайлый алмаса, ул: «*Җирдәме, күктәме?*», «*Җанлымы, җансызмы?*» кебек юнәлткеч сораулар бирә ала. Бу һич тә очраклы хәл түгел, чөнки табышмакларда җирдәге һәм күктәге барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләр сурәтләнеш тапкан. Моның шулай икәнлеген сез бу китаптагы табышмакларның тематик төркемнәре буенча да ачык күрә аласыз.

## КҮК ҖИСЕМНӘРЕ; ҖИР, СУ, КАЗЫЛМАЛАР; ЕЛ ТӘҮЛЕГЕ, ТАБИГАТЬ КҮРЕНЕШЛӘРЕ

### Күк

Терәмәгән, нитмәгән,
Басып тора — китмәгән.

Зәңгәр ашъяулык
бөтен дөньяны каплаган.

### Күк һәм ай

Төпсез дәрьяларда
бер алтын көймә йөзә.

Зур палас,
Төбендә йомры калач.

**Күк һәм йолдызлар**

Күк keләмгә
төн йокламый энҗе сиптем.

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Такта өстенә тезелдек,
Таң атканчы юк булдык.

**Күк, йолдызлар, ай**

Болын тулы сарыкка
тик бер генә көтүче.

Мич тулы пәрәмәч,
Уртасында бер калач.

**Күк, кояш, ай, йолдызлар**

Кирәгәсез* күк тирмәнең*
Төнлегендә* ике ак таш,
Киезендә мең-мең вак таш.

**Күк һәм болыт**

Зәңгәр диңгездә аккошлар йөзә.

**Кояш**

Ул булса, көн була,
Ул булмаса, кем була?

Тау башында
алтын тәңкә ялтырый.

**Кояш нуры**

Тәрәзә аша алтын таяк керә.

Тәрәзәдән сыя,
Ишектән сыймый,
Сандыкка сыя,
Салып бикләп булмый.

Алтын кылыч җиргә төште,—
Тавышын беркем ишетмәде.

**Кояш чыгу, таң ату**

Ак сандыгым ачылды,
Эченнән ефәк чәчелде.

**Кояш чыгу, ай бату,
этәч кычкыру,
кешеләр йокыдан тору**

Алтын капка ачыла,
Көмеш капка ябыла,

Мәрди бабай кычкыра,
Үлгән кешеләр терелә.

**Көн һәм төн**

Ике туган:
Берсе ак булган,
Берсе кара булган.

Кара сыер килде,—
Бөтен дөньяны җиңде;
Ак сыер килде,—
Бөтенесен дә күтәрде.

**Күләгә**

Кояшлы көндә артыңнан
калмый,
Болытлы көндә
эзләп тә табып булмый.

Иртә белән абый,
Төш турында энем,
Кичкә таба агай.

**Кояш һәм ай**

Апасы энесенә кунакка бара,
Энесе апасыннан кача.

Алтын китте,
Көмеш килде.

**Ай**

Агач башында алтын йөзек,
Аның да бер яртысы өзек.

Өй түбәсендә ярты ипи.

**Кояш, ай, йолдызлар**

Бер атасы, бер анасы,
Ничә йөз мең баласы.

**Ай һәм йолдызлар**

Бер көтүче мең сарык көтә.

Өй түбәсендә вак таш,
Алар янында бер зур баш.

**Йолдызлар**

Вак кынадыр үзләре,
Ялтырыйдыр күзләре.

Төнлә баксам — күк тулган,
Иртән баксам — юк булган.

Өй башына тары сиптем.

**Көянтә йолдыз**

Биш кыз бер көянтә
күтәргән,—
Төн буена су ташый.

**Җидегән йолдыз**

Өй башында саплы чүмеч.

**Тимер казык, акбүзат, күкбүзат йолдызлары**

Казыкка бәйләнгән ике атым
дулый,
Дуласа да бер тирәдән китә
алмый.

**Йолдыз атылу**

Тау аркылы ук аттым,
Аткан угым югалттым.

**Җир**

Ята торган ястыгым,
Шунда тарым, ясмыгым.

**Җир, су, ут**

Эчә дә эчә — бер дә канмый*,
Йөгерә дә йөгерә — бер дә
армый,
Ашый да ашый — бер дә
туймый.

**Чокыр казу**

Миннән ни чаклы алсалар,
Шулкадәр зурая барам.

**Тау һәм юл**

Олы казанны күтәреп булмый,
Озын бауны җыеп булмый.

**Туфрак**

Өй артында дарым бар,
Күтәрә алсаң, барын да ал.

**Ком**

Саз төбендә сары энҗе.

**Ташкүмер**

Кодыкка* төштем, таш

чыгардым,—
Таш дигәнем ут булды.

**Нефть**

Коем төбе — кара май.

**Су**

Булмаган җире сирәк,
Үзе һәрвакыт кирәк.

Илле грамм герне күтәралмый,
өстендә меңәр тонна йөкләр
йөртә.

**Су, җил, таш**

Нәрсә йөгерә аяксыз?
Нәрчә оча канатсыз?
Нәрсә үсә тамырсыз?

**Су өсте**

Җир иңгән җирдә шома
пыяла.

Ярты ел ат белән йөриләр,
ярты ел йөзәләр.

**Чишмә**

Таудан туа, диңгезгә куа.

**Елга**

Үзе чаба да чаба,
койрыгы күренми.

Кыш буена тик тора,
Яз җиттеме — котыра.

**Елга һәм аның ярлары**

Аты бара, тәртәсе кала.

**Елга, ут, җир, җил**

Бу дөньяда бар дүрт агай:
Берсе һаман йөгерә, бер дә
армый,
Икенчесе гел ашый, бер дә
туймый,
Өченчесе гел эчә, бер дә
канмый,
Дүртенчесе гел көйли,
Тавышы бер дә килми.

**Күл**

Тустак* тулы су,
Суның өсте бу*.

**Елның дүрт фасылы**

Бер картның унике улы бар:
Өчесе сары көпе* кия,
Өчесе яшел күлмәк кия,
Өчесе сары чикмән кия,
Өчесе ак тун кия.

**Кыш килү**

Бабай килгән сагынып,
Ак чикмәнен ябынып.

Кара сыерым ятып калды,
Ак киезем ябып калды.

**Кыш үтеп, яз килүе**

Ак сыер: «Торып китик»,—
ди,
Кара сыер: «Ятып торыйк»,—
ди.

Ак юрганымны алып куйдым,
Яшел юрганымны җәеп
куйдым.

**Яз айлары**

Кара мыеклы җизнәм
Сагынып-сагынып килгән.

**Җәй**

Кигән киеменең бизәге
Бөтен дөньяны ямьгә бизәде.

**Көз**

Үзе тук кебек,
Кайгысы юк кебек,
Җылый башласа — туктамый.

**Ел, айлар, атналар,
тәүлекләр**

Бер күркә, унике аккош,
Кырык сигез ана каз,
Өч йөз алтмыш биш бала каз.

**Ел, тәүлекләр, көн, төн**

Дөньяда бер агач бар:
өч йөз алтмыш алты яфрагы бар: бер ягы ак, бер ягы кара.

**Атналар, айлар, бәйрәмнәр**

Дыгыр-дыгыр дыгырчык,
Кырык сигез тыгырчык,
Унике каз, ике аккош,—
Аны тапкан тутый кош.

**Ел, айлар, айдагы тәүлекләр, төн, көн**

Өянке, өянке,
Ботак саны унике,
Һәр ботакның җиде яфрагы,
Кара булыр бер ягы,
Ак булыр бер ягы.

Бер авылда унике өй,
Һәр өйдә утыз кыз,
Һәр кызның бер бите ак, бер
бите кара.

**Ел, айлар, айдагы атналар, атнадагы тәүлекләр, көн, төн**

Бер тирәк,
Унике ботак,
Һәр ботакка дүрт чыпчык,
Һәр чыпчыкка җиде яфрак,
Һәр яфракның бер ягы кара,
Бер ягы ак.

**Ел, унике ай**

Унике йолдызга бер ай.

**Ай, тәүлекләр**

Унике чүлмәк,
Чүлмәк саен утыз йөзем,
Утыз йөземгә бер исем.

**Атна һәм тәүлекләр**

Бер ояда — җиде күкәй.

**Сәгать һәм минутлар**

Бер тавык астында алтмыш
йомырка.

**Һава**

Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел.

**Яңгырау, кайтаваз**

Тәнсез тора,
Телсез сөйләшә,
Һичкем аны күрми,
Һәркем аны ишетә.

Кем барлык телләрдә дә
сөйли ала?

**Җил-давыл**

Кулсыз-аяксыз тәрәзәне кага,
Тавышсыз җырлый,
Өйгә керергә сорый.

Үзе аяксыз-кулсыз,
Үзе агач сындыра.

Иртә килә, чиртә килә,
Ике канатын сирпә килә,
Камышлыктан үтә килә,
Камыш башын селкә килә.

Өй түбәсендә бүре улый.

**Томан**

Уты юк, төтене бар.

Ак чыбылдык эчендә
Айны ничек табаем?
Күк чыбылдык эчендә
Көнне ничек табаем?

**Судан пар күтәрелү**

Күк тана койрыгы белән су
эчә.

**Чык яки кырау**

Хан кызы мәчеткә барды,
Әчкече төшеп калды;
Төшеп калган әчкечне
Ай күреп, кояш алды.

**Чык һәм чалгы**

Җем-җем иткән нидер ул?
Ялмап алган нидер ул?
Биле бөкре нидер ул?
Яуны кырган нидер ул?

**Болыт**

Аягы юк — ил гизә,
Күзе юк — яшь түгә.

Онгыл-чонгыл манара,
Кат-кат булып кабара,
Суы барда карала,
Суы бетсә тазара.

Зәңгәр күктә бөркет оча,—

Канаты белән кояшны
каплый.

**Яңгырсыз болыт**

Сыерымның җилене тулган,
сөте юк.

**Болыт, яңгыр**

Түбә аркылы казлар үтте,
Бөтен җирне сазлар итте.

Кара төенем чишелде,
Эченнән җәүһәр чәчелде.

**Яңгыр**

Җәйге эссе көннәрдә
Мине сагынып көтәләр,
Мин аз гына күренсәм,
Качып-посып бетәләр.

Иләк белән су ташыйлар.

**Яңгыр, җир, үлән**

Берсе чәчә,
Берсе эчә,
Берсе үсә.

**Боз яву**

Юл тулы борчак чәчелде,
җыючы юк.

**Тамчы**

Борынсыз чыпчык боз тишә.

Өй артында дөп-дөп кое
казый.

Өй артында дөп-дөп тары
төяләр.

Өй артында тәңкә сикерә.

**Яшен**

Урал таудан кылыч орсам
Иделдә чабагым уйный.

Ялан җирдә ялт та йолт.

Тәрәзәне елык итте,

Йөрәгем чырык итте.

Ялт итәр дә йолт итәр,
Тигән җирен ут итәр.

**Күк күкрәү, яшен, яңгыр**

Ала казы калтыр-колтыр,
Канат очы ялтыр-йолтыр;
Инәсе* елый вәр-вәри,
Кызы көлә шар-шарый.

**Күк күкрәү, яшен**

Атасы чарык* әйләндерә,
Угылы пычагын яный.

Падишаның күркәләре
Галдыр-галдыр итәдер;
Муенындагы мәрҗәннәре
Ялтыр-йолтыр итәдер.

Болгаерда ялт итте,
Килдуразда шалт итте,
Борындыкта кисмәк ярылды.

**Яшен яшьнәү, яңгыр яву**

Ялт-йолт ялтырый,
Җирнең өсте калтырый,
Энҗе кебек тезелә,
Ефәк кебек сузыла.

**Аҗаган**

Селки арыш камчысы,
Алтын нурлар тамчысы.

Ялман ялап ала,
Ялаган җире янмый кала.

**Салават күпере**

Идел аркылы алтын дуга
ташладым.

Сыр-сыр сыры бар,
Алты төрле нуры бар,
Җиде кат күккә юлы бар.

Шундый матур бер күпер —
Кеше йөрми, ат керми.

**Суык**

Ишектән керер,
Түреңә менеп утырыр.

Байны кочаклый,
Ярлының куенына керә.

**Елгада боз кату**

Килделәр агайлар балтасыз,
Ясадылар күпер тактасыз.

Акты-акты да тәрәзә астына
ятты.

**Бәке**

Төнлә тәрәзәсе бикләнә,
Көндез ачыла.

Сыр-сыр сыргалак,
Уртасында бер табак.

**Боз китү, елга ачылу**

Аккошым очып китте,
Кара төлке ятып калды.

**Боз**

Кышын ята таштай,
Язын чаба аттай.

Утта янмый,
Суда батмый.

**Тәрәзә бозы**

Әндри күзен ак алган.

Аягы юк, кулы юк,
Тәрәзәгә гөл ясый.

**Кәрнизгә каткан боз**

Үзе туңа, үзе керми,
Үзе елый да елый.

Өй артында ак тана
Мөгезем бар дип мактана.

**Кар**

Ак ябалак ак киезгә ятыр.

Мамык юрган,
Кат-кат сырган,
Үзе суп-суык.

Кара җирнең өстенә
Каз мамыгын кем түккән?

Ак юрганын кем теккән?
Ап-ак онны кем сипкән?

Ак ашъяулык таптык,
Җир өстенә яптык.

Урамда — батыр,
Өйдә — җылак.

**Кар җемелдеге**

Менә ята җәүһәр таш,
Алыйм дисәң, юк була.

**Кар яву**

Яшь килен суга бара,
Тәңкәләре коелып кала.

**Буран, өермә**

Йон түшәгем ертылды,
Бөтен дөнья йон булды.

Аю бабай йон тетә,
Балакларын селкетә.

Котыра да үкерә,
Бөтен җирне тутыра.

## АГАЧЛАР, ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР, УРМАН ЭШЕ, ҮСЕМЛЕКЛӘР, ПЕЧӘН ЭШЕ; ИГЕНЧЕЛЕК, ЯШЕЛЧӘЛӘР

**Агач**

Җаны булмаса да гомер итә.

Җәй тун кия, кыш ялангач.

Язын ямь бирә,
Җәй салкын бирә.
Көзен тәм бирә,
Кышын тун бирә.

**Агач тамырлары**

Ай үсә, ел үсә,
Үзе күзгә күренми.

**Агач кайрысы**

Яфрак та түгел,
Ботак та түгел,
Үзе агачта үсә.

**Агач үзәге**

Айга да, кояшка да күренми,
Агач белән бертигез.

Көн үсә, төн үсә,
Агач белән тиң үсә.

**Яфрак**

Аяксыз, кулсыз,
Үзе агачтан сикереп төшә.

**Каен**

Ак киемен кигән,
Яшел чугын элгән.

**Усак**

Нинди агач җилсез шаулый?

Анасы тулгана,
Балалары кул чаба.

**Зирек**

Терт итә дә мерт итә,
Суга карап көн итә.

**Имән һәм аның чикләвеге**

Бер сарай бар — бүрәнәсе
имән,
Башы күккә тигән.
Илдар ханның балалары
Бар да алтын такыя кигән.

**Чыршы яки нарат**

Җәй дә, кыш та, яз да, көз дә
Чәчәк ата бер төстә.

Җәй дә егет, кыш та егет,
Картайганы юк, гел егет.

Күп инәле, сукыр күзле.

**Чикләвек**

Бәләкәй генә чүлмәгем,
Тәмле булды чумарым.

Кечкенә генә таш сандык,
Сандык эченә мал салдык.
Ачкычын табалмагач,
Капкачын ватып алдык.

Никадәр күбрәк ашасам,
шулкадәр өстәлдә күбрәк
кала.

**Яңак чикләвеге һәм өрек**

Бер бик тәмле нәрсә күрдем
Сөягенең эчендә,
Бер бик тәмле нәрсә күрдем
Сөягенең тышында.

**Өрек**

Тышы татлы ит,
Эче каты таш.
Ташның эчендә
Тагы тәмле аш.

**Шомырт**

Иелә, бөгелә,
Ак мамыгы түгелә,
Кара күзе күренә.

Урманда кара төймәм эленеп
тора.

**Миләш**

Чөйдә кызыл читлек.

Кызыл төймәсен аскан,
Каршыма килеп баскан.

**Балан**

Кара урман уртасында
Кызыл әтәч утыра;
Кагына да сугына,
Канатыннан кан тама.

Урманда куашнам* ачый.

**Гөлҗимеш**

Ал яулыклар ябынган,
Ал кыналар ягынган;
Кулым сузсам тешләп алды,
Шул кадәрле сагынган.

**Карлыган**

Кара гына, кечкенә генә
бүрекле,
Үзе бөтен дөньяга күрекле.

**Кура җиләге**

Кызыл бүкәй, ак чүкәй.

Озын курай үләндер,
Кызыл алка элгәндер.

**Җир җиләге**

Әкәм-чекәм башында
Кызыл тургай утыра,
Бүген килеп алмасагыз,
Китәм диеп утыра.

Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.

**Чия**

Түгәрәк-түгәрәк шар кебек,
Кызыл-кызыл кан кебек;
Әчедер дә татлыдыр,
Йотыйм дисәң ташлыдыр.

**Алма**

Алсу битле кыз үсте,
«Тып» итеп агачтан сикереп
төште.

Бакчадагы асыл кош
Төшәм диеп тилмерә.

**Урман кисү, балта**

Бәләкәй генә малай
Урман төбен ялай.

**Билгә кыстырылган балта**

Урманга барганда, өйгә карый,
Өйгә кайтканда, урманга карый.

**Пычкы, агач кисү, такта яру**

Тиз ашый, вак чәйни,
Үзе йотмый, башкага бирми.

Ике алаша
Читән аша талаша.

**Борау**

Кәкре-бөкре төз киткән.

**Өтерге**

Күк тәкәмне көн дә берәү
түбәли.

**Дегет кайнату**

Урманда аю үтердем,
Өйгә канын китердем.

**Гөлләр**

Яшел-яшел пәриләр
Тәрәзәдән карыйлар.

**Чәчкә**

Патша түгелмен — таҗым бар,
Кешеләргә бирер назым бар.

**Кычыткан**

Кыйнамый, сукмый, үзе
җылата.

Күмер түгел, ут түгел,
Тотсаң, кулны пешерә.

Бер үлән бар чокырда,
Аны таный сукыр да.

**Билчән**

Энәләрен тоткан,
Юл буена чыккан.

**Тигәнәк-кырмавык**

Бер йомгакта мең энә.

Җиз мыеклы җизнән,
Чәнчелмичә түзмәм.

Кечкенә генә черәшкән
Тырнашкан да тешләшкән.

Юл буенда тиле:
Тигәнгә дә тия,
Тимәгәнгә дә тия.

**Кылган**

Иелдем, үрелдем,
Әби чәчен мин үрдем.

**Андыз**

Аю колак, алтын баш,
Тамыры зәхмәттән аш.

**Аю көпшәсе**

Аягы алыптай,
Гәүдәсе таяктай.

**Курай**

Кырда үскән бер бала
Өйгә килеп моңлана.

**Камыш**

Яшел бабайның сакалы
су өстендә җилферди.

Торалар күл каршында,
Койрыклары башында.

**Төнбоек**

Кечкенә үзе,
Ташаяк күзле.

Су өстендә сары май.

**Колмак**

Озын чылбыр чуалган,
Чыпчык шуңа уралган.

Кулсыз-аяксыз,
Арты белән агачка менә.

Исерткеч аш, чалмалы баш.

**Гөмбә**

Кырда да, урманда да
Кызыл бүрек кигән бер карт
утыра.

Олысы да, кечесе дә эшләпә
кигән.

Багана башында ак калач.

**Чалгы, печән чабу**

Аягы йөрми, таягы йөри.

Үзе тешсез,
Тормый эшсез.

Үлән ашый — теше тупара*.
Таш чәйни — теше үткенәя.

Ялт-йолт итә,
Ястык ташлап китә.

**Чалгы, чүмәлә, кибән**

Ялтырый елан,
Утыра Имам,
Иң олысы — Әмирхан.

**Печән пакусы, күбә, чүмәлә**

Ятса — елан күк,
Утырса — олан күк,
Басса — болан күк.

**Чүмәлә белән кибән**

Инәсеннән элек баласы туар.

**Сәнәк**

Авызы юк, үзе печән ашый.

Авызы юк, теле юк,
Үзенең өч теше бар,
Кеше белән эше бар.

**Басу-ызан**

Озак, озак,
Юлга тозак.

**Тирес-ашлама**

Кыш көне өелә,
Җәй көне җәелә.

**Сука**

Сарык көтүгә бара,
Мөгезләре өйгә бага.

**Төрән**

Җир астында ай йөри.

**Сабан сөрү**

Тимер казым җир ерта.

Әнә бара, юлны яра,
Сукмагы кара.

**Җир тырмасы**

Кырга сыяр, урманга сыймас.

Аягы әллә ничә булса да,
Кырдан аркасы өстенә ятып
кайта.

**Тырмалау**

Кап-кара җир уртасында
Кырык аяклы сыер йөри.

**Трактор**

Тимер ат җир сөрә,
Ашарга сорамый.

Ат түгел, кешнәми,
Йөз аттан ким эшләми;
Үзе йөри тыр да тыр,
Йә, бу нәрсә, кем әйтер?

**Чәчү, орлыкның тишелүе**

Баз астында ятып бала тудыра.

**Чәчү, уру, амбардагы ашлык**

Яз көне җәйгән җәймәмне
Көзгә җыеп алдылар;
Бер келәткә салдылар,
Караңгыга яптылар.

**Кукуруз**

Озын-озын егетләр,
Башларында бүрекләр.

**Бодай**
Ук,
Башы алтын чук.

**Бодай орлыгы**

Кайнегәчемнең карыны ярык.

**Арыш уҗымы**

Кар астында кышлаган,
Бүреген яшел тышлаган.

Җәй дә яши, кыш та яши,
Яшел бәрхет тун тышлый.

Кыш кышлар,
Җәй җәйләр,
Тоягыннан су эчәр,
Мөгезеннән бәбиләр.

**Тары**

Башы утта, аягы суда.

Кечкенә генә капчык,
Эчендә сары балчык.

**Карабодай**

Аягында кара ката,
Тәпиендә кызыл оек,
Яшел күлмәкле, ак яулыклы.

**Карабодай орлыгы**

Өч почмаклы келәтем,
Өч почмаклы келәтемдә
Ак күлмәкле бикәчем.

**Карабодай, арыш**

Ак яулыклы җиңгәм,
Җиз мыеклы җизнәм.

**Солы**

Кырда бер алачык,
Алачык эчендә капчык,
Капчык эчендә карчык.

Уклау, чуклау,
Тәңкәле бай хатыны.

**Солы орлыгы**

Бара идем, атым арыды,
Камчым ордым — бармады,
Тамагына
Җиз кадак кактым — барды.

**Борчак**

Агач,
Агач саен ботак,
Ботак саен оя,
Оя саен күкәй —
Сигезәр дә тугызар.

Усак,
Усак башында ботак,
Ботак башында сабак,
Сабак башында ал-кызыл,
Зәңгәр чәчәк ата.

**Борчак кузагы**

Яшел болын,
Уртасында дүрт колын.

Кулга алсаң, елтырый,
Шарчыклары чылтырый.

**Җитен**

Озын буйлы,
Зәңгәр күзле.

Башын ашыйлар,
Тәнен ташлыйлар,
Тиресен кияләр.

**Киндер**

Төбе тамыр,
Уртасы сеңер,
Башы майлы,
Ашарга җайлы.

**Мамык**

Күтәреп була,
Ыргытып булмый.

**Көнбагыш**

Ай башлы,
Яшел кашлы,
Сары ефәк калфаклы,—
Борыла да кояшка карый.

Бабай мескен картайган,
Эшләпәсе янтайган.

Агач,
Агач саен табак,
Табак саен кибет,
Кибет саен күлмәкле егет

Бер анага мең бала,
Аларның да күлмәге кара,
Юсаң да агармый — шунысы
бәла.

**Иген кыры**

Диңгез түгел — дулкынлана.

**Урак, иген уру**

Бәләкәй генә бөкере
Бөтен кырны бетерде.

Сыңар мөгез үгезем
Сөзеп кыр аудара.

Камыл төбеннән
Яңа туган ай йөгерә.

**Комбайн**

Үзе ура,
Үзе суга,
Үзе суыра.

**Көлтә**

Юк аягы, юк кулы,
Боргычлап билбау буды.

Йөз туган
Бер каеш буган.

**Солы көлтәсе**

Кечкенә генә Петра
Билен буып утыра.

**Сүс көлтәсе**

Бәләкәй генә марҗа кызы,
Билен буа да суга сикерә.

**Көлтә бәйләү машинасы**

Чылтыр-чылтыр Мәликә,
Өч селтәүгә — бер көлтә,—
Әллә ничек өлгертә.

**Көлтә, чүмәлә**

Әнисеннән алда кызы туа.

**Кибән**

Бер мичкәдә кырык кыршау.

**Ындыр табагы**

Йөзи агаң табагын
йөз илле кеше дә
әйләндереп салалмас.

**Чабагачлап ашлык сугу**

Ары да лап-лап,
Бире дә лап-лап,
Сөңге саплап,
Киез каплап,
Ука таптап,
Баштан башка
Чыктык чак-чак.

Күккә менә — әлә-лә,
Җиргә төшә — әтә-тә.

**Ашлык сугу машинасы**

Әйләнә ул зырылдап,
Зырылдап та пырылдап,
Ашый салам, төкерә бодай,
Тавыш бирә тырылдап.

**Бәрәңге**

Җир астында җиз бүкән,—
Ул ни икән?

Чәчәге агачында,
Алмасы тамырында.

Төбе алмалы,
Башы чалмалы.

Башы — тәтәй,
Төбендә — ун күкәй.

И рәхмәте, рәхмәте,
Рәхмәтенең данәсе;
Данәсен алып җиргә күмсәң,
Гөрләп чыгар баласы.

**Кәбестә**

Кат-кат тунлы,
Карыш буйлы.

Эсселәнгән саен
Кат-кат тун кия.

Кат-кат яулыгым,—
Чишәм дә ташлыйм,
Чишәм дә ташлыйм.

Ак казым
сыңар аяк өстендә тора.

Ак казым,
кырык кат канатлы булса
да, очалмый.

**Кишер**

Җир астында алтын казык.

Кызыл кызы җир эчендә,
Чәчләре җир өстендә.

Үзе кызыл, үзе буялмаган.

**Суган**

Кечкенә генә сары карт,—
Кигән туны тугыз кат.

Өч кат тун кигән,—
Кем салдырса, шул җылый.

Түтәлдә утырган бер хатынны
кем үпсә, шул җылый.

Җир астында җирән ат,
Аның тиресе җиде кат;
Суярсың да тунарсың,
Тунаганда еларсың.

Үскәндә яфрагын ашыйлар,
Үсеп җиткәч, тамырын
ашыйлар.

**Борыч**

Кечкенә генә мишәр кызы
Йөрәгемне көйдерә.

**Чөгендер**

Җир астында кызыл әтәч.

Туп түгел — түгәрәк,
Күсе түгел — койрыклы.

**Шалкан**

Җир астында картыгыз,
Сакалыннан тартыгыз.

Түгәрәк — ай түгел,
Сары — май түгел,
Койрыгы бар — тычкан түгел.

**Торма**

Җир астында җиз бүкән.

**Помидор**

Түгәрәк кенә кызыл йорт,
Эче тулы корт.

**Кыяр**

Тәрәзәсе юк, ишеге юк,
Эче тулы халык.

Алтын-алтын яфырак,
Ятыр җире туфырак,
Алтын белән каплаган,
Көмеш белән саплаган.

**Кабак**

Йомры яткан таш күрдем,
Тозсыз пешкән аш күрдем.

Үзе — бер бөртек,
Эче — мең бөртек.

**Карбыз**

Үзе шардай,
Эче кандай,
Тәме балдай.

Өе яшелгә буялган,
Эчендә кызыл чаршау.

Тышы таш, эче боз.
Тәрәзә-ишек куймаган,
Эчен кемдер буяган.

**Кавын**

Ходай биргән туп кына,

Аягы-кулы юк кына;
Ука белән тупчыган,
Ефәк белән типчегән.

Тавык суйдым — ак канлы.

**Мәк**

Бикле келәт эчендә кара ком.

Җитмеш карак бер калпак
астында.

## БӨҖӘКЛӘР, СӨЙРӘЛҮЧЕЛӘР, ҖИР-СУ ХАЙВАННАРЫ, КОШ-КОРТ, ҖӘНЛЕКЛӘР, ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ

**Бал корты**

Җил-җил җилә килә,
Ике җиңен селкә килә;
Каенсарга керә килә,
Каен суын эчә килә.

Җәйнең буе бал җыя,
Кышның буе хәл җыя.

Чи-чи итәр,
Читлегенә кереп китәр;
Алтын башлы, йомры кашлы,
Моны белгән йөз яшьле.

Или-или иләктән,
Или чыкты келәттән,
Бер битемнән суырып үпте,
Әле дә китми йөрәктән.

Тызлый да бызлый,
Үпкән җире сызлый.

**Бал кортының бал ташуы**

Алпавытның бакчасы,
Бакчасында мунчасы;
Мунчасына су китерә
Нечкә билле тутасы.

Бигрәк матур бакчасы бар,
Бакчасында кысасы бар;
Тәмле ризык ашыйлар,
Бик авыр йөк ташыйлар.

Безли дә безли,
Бигрәк җаны түзми,
Гел тәмлене эзли.

Озын-озын колгалар,
Анда кошлар оялар;
Ите хәрам, өресе хәләл,
Аны белер муллалар.

Очалар, очалар

Һавадагы каргалар;
Ите хәрамга китә,
Сөте хәләлгә китә.
Мөрт-мөрт мөрткәсе,
Йөз илле баш күркәсе;
Кимерсәң бар кимеге,
Суырсаң бар җилеге.

**Бал кортының кәрәзгә бал җыюы**

Кап-караңгы бүлмәдә
Ашъяулык бәйли кыз бала.

Чит-читләп менәр,
Чит-читләп төшәр,
Вәл бәдри, вәл челтәр*.

**Күч аерылу**

Чи-чи итәр, читәнгә кунар,
Аны тоткан уңар.

Чалма-чалма чәчәккә,
Чалып алдым беләккә;
Туксан егет йөгерә,
Тугыз кучкар менгерә.

**Умартада яшь корт анасы**

Ялгыз өйдә кыз елый.

**Умартага бал кортлары ябу**

Почмаксыз аранга
койрыксыз сарыклар яптым.

**Умарта һәм бал кортлары**

Кечкенә генә келәт,
Эче тулы кеше,
Берсенең дә юк теше.

Аршин ярым бүзем бар,
Бөдрә чәчле кызым бар;
Күтәрергә хәлем юк,
Кеше алыр дип гамем юк.

**Бал**

Чәйдә — чәйдәш,
Майга иптәш,
Аңа юк тиңдәш.

**Кәрәзле бал**

Инәемнең иләге,
Иләгендә чиләге,
Чиләгендә сары җиләге.

**Балавыз**

Пичкә салсаң җеби,
Суга салсаң корый.

**Төклетура**

Дул-дул итә,
Дугага куна,
Әфәфи җонлы,
Алтын канатлы.

**Чикерткә**

Чик-чик итә — читкә сикерә.

«Тоттым» дигәндә тора да
китә.

Ат башлы,
Болан мөгезле,
Бүре гәүдәле,
Бүкән сынлы,
Кош канатлы,
Кырмыска аяклы.

Аягы кулдан югары,
Сикерә талдан югары;
Ни кош түгел, ни корт түгел,
Тезе билдән югары.

**Күбәләк**

Җилт-җилт итәр,
Җилпеп китәр,
Гөлгә кунар,
Чәчкә үбәр.
Бик күп төрле,
Алтын сырлы.

Зелф-зелф итәр, зелфәргә
кунар,
Әлиф-лям* сырлы, алтын
кырлы.

Аллы-гөлле очкалак,
Оча гөлләр кочкалап.

**Ефәк корты**

Кечкенә генә бер корт,
Ашаганы — тут,
Адәмне киендерә,
Кызларны сөендерә.

**Көя корты**

Бәла-бәла-бәла килә,

Ике җиңен сала килә,
Йон-тирене җия* килә,
Йортка зыян кыла килә.

**Коңгыз**

Үзе кара — карга түгел,
Мөгезе бар — үгез түгел,
Алты аягы бар — тояксыз.

Чем кара — елан түгел,
Мөгезле — сөзгәк түгел,
Канатлы — песнәк түгел,
Очканда мыш-мыш килә,
Туфракка яшеренә,
Бу нәрсә, йә, кем белә?

**Ат коңгызы**

Кара — карга шикелле,
Мыеклы — маймыл шикелле.

**Кырмыска**

Билле-билле җирән ат,
Биле нечкә көрән ат,
Тауга менеп таймас ат,
Хәстә тиеп үлмәс ат.

Үзе базык,
Биле нәзек,
Шәһәргә ташый
Бүрәнә дә азык.

**Кырмыска оясы**

Иләк-иләк тарым бар,
Күтәралсаң барын да ал.

Урманда утсыз казан кайный.

Кечкенә генә кешеләр тау
өяләр.

**Кигәвен**

Чи-чи итә, читәнгә куна,
Ду-ду итә, дугага куна,
Моны белмәгән кеше.
Караңгы мунчада куна.

Үзе бер дә армас,
Ат артыннан калмас,
Дугадан да узмас.

**Үрмәкүч**

Кулсыз-аяксыз җәтмә кора.

Алты аягы бар — Алып түгел,
Дүрт күзе бар — Дию түгел;
Аркасында кылдан җебе,
Эрләп суккан җебе түгел.

Күрер-күрмәс күзләре,
Челтәр бәйли үзләре,
Челтәрләре түгәрәк,
Эшли алар үрмәләп.

**Чебен**

Җизни аты егылган,
Йөз мең халык җыелган.

**Түшәмдәге чебен**

Безз-безз, без түбән,
Безнең өстә — йөзтүбән.

**Черки яки озынборын**

Кем аны үтерсә,
шул үзенең канын коя.

Безз-безз, безелди,
«Борынымда бар безем»,— ди,
Үзеннән зурга: «Энемм»,— ди.

Борыны озын — фил түгел,
Үзе шаулый — җил түгел.

**Кандала**

Асты такта, өсте такта,
Кызыл егет карап ята.

Кызыл корсаклы бала
Кеше таларга бара.

Киштә буйлап кызыл йомгак
тәгәри.

**Таракан**

Морҗа төбем — җиз кадак.

Мич башында — тархан* туе.

Ап-ак тауның башында
Кара өер утлыйдыр.

**Кыргаяк**

Юештә йөрер хәле бар,
Кырык төрле тәне бар,
Исеме белән җисеме бар.

**Борча**

Ары да очар карачай,
Бире дә очар карачай,
Тал төбендә тонык су,
Тондырып эчәр карачай.

Караңгы өем эчендә
Кара тәкә сикерә.

Сәке астында чирү* йөри.

**Бет**

Яссыдыр, йомрыдыр,
Итең-тәнең тырмалар,
Кан имәргә бик әвәс,
Анда-монда юргалар.

Адәмне сөя,
Әмма ләкин азаплый;
Адәм аны сөйми,
Әмма ләкин эзли.

**Балык**

Канаты бар, очалмый,
Күккә таба карамый,
Йолдызларны санамый,
Коры җирдә торалмый.

Суда йөзә — кош түгел,
Канаты да юк түгел,
Ай-һай, аның күлмәге,
Кемнәрнең бар күргәне?

Башы бар, чәче юк,
Күзе бар, кашы юк,
Авызы бар, теле юк,
Гәүдәсе бар, муены юк;
Суыкта туңмый.
Эсседә көйми,
Аягы юк, үзе йөри.

Көмеш тәнле,
Ите тәмле.

Аяксыз тай чуптырдый,
Койрыгын миңа тоттырмый.

**Җылым белән балык тоту**

Аучылар килделәр,
Хуҗаларын тоттылар,
Өе чыгып качты.

**Җылым**

Ямавы юк — тишек-тишек,
Чыгып булмый — юк ишек.

Сараемның эргәсе— аркан,
тәрәзәсе мең,
берсенең дә пыяласы юк.

**Кысла**

Мунчага керәм кара булып,
Мунчадан чыгам кызыл
булып.

**Бака**

Баткаклыкта җылый, үзе
чыкмый.

Үз күлендә үзе патша.

Аралга да ул хуҗа
Тугайга да ул хуҗа,
Көн җылынса, кычкыра.

Җәй буе акыл сата,
Кышын боз булып ката.

**Ташбака**

Аягын-башын яшерә
Таш күлмәге эченә.

И таш капка, таш капка,
Аслы-өсле куш капка.
Аны беркем ачалмый,
Хуҗасы да чыгалмый.
Муенын сузып караса да,
Капкасыннан узалмый.

**Сөлек**

Суда—Сөләйман*.

Пыяла чардак эчендә
Кара кызлар эшендә.

Ите бар — сөяге юк,
Авызы бар — теле юк.

**Карышлавык**

Арслан батыр калышмый,
Юл йөрүгә карышмый,
Барыр юлын буе белән
карышлый.

Ганбәр ана*,
Үз буе белән җир үлчәп,
хаҗга бара.

**Әкәм-төкәм**

Борма-борма бормадыр,

Шул торбада торадыр.

**Елан**

Урманнан чыгар,
Түше белән шуар,
Кешене күрсә — куар.
Әфәләм* төрле,
Көмеш сырлы,
Төймә башлы,
Тоз күзле.

Тауга менә таяксыз,
Таудан төшә аяксыз.

Озын эчәк,
Бер очы төенчәк.

Юл өстендә майлы каеш.

**Тузбаш елан**

Суда йөзә,
Җирдә шуа,
Койрыгы очлы,
Җиз башлы.

**Елан һәм балык**

Җир астында — җирән атым,
Боз астында — бүз атым.

**Елан һәм бүре**

Җиз камчысын тотып
булмый,
Җиз атына утырып булмый.

**Кош**

Югары менә чылбырсыз,
Түбән төшә баскычсыз,
Өйләр сала балтасыз.

**Кош мамыгы**

Күтәреп була,
өй аркылы ыргытып булмый.

**Сыерчык оясы һәм сыерчык**

Колга башында бер өй,
Кунагым тәрәзәсеннән йөри.

Коймада — өй, өйдә — җырчы.

**Сандугач**

Ары да чут, бире дә чут,
Иһи лә, миһи лә,
Ул нәрсә, йә, сөйлә?

**Карлыгач**

Ерактан килгән кунак булса да,
тәрәзә артында тора.

Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый.

**Күгәрчен**

Гөлдер-гөлдер гөл итекле,
Гөлкәй кызыл читекле.

Көләч түтәй гөлдерәк,
Кызыл читек, күк күлмәк.

**Чыпчык**

Урмый, чәчми,
Ил өстендә көн итә.

**Саескан**

Көлтәсеннән бастырыгы озын.

Кечкенә генә берәү,
Артында озын терәү.

Өй башында саплы чүмеч.

Койрыгын алса — башы
ябыша,
Башын алса — койрыгы
ябыша.

Ала атым җигүле,
Тисничәсе* төяүле.

Агы астай,
Карасы кештәй,
Борыны боздай.

Күзе тоздай,
Йөгергәне кыздай.

Ак җире кершән кебек,
Яшел җире суган кебек,
Кара җире корым кебек,
Утырганы мулла кебек,
Сызгырганы шайтан кебек.

**Саесканның кунган, очкан вакыты**

Казаннан кара,
Кардан ак;
Уракτан кәкре,
Уктан төз.

**Саесканның йомырка эчүе**

Ак келәтне ватып керә,
Сары майны чөмерә.

**Акчарлак**

Ак уймагым суга төште,
Балдаклары уела төште.

**Тургай**

Бер кошым бар: тынмый,
Агачка оя кормый;
Өе — җирдә,
Җыры — күктә.

**Кәккүк**

Үзе йомырка басмый,
Баласын да бакмый.

**Тукран**

Кара урманның эчендә
Агач кыңгырау шалтырый.

Җәй шакылдый бу чүкеч,
Кыш шакылдый бу чүкеч,
Ничек чыдый бу чүкеч?

**Тутый кош**

Син әйтәсең, ул кабатлый.

**Мәче башлы ябалак**

Көндез йоклый, төнлә җылый.

**Бөркет**

Кара атым җилә килә,
Юл уңае тибә килә.

**Торна**

Үзе озын, чабуы кыска.

**Божыр**

Урманнан чыгар, үзе чуар.

**Божыр аулап, утта өтү**

Урманнан чыгар
Өсте-башы чуар,

Тимербай куар,
Биктимер суяр,
Хуҗасы өтәр,
Исе дөньяга тулыр.

**Көртлек**

Биек каен түбәсендә ах-ух
итәдер.

Ханның кызын алыр идем,
Кашым кызыл булмаса.

**Көртлек аулау**

Урманнан чыгар,
Түше чуар,
Бикәнәе куар,
Бикмәмәте тотар,
Биктимере суяр;
Солтан башлы,
Кызыл кашлы,
Аны белгән йөз яшьле.

**Күркә**

Кабара, кабара, кабара күк,
Кабарып пешкән икмәк күк;
Шыгай улы кунак күк,
Киенеп чыккан кияү күк.

Ясана, ясана, ясана күк,
Ясана килгән кияү күк;
Кызара, кызара, кызара күк,
Кызарып пешкән чия күк.
Кытай бара юлдан,
Каткан-поскан туннан;
Кызыл чугы муйнында,
Тәсбихләре кулында.

Гөбер-гөбер гөбара,
Кызыл күрсә кабара.

**Каз**

Суда юынып алды,
Өсте коры калды.

Кыйкан-муйкан атлаган,
Ак чикмәнен каплаган.

Суда йөзә,
Күктә оча,
Җирдә йөри,
Ит белән сыйлый.

**Каз бәбкәсе**

Су өстендә сары күбек.

Яшел палас өстендә
Сары йомгак тәгәри.

**Үрдәк**

Ука-ука тыш кына,
Су коена инештә;
Очалса да җирдә йөри,
Ите яхшы бәлешкә.

Соскы борын бакылдык,
Күп сөйләшә такылдык.

Көрәге — алдан,
Әрҗәсе — арттан.

Су төбенә төшә,
Чыланмыйча чыга.

**Үрдәк бәбкәсе**

Җон җомгагым — бөдрә,
Су күрдеме — йөгерә.

**Әтәч**

Башы тарак,
Койрыгы урак,
Кычкыртып быргысын,
Уята барысын.

Укталы да чукталы,
Муены яшел нукталы,
Түбәсендә тарагы,
Койрыгында урагы,
Тәпиендә сәнәге,
Шул ни булыр, йә әле?

**Әтәчнең кикриге һәм койрыгы**

Нинди тарак тararга ярамый?
Нинди урак урырга ярамый?

**Әтәч, таң ату**

Базда бака кычкыра,
Тауда такта ярыла.

**Тавык**

Кечкенә генә кодача,
Аның артын җил ача.

**Тавыкның йомырка салуы**

Кыт-кытыйк, кайда салам —
анда юк.

**Тавыкның ояда утыруы**

Ак тау өстендә ак мулла
утыра,
Үлекләрнең терелүен көтә.

### Йомырка, чеби

Җанлыдан җансыз туар,
Җансыздан җанлы туар.

Ике туа, бер үлә.

### Йомырка

Кисмәк таптым кыршаусыз,
Ул да булды капкачсыз.

Бер кисмәктә ике төрле бал.

Бәләкәй генә ак келәт,—
Эче тулы сары май.

Кечкенә генә таш пулат,—
Эче тулы алтын да көмеш.

Таш пулат,
Көмеш пулат,
Эчендә сары балавыз.

Бозын ватсаң, көмеш чыгар,
Көмешен ватсаң, алтын
чыгар.
Ак күл,
Ак күл эчендә сары күл.

Пыяла түгел — ватыла.
Гәүһәр түгел — сатыла.

Ак гөмбәзле бер таш мәчет
бар,—
Керергә ишеге юк,
Гөмбәзен ватып керәләр.

Ак толып җөйсез генә
тегелгән.

### Йомырка пешереп ашау

Ак табагымның ашы татлы.

Тоз боткасында кайнатсаң да,
Тозсыз ашап булмый.

Тумаган тавыкны ашыйлар.

### Аю

Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста.

Килә бер батыр атлап,
Аягы баса лап-лап;
Урманда йөри,
Умартадан бал көри.

**Аю, балык, этәч, баклажан, сабын**

Тауда Талайман* күрдем,
Суда Сөләйман күрдем,
Ит сакаллы ир күрдем,
Кояшка пешкән аш күрдем,
Күбек коскан таш күрдем.

**Аю һәм елан**

Җизни атын менеп булмый,
Җиз камчысын тотып булмый.

**Бүре**

Әнә бара Алып,
Колакларын салып;
Киңдер күкрәге,
Тимердер йөрәге.

Әнә бара хан,
Авызы-борыны кан.

Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Бозаулар эзли.

**Төлке**

Әдәпле генә кодача
Тавыкларны ярата.

Нечкә билле,
Көлтә койрыклы.

**Куян**

Әйтим бер йомак:
Җәен соры, кышын ак,
Төймә койрык, шеш* колак.

Кечкенә генә Батыш,
Куак астында ятыш.

Курыкканнан да курыккан,
Курыкмаганнан да курыккан,
Күләгәсеннән дә курыккан.
Колаклары сөңге-сөңге,
Аяклары дөңге-дөңге;
Базарга чыгарып сатар идем,
Унике тиен деньге, деньге.

**Куян, көзге**

Чал тәкәдә мөгез юк,
Чалт аязда болыт юк.

**Ас**

Бән, бән, бән икән,
Бармаклары ун икән;

Шомырт кара күзе бар,
Ак өстендә миңе бар.

**Йомран**

Чут-чут чунлы,
Өсте җылы тунлы,
Ефәк ыштанлы.

Кәкре егет алтын казый.

**Йомран, бака**

Җир астында җизнәм аты кешни,
Су астында бабам аты кешни.

**Керпе**

Яланда энәле йомгак ятыр.

Энәләре үзе белән йөри,
Үзе тегә белми.

Өстенә шау энәле күлмәк кия,
Шулай да аны әнисе
«йомшагым» дип сөя.

**Тиен**

Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата.

**Тычкан, күсе**

Сәке астыннан туй уза,
Сөңгеле дә мылтыклы.

Идән астында печмәгән тәкә йөри.

Җир астыннан җек* чыгар,
Ике колагы тек* чыгар.

Койрыгы озын,
Үзе кыска,
Мәчедән курка.

Эргәдәдер өйләре,
Бал-май ашар үзләре,
Елт-елт итәр күзләре.

**Тычкан, мәче**

Урманнан чыгар,
Койрыгы чуар;
Әйтегез Исхакка,
Кереп китте почмакка.

**Ялман (кушаяк)**

Керт-керт тауга менә,
Керт-керт таудан төшә;
И аяулы, аяулы,
Койрык очы буяулы.

**Маймыл**

Чылт-чылт күзле,
Адәм төсле йөзле,
Үчекләшер үзе,
Ходайның бойрыгы,
Бардыр койрыгы.

**Капкын, тозак**

Юаш ятар,
Дәшми тотар.

**Ат**

Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,
Үзе авылда беренче эшче.

Калын арка,
Тарта да тарта,
Ул тарткан саен табыш арта.

**Ат бәкәлләре**

Дүрт карый,
Дүртесенең дә сакалы артка
карый.

**Ат аяклары һәм койрыгы**

*(чапкан вакытта)*

Дүртәве көшел тарта,
Берәве җилгерә.

**Дага һәм кадаклары**

Дүрт яңа туган ай,
Егерме дүрт йолдыз.

**Ат, арба, күпер**

Дөбер-дөбер дүртәү,
Дөбердәүче бишәү,
Иван агай алтау,
Шыбан агай шып ялгыз.

**Ат, сыер, эт**

Безнең өч дустыбыз бар:
Берсе ашата,

Икенчесе эчертә,
Өченчесе йорт саклый.

**Ишәк**

Бүре түгел — көрән,
Куян түгел — озын колаклы,
Ат түгел — тояклы.

**Сыер**

Үлән ашый, май ташый.

**Сыер, аның койрыгы
һәм мөгезләре**

Ишегалдында чүмәлә;
Артында — себерке,
Алдында — сәнәк.

**Сыерның аяклары,
мөгезләре, койрыгы**

Дүрт терәвеч,
Ике кылыч,
Бер болгавыч.

Ике сөзгеч,
Дүрт йөргеч,
Бер селтәвеч.

**Сыерның аяклары,
койрыгы, мөгезләре,
күзләре**

Дүрт терәвеч,
Бер болгавыч,
Кәкре кубыз,
Якты йолдыз.

**Сыер мөгезләре**

Бөтен батыр йокласа да,
Ике батыр йокламый.

Бер җирдә бар куш агач,
Буран сырмас, кар тимәс.

Коры ботакка кыйгыр* кунмас.

**Сыерның теле белән
борынын ялавы**

Ике өйгә бер кисәү.

**Сыер җилене**

Турсыкта сөтем оемый.

**Сыер имчәкләре**

Идән астында дүрт көпшә,
Дүртәве дә бер төштә.

Агыйделдә дүрт тал:
Берсе — Сәрви, берсе — Гыйльми,
Берсе — Ишнәр, берсе — бал.

**Сыер һәм кәҗә имчәкләре**

Гөбер-гөбер, гөбертау,
Гөбертауныкы дүртәү,
Илемәйнеке икәү.

**Сыер саву**

Дүрт татар,
Дүртесе дә бер чиләк төбенә
атар.

Дүрт килендәш бер кияүгә ук
атар.

**Сөт**

Сыек булса да су түгел,
Ак булса да кар түгел,
Йомшак булса да йон түгел.

**Кәҗә**

Үзе актай,
Корсагы каптай,
Кәкре таягы шактай.

Сакаллы килеш туа,
Берәү дә гаҗәпләнми.

Сакалы бар, акылы юк.

Юк үзенең әдәбе,
Маңгаенда сәнәге,
Коелып йөри сәдәбе.

**Сарык**

Тиресе иләнмәгән,
Туны тегелмәгән,
Тутай шуны киеп йөри.

Ашата, туендыра,
Җылыта, киендерә,
Кешене сөендерә.

Кара җиңги суга бара,
Шомыртларын коя бара.

**Сарык йонын алу**

Урманны кыркалар,
йомычкасы төшми.

**Сарык бәрәне**

Мич янында ак итек.

**Дөя**

Коры җирнең кимәсе.

Ияре дә, дугасы да үзендә.

**Дуңгыз**

Ни югалттың, ни эзлисең?
Кем кыйнады, ник
җылыйсың?

Төрән танау җир сөрә.

**Эт**

Кешенең дусты, йортның
сакчысы.

Сакбаем теле салынып
төшсә дә,
койрыгы югары.

**Этнең аяклары һәм койрыгы**

Дүрт тал-агач төбендә
Кәкре кое сиртмәсе.

**Мәче**

Мыегы бар, сакалы юк,
Туны бар, чапаны юк;
Файдасы өйдә булгач,
Яланга сәфәре юк.

Үзе суфый, үзе урлаша,
Әле тотсаң тырнаша.

Бәләкәй генә җиңгинең
Артына уклау тагылган.

Үзе мич башында,
Үзе тун ябынып йоклый.

Мич башында комган,
Колакларын йомган.

**Мәче һәм эт**

Берсе өйне саклый,
Берсе тышны саклый,
Үзләре бер-берсенә кан
дошман.

**Хайван өстендәге тире**

Берәүләрнең өстендә
Тегелгән җылы тун,—
Теләсәң кайда ятып кун.

**Ала тире**

Ямау салам, җөе юк,
Паласымның кыры юк.

## КЕШЕ: АНЫҢ ТӘН ТӨЗЕЛЕШЕ; ГАИЛӘ, ТУГАНЛЫК

**Ана һәм карындагы бала**

Кырык бармак, кырык тырнак,
Ике җанга бер сулыш.

**Бәби**

Асты диңгез, өсте нур.

Кунак килде, чыгып алыгыз:
Аягы бар — йөрми,
Күтәрмичә өйгә керми.

**Имчәк сөте имү**

Ак җимеш,
Өстәлгә куелмый,
Үзен һәркем ашый.

Берәүләр үз ашларын
эскәтер җәйми генә ашыйлар.

**Бишек**

Төшә-төшә, җиргә җитми,
Менә-менә, күккә җитми.

**Бишектәге бала**

Югары менәр һү-һү,
Түбән төшәр һү-һү,
Уртасында былбыл кош
Сайрыйдыр ла һү-һү.

**Кеше гәүдәсе**

Үзе бер, ябе дүрт,
Һәр япьтә бишәр ботак.

Ике багана,
Ике багана өстендә мичкә,
Мичкә өстендә бөке,
Бөке өстендә йомры туп,
Туп өстендә куаклык,
Куаклык эчендә хайванлык.

**Гәүдә һәм колаклар**

Бер агачта ике яфрак.

**Гәүдә, авыз, тел**

Өлкән өй,
Өлкән өй эчендә кече өй,
Кече өй эчендә балван бии.

**Баш**

Бер бүкәндә җиде тишек.

**Чәч толымы**

Тал башына кара җылан
асылган.

**Чәч, бет**

Урман ботаксыз,
Җәнлеге сөяксез.

**Чәч алу**

Тимер тәкә тау яра.

Карурманны бер балта белән
кырып салдым.

**Чәч, маңгай, каш, күз, борын, тел, ияк**

Иң әүвәле кара урман,
Аннан ары шома тау,
Аннан ары кече урман,
Аннан ары елтыравык,
Аннан ары мышлыпый,
Аннан ары тәтелдек,
Аннан ары очлыкый.

**Чәч, каш, күз, борын, авыз, ияк, кул, бармаклар**

Кара урман,
Кара урман артыннан кире
урман,
Кире урман артыннан

җелкелдек,
Җелкелдек артыннан
мыркылдык,
Мыркылдык артыннан
шаркылдык,
Шаркылдык артыннан
селкенчәк,
Селкенчәк артыннан
тәртешкә,
Тәртешкә артыннан тырма.

**Чәч, каш**

Олы урман да кече урман,—
Берсен кыралар,
Берсен саклап торалар.

**Каш**

Ике батыр,
Аяк юлы ятыр.

**Керфекләр**

Йөзлек астында йөз энә.

Ялт-йолт ябыла,
Йозаксыз бикләнә.

**Керфекләр һәм күзләр**

Кыл-кыл, кыл сарай,
Кыл сарайның эчләрендә
Кылыклы атларым уйныйдыр.

**Күз**

Туз чиләк эчендә тырантай*
уйный.

Тирән күл — суы акмый.

**Ике күз**

Бер яланда ике күл.

Ике агай рәттән торсалар да,
Бер-берсен күрмиләр.

Ике туган бер-берсен
күрмәсәләр дә,
Гомер буе, бергә ятып,
бергә торалар.

**Ике күз һәм борын**

Ике туган һәрвакытны
Аерылып тормыйлар,
Юл аркылы торсалар да,

Бер-берене күрмиләр.

Ике туган янәшә
Чыгалмыйлар тау аша.

**Күзләр, колаклар, тел**

Икәү карап тора,
Икәү тыңлап тора,
Берәү сайрап тора.

**Күз һәм каш**

Ишек башы уратма,
Аны эзләрсез бер атна.

**Күз карашы яки уй**

Мин итекне кигәнче,
Агаем айда була.

**Күз яше**

Түгәрәк күлгә су тулган,
Көянтәләп алыгыз.

**Күзлек**

Бер күчәрдә ике көпчәк.

Тәртәсе бар, аты юк,
Күзләре бар, башы юк.

Бик күп укый, бер дә
белеме юк.

**Колак**

Яр буенда ярты алачык.

Бер тау тирәли ике тишек
чүмеч эленгән.

**Колак һәм алка**

Ишетмешнең ишек төбендә
ике туры ат бәйләдем.

**Борын**

Тау битендә бер амбар,
Аның ике ишеге бар,—
Бервакытта ябылмый,
Көне-төне җил уйный.

**Борын белән сулау**

Ишек ябылган,
Кече морҗадан җил уйный.

**Мыек**

Башы улакта,
Койрыгы колакта.

**Сакал**

Карт атаем урманында
Ат кермәгә юлы юк.

**Күсә***

Алдан — малай,
Арттан — бабай.

**Авыз, иреннәр**

Кечкенә генә җил капка
Ачыла да ябыла.

«Ти»,—дисәң, тими,
«Тимә»,— дисәң, тия.

**Авыз һәм бугаз**

Ишек,
Ишек артында тишек;
Аны белмәгән кешенең
Тамак асты тишек.

**Авыз, борын, күз, керфек, каш, чәч, бет**

Кап-кап, мыш-мыш, елт-елт,
челт-челт, каләм, урман,
җанвар.

**Авыз һәм тел**

Йөзлек* астында юеш бозау.

Кызыл сандык эчендә
күкеле сәгать кычкыра.

Оясыннан чыгып өрә дә кереп
кача.

Ти-ти итә,
Тау астына керә дә китә,
Бәласе иясен көтә.

**Тел**

Үзе сөяксез,
Сөйләгән сүзе хисапсыз.

Сөйдергән дә шул,
Биздергән дә шул,
Иң татлы да шул,
Иң ачы да шул.

**Авыз һәм тешләр**

Бикләнмәгән сандыкта
Утыз ике энҗем бар.

Түгәрәк күлдә алтын таш,
Ау салсаң да алынмас.

Бер өйгә керсәм,
Эче тулы күкәй, имеш.

**Авыз, тешләр, тел**

Кабык абзар,
Кабык абзар эчендә сөяк
абзар,
Сөяк абзар эчендә җизнәң аты
кешни.

Ит сарай,
Ит сарай эчендә ак калай,
Ак калай эчендә йөгерек
малай.

**Урт һәм тешләр**

Ак тавыклар кунаклаган
Кызыл киртә өстенә.

Кечкенә генә кунача,
Утыз ике кодача
Утыралар кунакта.

**Тешләр һәм тел**

Сөяк келәт, ит бастырык.

Утыз ике ак ат,
Бер чыгымчы җирән ат.

Көмеш сарай эчендә
Чаптар айгырым кешнидер.

**Тешләр, иреннәр**

Сөяк абзар, кабык ишек.

**Тешләр, иреннәр, сөйләшү**

Койма коелган,
Каплап куелган,
Әмма җил тормый.

**Төкерек**

Олы юлдан берәү бара,
Ак капчыгы төшеп кала.

Чарлактан ак чалма төште.

**Кул һәм бармаклар**

Бер ананың биш баласы,
Кайсын тешләсәң, шунысы
авырта.

Биш анага биш туган,
Бишесе дә иш туган;
Арада берсе баш туган,
Буйлары гына тиң түгел.

Уклау,
Уклау башы чуклау,
Чуклау башы биш тармак.

**Кул, бармаклар, тырнаклар**

Өй эчендә биш бала,
Бишесендә биш тана.

**Кул, бармаклар,
тырнаклар, кына ягу**

Мәгъри, мәгъри, мәгъри тал,
Мәгъри талда биш ботак,
Биш ботакка кар яуган,
Кар өстенә кан тамган.

**Ике кул һәм бармаклар**

Ике анада бишәр бала,
Һәркайсына бер исем.

**Беләк һәм беләзек**

Ак каенда сары билбау.

**Бармаклар, йодрык**

Таралгач — биш,
Җыелгач — бер.

**Имән бармак**

Күзсез, телсез,
Барысын да өйрәтә.

**Бармаклар һәм йөзек**

Ит бүкән, тимер кыршау.

Ун казыкка бер көмеш
кыршау.

**Бармаклар һәм перчатка**

Биш малай керә чоланга,
Һәрберсе бер чоланга.

**Аяк, кул, бармаклар**

Дүрт таяк,
Бишәр тармак.

**Аяклар**

Җирдә тора ике агай,
Тарбагай да тарбагай.

**Аяк бармаклары, үкчә**

Бишәве качып бара,
Биктимер куып бара.

**Йөрәк**

Җәрәхәте юк — авырта,
Төтене юк — яна.

**Үпкә, бавыр**

Әйләнәсе алты кат,
Акылың булса, аны тап;
Кына кебек кызыл кат,
Кылыклы булсаң, аны тап;
Беләү кебек бөп-бөтен,
Белекле булсаң, аны тап.

**Ашказаны**

Бер чокыр бар — тулмас,
Беркөнне дә буш тормас;
Буш торса, тынмас,
Ансыз кеше тормас.

**Эч**

Авызын бөргән капчык,
Эче тулы балчык.

**Кендек**

Ялан җирдә сыңар гына тай
эзе.

Үз буеңда — бер уймак.

**Ми, акыл**

Сөяк сарай эчендә
Исләй агай утыра:
Ай да дими, көн дә дими,
Исәп биреп утыра.

**Хәтергә беркетү**

Төймә төйдем, төпкә салдым.

**Искә төшерү**

Сандык төбемнән төенчек
алдым,
Чишеп карап, яңадан салдым.

**Уй-фикер, күңел**

Бер секунд эчендә
бөтен җир шарын әйләнеп
чыга.

Үзе бара — урында тора,
Үзе бөтен дөньяны әйләнә.

**Хыял**

Сөрмәгән җир өстендә,
Үсмәгән каен астында
Тумаган куян йөгерә.

**Акыл**

Аршинлы түгел, потлы түгел,
Һәркемдә бар.

**Бәхет**

Үлчәүләрдә үлчәнми,
Базарларда табылмый.
Үзеңнеке булмаса,
Кешедән сатып алынмый.

**Кайгы**

Тоз түгел — ачы,
Кылыч түгел — үткер,
Ут түгел — яндыра.

**Йокы**

Базарда сатылмый,
Бизмәнгә салынмый,
Мамыктан йомшак,
Балдан татлы.

Сатучы да сатмый,
Алучы да алмый,

Вакыты җиткәч,
Бирәү дә алмыйча калмый.

Баш астында баллы кашык.
Ялт итмәс, йолт итмәс,
Кеше сизмәс, эт өрмәс,
Үзе килер.

Мүкәй килә, мүкәй килә,
Халыкларны кыра килә.

**Уяну, әтәч кычкыру, кояш чыгу**

Уф-уф итәр,
Үлгән кортлар кыймылдар,
Газраил муенын сузар,
Алтын табак ярылыр.

**Исем**

Җанлыга да ябышкан,
Җансызга да ябышкан,
Ябышканга да ябышкан.

Төшсә суга, батмыйдыр,
Ут кабынса, янмыйдыр,
Күмсәң җиргә, чермидер,
Беләсезме, ул нидер?

**Кеше гомере**

Иртән дүрт аяк,
Төштә ике аяк,
Кич өч аяк,
Өстендә була маяк.

**Саулык**

Дөньяда иң кирәк,
Иң кирәктән ни кирәк?

**Чир**

Бушка килә, акчага китә.

Потлап керә, мыскаллап чыга.

**Кәфен**

Якасы бар, җиңе юк.

**Табут**

Ясыйлар, саталар,
Кирәкмәгән кеше ала,
Кирәк кеше алмый.

**Мәет күмү**

Йөри торгач юк булды,

Җир куены тук булды.

Башсыз атка менгән,
Җиңсез күлмәк кигән,
Ашыга-ашыга ерак сәфәргә
китеп бара.

Бер арбада — биш баш, дүрт
җан,
Бишәү барып, дүртәү кайткан.

**Кабер**

Җир астында — ябык сандык.

Берәү былтыр бездән киткән,
Тигез җирне түмгәк иткән.

**Зират**

Авылы бар, төтене юк.

Авыл утырган, этәч
кычкырмый, халык тормый.

**Кеше үзе**

Үзе минем этинең улы,
Үзе миңа туган түгел.

**Ата**

Әй, углан, углан,
Без икебез бертуган,
Бар кер дә әйт анаңа:
Анаңның ире килгән.

**Ата һәм кыз**

Бер кыздан: «Бер көннәрдә бакчада бер кеше белән йөридер идең. Ул нинди кеше иде?»— дип сораганнар иде, кыз аларга: «Аның анасы минем әнкәемнең каенанасы буладыр»,— дип җавап бирде. Сораучылар: «Ул кеше белән бу кыз ничек карендәш буладыр инде?»— дип тикшерә калдылар. Кыз үзләреннән көлеп китте.

Җавабын инде сез бирегез.

**Ата, ана, карендәш**

Өч кешене күпме эзләп тә табалмыйсың. Кемнәр алар?

**Ата, ана, ул**

Ире белән хатыны,
Улы белән атасы,
Ул җитми, атасы белән баласы,—
Барысы ничәү?

**Ата, ана, кыз, ул**

Булган, ди, бер карт белән карчык: аларның бер кызы, бер малайлары булган; шул малайларның —

карт белән карчыклары, шул карт белән карчыкның бер кызы, бер малайлары булган. Бу ничек?

**Ата, ана, кыз, кияү**

Менә сезгә табасы,
Күмәк йортның чамасы:
Атасы белән кызы,
Хатыны белән ире,
Кияве белән бабасы,
Кызы белән анасы,
Кайнатасы, кайнанасы,
Аларның берәр баласы —
Ничәү болар барысы?

**Ата, кыз, кияү**

Гали кызы белән,
Вәли хатыны белән;
Ашъяулыкта өч күмәч,
Өләшеп бир берәрдән.

**Абый, сеңел, кияү**

Хатыны белән ир киткән,
Сеңлесе белән агасы киткән,
Өстәвенә кияү белән
кайнагасы киткән.

**Бабай, ата, ул**

Ике ата, ике угыл, бакчада йөргәндә дүрт алма өзеп, һәрберсе берәрдән ашасалар да, кулларында янә бер алма артып калган. Ул ничек була?

**Әби, ана, кыз**

Ике ана һәм ике кыз бергә утыз баш каз үстергәннәр.
Көз көне шул казларны баш исәбеннән бүлеп, һәрберсе унар баш каз алган. Шул ничек була?

**Кыз бала**

Бер кеше урамнан үтеп барганда кечкенә генә өй янында басып торучыны күреп:
— Нигә биредә торасың?— дип сораган.
Теге кеше:
— Мин этинең өен саклыйм, ләкин мин аның улы түгел,— дип җавап биргән.
Сезнеңчә бу кем булыр?

**Җиде бала**

Бер кешенең алты улы булган. Аларның һәрберсенең берәр сеңлесе булган. Бу кешенең ничә баласы булган?

## АВЫЛ, КАРАЛТЫ; ӨЙ, ҖИҺАЗЛАР, ЯКТЫРТУ ҺӘМ ҖЫЛЫТУ ӘЙБЕРЛӘРЕ

**Авыл тирәли тотылган читән һәм иген кыры**

— Кыек-мыек, ни эшлисең?
— Яшел әфәнде, сине
саклыйм.

**Утыртма читән**

Йөз дә бер брат,
Барысы да бер рәт,
Куйганнар терәп.

**Киртә казыклары**

Ике егеткә бер шарф.

Ике солдат бер каеш буган.

**Кое**

Тирән күлдә балык юк.

Кара җирнең төбеннән,
Казы дисәң, кан чыга.

**Кое сиртмәсе**

Мөгри-мөгри мөгрәгән,
Мөгезен күккә терәгән.

Озын агай кармак саплый.

Ак дөямнең муены озын.

**Коедан су алу**

Сыңар аяк бер торна,
Коега сузылып, су эчә.

Түбән төшә ләй-ләй,
Югары менә ләй-ләй,
Тонык суны тондырып
эчә ләй-ләй.

**Мунча миче**

Бер бүректә кырык ямау.

Кызыл үгезнең кырык
тишеге,
Кырык беренчесе үз тишеге.

**Мунча себеркесе**

Алып кайттым яшел каз,
Яшел казның башы таз.

Яшел чапан кигән, билен
буган,
Үзе кешене кыйный да
кыйный.

Урманда үсә,
Мунчада пешә.

Үзе чук-чук,

Бер шәһәргә керсә,
Кыйнаудан башка эше юк.

**Кар базы**

Якты вакытта караңгы була,
Суык вакытта җылы була,
Җылы вакытта суык була.

**Баскыч**

Озын-озын йөрмәләр
Аннан кеше үрмәләр.

**Утын кузласы**

Алтмыш өйгә бер сарык,
Ул да булса бик арык.

**Тегермән**

Кала тавы башында
Котырган аю шашына.

Тиз ашый, вак чәйни,
Бөтен илне туйдырса да,
үзе туймый.

Мин үзем су белән дә,
Җил белән дә торам,
Бөтен халыкны туйдырам,—
Үзем чәйним, башкалар йота.

**Су тегермәне**

Утыра әби елгада,
Аякларын асып елгага.

**Чарык**

Армас, талмас,
Аягын судан алмас.

**Чарык калаклары**

Бере керә, бере чыга,
Ардым-талдым дияләр.

**Җил тегермәне**

Мөгри-мөгри мөгрәгән,
Мөгезен күккә терәгән;
Аш та ашаган, туймаган,
Таш та ашаган, туймаган,
Җилсез күңел куймаган.

Дүрт канат, алты аяк,
Аны белмәгән кешенең
Аркасына тал таяк.

**Тегермән канатлары**

Дүрт ага тау менешә,
Берсе менә, берсе төшә,
Ардым-талдым, диешә.

**Тегермән мешкәсе**

Олы агайның бүреге
Кече агайга ярамый.

**Тегермән тарту, он**

Аю акыра, йонын коя,
Аның йонын кем җыя?

Үгез үкерә тора,
Йонын төкерә тора.

**Киез өй, тирмә**

Тәрәзәсе юк, түбәсе тишек,
Яңгыр үтми, җил өрми.

**Тирмәнең кирәгәләре**

Аркычак, торкычак,
Җыеп алсаң, бер кочак.

**Өй, мич, таба, бәлеш**

Агач пулат,
Таш пулат,
Тимер пулат,
Камыр пулат,
Тамыр пулат.

**Өй, мич, таба, май, коймак**

Агач өй,
Агач өй эчендә таш өй,
Таш өй эчендә тимер өй,
Тимер өй эчендә күл,
Күл эчендә үрдәкләр йөзеп
йөри.

**Өй базы**

Дәү әтидән калган иске
казан.

**Баздагы чүп-чар**

Базда батман тарым бар,
Күтәралсаң, барын да ал.

**Өй нигезе**

Кунак саен бер түшәк.

Өй артында карават,
Сузылып яткан Салават.

**Стенадагы ботак эзе**

Өй багалый үгез күз.

**Өй стеналары арасындагы мүк**

Өй әйләнәсе кыл дилбегә.

Кырык кунак, кырык буй,
Каян ястык җиткерим.

**Стена мүге һәм морҗа**

Өй тирәли кызыл билбау,
Уртасында бер егет.

**Өй почмаклары**

Тышта санадым — сигез,
Өйдә санадым — дүрт.

**Түбә такталары**

Өй башында телем-телем икмәк.

Өй башында дранча,
Дранча саен бер акча.

**Салам түбәдәге бастырык**

Сыерым аранда,
Койрыгы аран башында.

**Күзләвек**

Ае бар, шәүләсе юк.

**Өрлек һәм идән такталары**

Атасы өстендә балалары.

**Идән тактасы**

Ишектән кергән дә сузылып яткан.

**Идән ярыгы**

Өстәл астында яшь килен
көлә.

**Идән һәм түшәм**

Фатыйма белән Хәдичә
Бер-берсенә караша,
Килалмыйлар янәшә.

**Матча**

Әндри өйдә,
Башта тышта.

**Түшәм такталары**

Алтмыш татар
Аяк очлаш ятар.

**Матча һәм түшәм
такталары**

Озын агай сузылып ята,
Балалары тезелеп ята.

Бер мендәрдә алтмыш солдат
йоклый.

**Сәндерә**
Ишек,
Ишек өстендә бишек.

**Сәке**

Буй-буй күлмәк кигән,
Аягы җиргә тигән.

**Киштә**

Ике солдат мең солдатны
күтәрә.

**Ишек**

Киттем дип китә, кире килә.

**Ишек яңаклары**

Ике егет буй үлчәшә.

**Ишек яңаклары һәм ишек**

Ике килен тик утыра,
Кайнанасы эшләп йөри.

**Ишек өсте һәм бусага, ишек яңаклары, ишек**

Бер җирдә бар биш агай:

Икесе ята,
Икесе тора,
Берсе арлы-бирле йөри.

**Ишек һәм йозак**

Аю сыртына алма ябышкан.

**Ишек күгәне**

Ишек ача,
Ишек артына кача.

**Бусага**

Кечкенә генә таем бар,—
Кергән-чыккан атлана.

**Ишек тоткасы**

Көненә мең кеше белән
күрешә.

**Ишек бавы***

Кергән белән керә,
Чыккан белән чыга.

Бер сыер койрыгына
мең кеше ябышкан.

**Ишек элгече**

Караңгы өйдә карт агай
Кармак салып утыра.

**Йозак**

Кечкенә генә эт
Өрми дә, җибәрми дә.

Тимер чыпчык өй саклый.

**Йозакны бикләү-ачу**

Келт-келт итә,
Өенә кереп китә.

**Тәрәзә**

Җире пыяла, межасы агач,
Алтын яңак, җиз тупса.

Аркылы да торкылы
Безнең бабай ындыры.

**Тәрәзә һәм ишек яңаклары**

Түрдә дүртәү утыра —
түрәмен дип,
Ишек төбендә икәү утыра —
үләмен дип.

**Кием элгеч, чөй-кадак**

Бабай бармагы тун күтәрә,
Күтәреп төн үткәрә.

**Шкаф**

Аркылы да торкылы
Безнең бабай болдыры.

**Этажерка**

Йорт түгел — үзе биш
этажлы,
Кеше яшәми — кешенең
тормышы яши.

**Эскәмия**

Дүрт аягы баскан,
Бер аягы яткан.

**Өстәл**

Дүрт татар хатыны бер шәл
бөркәнгән.

Дүрт туган бер
түбә астында яшиләр.

Бер абзарда дүрт килен сыер
сава.

**Өстәл җәймәсе**

Йолкындым, талкындым,
Сузылдым, тартылдым,
Чирәмдә җәйләдем,
Сандыкта кышладым,
Өстәлгә җәелдем*.

**Урындык**

Ары тәки, бире тәки,
Кунак килсә, йөгрер тәки.

Аягы бар, кулы юк,
Аркасы бар, түше юк.

**Сандык**

Бар бер матур агач сарай,
Әйләнәсе суккан калай.

Дүрт мөеш, ике теш,
Түр башыннан төш.

Аяксыз-кулсыз — мал җыя.

**Карават**

Дүрт аяклы, ике башлы, бер корсаклы.

**Карават, түшәк**

Дүрт аяклы — мал түгел,
Мамыгы бар — кош түгел.

**Мендәр-ястык**

Дүрт колаклы,
Ике корсаклы,
Идәнгә төшмәс,
Түрдән китмәс.

Кеше түгел, яңа күлмәк сорый.

Иртә белән тау була,
Кич белән болын була.

**Юрган**

Көндез — хөрмәттә,
Кич — хезмәттә.

**Чыбылдык**

Торса дөядәй, ятса куяндай.

Ак өем бар — ишексез,
Чебен кермәсә дә, кеше керә.

Балтасыз чолан куйдым.

**Сөлге**

Озын-озын озарган,
Ике башы кызарган.

Ак тавыкның койрыгына кан тигән.

**Көзге**

Кечкенә генә түгәрәк күл,
Тирәк аның эчендә,
Чатма кигән, камка кигән
Кызлар аның эчендә,
Биленә кылыч бәйләгән
Егетләр аның эчендә.

Син артыңны әйләнсәң,
Ул да артын әйләнә.

Алды — хуш, арты — буш.

**Сәгать**

Башы бер, күзе унике.

Көн-төн йөри,
Урыныннан китә алмый.

Йөзе ак, күзләре кара,
Көне-төне алга бара,
Үзе бер урында кала.

Көн үткәнне кем белә?
Мин онытсам, ул белә.

**Күкеле сәгать**

Челт-челт итә,
Читлегенә кереп китә.

Мәскәүдән килгән былбыл,
Аягында чылбыр.

Йөк салсаң йөри,
Йөкне алсаң туктый.

**Будильник**

Җансыз җанлыны уята.

**Сәгать маятнигы**

Тауга менә — таелмый,
Таелса да егылмый.

**Сәгать һәм аның ике теле**

Олы киленем эшлекле,
Кече киленем кешелекле;
Үзем бай остабикәсе,
Эшемне кем эшлисе?

**Сәгать телләре**

Ике агай-эне:
берсе торганчы,
икенчесе урам әйләнеп
кайта.

**Идән мунчаласы**

Урманда туа,

Идәндә шуа,
Кулда елый.

**Себерке**

Бәләкәй генә бичура
Билен буып утыра.

Ишек артында биле бәйләүле
кол ятыр.

Йөз агай бер билбау
бәйләгән.

Билен буган Биктимер
Ишектән түргә сикерер.

Ишекле-түрле яшь килен
йөри,
Эләккәнне сөйри.

**Чырак***

Су өстендә чыжлап тора бер
елан,
Төннәрендә утлар чәчә
авызыннан.

**Шәм**

Багана яна, күмере-көле юк.

Күлмәге эчендә,
Гәүдәсе тышында.

Тешсез әби май ашый.

Казаннан килгән бер гөлем
бар,
Бөресез, ботаксыз;
Аны ашаган бер кошым бар,
Борынсыз, тамаксыз.

**Шәмдәл һәм шәм**

Тәне тышта,
Күлмәге эчтә,
Мәлихәсе башында,
Ул синең дә каршыңда.

**Шәмдәл, шәм, ут**

Табак,
Табак өстендә таяк,
Таяк өстендә әлтери,
Әлтери өстендә бәлтери,
Бәлтери өстендә калтырый,
Калтырый өстендә ялтырый.

**Керосин лампасы**

Пыяла сарай эчендә
Сары тавыгым утыра.

Өе дә пыяла,
Тәрәзәсе дә пыяла,
Кәрнизе челтәр,
Тәрәзәсе мең.

**Абажурлы лампа**

Атасы улын күтәргән,
Улы бүреген күтәргән.

**Асылмалы лампа**

Катлау-катлау катланган,
Кече матчага атланган.

**Филтә**

Бер башы — суда,
Бер башы — утта.

**Филтә күмерен алу**

Бармагыңны төрт,
Борыныңны сөрт.

**Электр лампасы**

Безнең өйдә ут яна,
Аның мае елгада.

Җем-җем итә,
Җемелдәп китә,
Шырпысыз үрләп китә.

**Өстәл лампасы**

Өстәлемдә бер гөмбә,
Яктыртып тора төнлә.

**Мич**

Үзе ак күлмәк кигән,
Башы түшәмгә тигән,
Аягы җиргә тигән.

Иртә тор да кара:
Әбинең күлмәге ак,
Изүе кара.
Аяксыз-кулсыз кершән ягына.

Кыш көне күп ашый,
Җәй көне күп йоклый.

**Мич һәм морҗа**

Гәүдәсе өйдә, муены тышта.

Җизни кигән ак күлмәк,
Башында балчык чүлмәк.

Аслы-өсле ак келәт,
Кулым кысты карт үләт.

**Мич, ялкын**

Таш өйдә сары төлке сикерә.

**Мичтәге утлы күмер**

Әрҗәм тулы чын ахак,—
Кулым тыгып алалмыйм,

**Мич, төтен**

Үзе өйдә, чәче урамда.

**Мич, ут, төтен**

Анасы юан, кызы чибәр,
Улы җитез икән —
Күккә җиткән.

**Мич, ут, төтен, кисәү агачы**

Анасы юан, кызы кызыл,
Улы уңган, атасы бөкере.

**Мич, утын, күмер алу**

Бер кечкенә таш пулат бар,
Эче киң дә авызы тар,—
Акны салалар,
Караны алалар.

**Тимер мич**

Дүрт аяклы кара куй,—
Төрепкәсе артында.

**Морҗа**

Өй түбәсендә киле,
Аны белмәгән тиле.

**Морҗа, төтен**

Өй кыегында бер карт
Челем тартып утыра.

Сыерым аранда,
Койрыгы яланда.

**Моржа япкычлары**

Кече киленнеӊ калфагы
Уртанчы киленгә ярамый,
Уртанчы килен калфагы
Кече киленгә ярамый.

**Чыра телү**

Тимер балык тау шуа.

**Утынны алып кайту, мичтә яндыру**

Сикереп торды,
Атка утырды,
Куышны тутырды,
Ачысын очырды,
Җылысын калдырды.

**Мичкә утын ягу**

Ак әбинеӊ тамагына
Кырык чыра кадалган.

Ишектән керә, тишектән чыга.

**Утынныӊ яна башлавы һәм төтен**

Атасы аягын киенгәнче,
Улы базарга барып кайта.

**Чакма таш, ут**

Таш тирмәнеӊ эчендә
Сары чәчле кыз ята.

**Чакма чагып ут кабызу**

Заман ахыры булганда,
Таш өстенә таш кубар,
Ике ташныӊ эченнән
Бөдрә чәчле кыз чыгар.

**Каплы шырпы**

Бәләкәй генә оя,
Җитмеш биш кеше сыя.

Кара башлы ак тутайлар
Төялгәннәр вагонга.

**Шырпы кабызу**

Бер бәләкәй генә малайныӊ башы каный.

**Ут**

Күрергә күркәм,
Тотарга куркам.

Зәңгәр-зәңгәр, зәңгәр чәчәк,
Күк-күк, күк чәчәк;
Күрер күзгә матур чәчәк,
Күтәрергә авыр чәчәк.

**Ут, утын яну**

Кызыл гына мәче баласы
агач өстендә уйный.

**Янгын**

Өй түбәсендә кызыл әтәч
кычкыра.

**Ут һәм казан**

Кызыл сыер кара сыерны
ялый.

**Учак яккан урын**

Кызыл үгез яткан җиргә
Кырык елсыз үлән чыкмас.

**Очкын**

Әстерханда утын кисә,
Йомычкасы монда төшә.

**Төтен**

Кара аю кикерә,
Күккә карап сикерә.

Казанның да бурасы,
Болгарның да бурасы,
Күтәрелгән курасы.

**Төтен, ут, морҗа**

— Озын агай, кая барасың?
— Кызылбай арттан төртә,
тырпыча авыз, син ни
беләсең?

**Төтен, көл**

Дию пәрие күккә аша,
Ашы-суы җирдә кала.

**Төтен яки ис**

Борынга керә,

Кулга тотылмый.

**Утлы күмер**

Мәрҗәнбикә идән тишәргә
оста.

**Сүнгән күмер**

Әрҗә тулы кара таш.

**Кисәү агачы, күмер алу**

Тимери агай олы киртәдән
кече киртәгә мәрҗән күри.

Аргы абзардан бирге абзарга
Йөгерә-йөгерә ут ташый.

**Пумала**

Бәләкәй генә чәчле пуп
Морҗа юллыгын тазарта.

**Пумала, төтен**

Бер ялбыр* эт
абзардан бөтен сарыкны куа.

**Җылыткыч батарея**

Гармун кебек сырлы ул,
Мич шикелле җылы ул.

**Су, газ торбалары**

Тирән базда тимер эчәк.

## САВЫТ-САБА, РИЗЫК ӘЗЕРЛӘҮ, АШАУ-ЭЧҮ

**Чиләк**

Үзе йомры, үзендә су тора.

**Чиләк тоткасы**

Су аркылы тимер күпер.

**Көянтә**

Киермә кашлы,
Киртек башлы.

**Ике чиләк белән суга бару**

Ике туган суга бара,

Берсен-берсе уза бара.

**Чиләк белән су алу**

Кола атым суга төште,
Колаклары салпая төште.

**Сусыз һәм сулы чиләкләр**

Барганда җырлый-җырлый
бара,
Кайтканда җылый-җылый
кайта.

**Көянтәләп суга бару**

Өч туган су керергә барган,
Икесе кергән,
Өченчесе ярда калган.

Бер дугада ике күл эленеп тора.

Бер ботакта ике кош сайрый.

**Кисмәк**

Кырык төштән билен буган,
Утыз чиләк аш ашый.

**Мичкә**

Кара сыерның кабыргасы
тишек.

**Мичкәдән су агызу**

Бер өй,
Өй битендә чөй;
Чөен күзенә тыгар,
Суырып алыр, су чыгар.

**Лакан**

Ике колаклы,
Өч аяклы,
Олы корсаклы.

**Ялгаш, тагарак**

Аркасы бар — эче юк.

**Комган**

Борыны бортас,
Карыны картас,
Атка менмәс,
Җәяү йөрмәс,
Тик тормас.

Өй артында җиз тәкә,

Җитәкләтә, күтәртә.
Үзе бармас,
Ияртсәң калмас.

Бохарадан килгән сары
торна
Башын сузып су эчә.

**Юынгыч**

Төртсәң су чыга,
Су чыкмаса, сүз чыга.

**Күмер савыты**

Кап корсак,
Эче кара бавырсак.

**Тәлинкә**

Өй эчендә түгәрәк күл.

**Чүлмәк**

Эче куыш, тышы таш,
Әләлекәй орчык баш.

**Миски**

Колагы бар, башы юк,
Ашамаган ашы юк.

**Казан**

Колагы бар — ишетми,
Тигез җиргә утырмый.

**Казан астында ут яну**

Кара сыер астында кызыл бозау.

Кара сыерым карап тора,
Кызыл сыерым ялап тора.

**Чүмеч**

Сыңар аяк саескан,
Суга төшеп, су эчкән.

Үрдәкнең койрыгы тау
башында,
Башы Кама елгасында.

**Кашык**

Үзе бер дә ашамый,
Ашаганда бушамый.

Биш туганга баш булам,
Ашатсам да ач булам.

**Май канаты**

Табышмак әйтәм, таба төш,
Табалмасаң утка төш,
Кайнанаң биргән ак яулыкны
Сары майга мана төш.

Алама тай,
Эче тулы май.

**Пычак**

Мөгез саплы,
Тимер кашлы,
Күн каплы,
Аны белгән мең яшьле.

**Өчаяк**

Черт-черт итә үзе,
Өч аягы, бер күзе.

**Таба**

Кара койрык куем бар,
Өйдән өйгә йөридер.

Бәләкәй генә тай,
Төбе чеп-чи май.

**Таба, кабартма**

Кайнар күлдә каек уйный.

**Таба, бәлеш**

Тимер ындыр табагында
Сырлы кибән утыра.

**Табагач**

Кара чегән кызы
мичтән коймак урлый.

Эләктергеч, каптыргыч,
Мичтән бәлеш тарттыргыч.

**Табагач, таба**

Аты — агач,
Арбасы — тимер.

**Табагач, таба,**
**коймак**

Электергеч, каптыргыч,
Хатыннарга тарттыргыч;
Чыж-ж иттереп салалар,
Кып иттереп алалар.

**Самавыр**

Кечкенә генә кыз бала
Йөрәгенә ут сала.

Башы да тишек,
Төбе дә тишек,
Уртасында ут,
Читендә су.

Ике чите су булыр,
Уртасында ут булыр;
Байларны көлдерер,
Ярлыларны бөлдерер.

Бохарадан килгән кунак
Ут ашый да су эчә.

Кечерәк кенә күл эчендә
Дөрли-дөрли ут яна,
Уты суны киптерми,
Суы утны сүндерми.
Килде бер төркем халык,
Утырдылар уфтанып;
Уты сүнде — янмады,
Суы кипте — калмады.

Гөбер-гөбер гөбердән,
Яккан уты күмердән;
Көмештән дә җиздән,
Табында күрербез тиздән.

И Туйбикә, Туйбикә,
Кунак килсә — куй, бикә;
Салпы колак, киң битле,
Сөйләшергә бик ипле.

**Самавыр морҗасы**

Мич алдында төпсез итек.

**Самавыр, чәйнек**

Алтын багана өстендә
Күк күгәрчен утыра.

Кытайдан килгән бер аккош;
Шул кош алтын багана
башына кунса,
Кунакның күңеле бик хуш.

**Самавыр, чәйнек, чәй ясау**

Җиз багана, таш чыпчык,
Очып төшә, косып менә.

**Самавыр, чәйнек, чынаяклар**

Менә кызык, менә кызык,
Менә китте кодалар кызып,
Берсе менә, берсе төшә,
Берсе тора сызгырып.

**Самавыр, поднос, чынаяклар**

Аталары — җиз күкрәк,
Аналары — киң күкрәк,
Балалары — чәлдер-чөлдер.

**Чәйнек**

Өстәлемдә ак үгез,
Маңгаенда бер мөгез.

Тәнендә — мунча,
Борынында — рәшәткә,
Аркасында — бер кул.

**Чынаяк**

Кечкенә генә кызым бар,
Кергән-чыккан үбәдер.

**Иләк**

Урманга барган да бөккән,
Урманнан кайткан да теккән,
Чит-чите тырт-тыртлы,
Уртасы иһа-һайлы*.

Урманда бөгелгән,
Өйдә тегелгән,
Өр-яңа савыт,—
Төбе тишелгән.

**Киле һәм кисап*, орлык төю**

Нечкә билле чибәр килен
Кое авызында бии.

Дөп-дөп, дөпәләп кимәләнки,
Көш-көш, көшәләп кимәләнки;
Алачыкка керсәнә,
Алача күлмәгеңне салсана,
Ходай биргән товарыңны
Ялтыратып салсана.

**Капчык**

Ач булса — ята,
Тук булса — торып утыра.

**Капчык һәм капчык бавы**

Келәте сүс,
Ишеге мунчала.

**Суыткыч**

Өй эчендә базым бар,
Баз эчендә бозым бар;
Керер идем, сыялмыйм,
Бозларында шуалмыйм.

**Ботка пешерү**

Куй көтүем суга төште,
Сөләйман аксак куа төште,
Карагай калпак каплый төште,
Торымтай эзли төште.

**Он иләү**

Тәбәнәк күктән кар ява.

Келәт астында буран уйный.

Болытсыз көнне яңгыр ява.

Уңнан да чалт чигәмә,
Сулдан да чалт чигәмә;
Бу җиңгидән йөдәп беттем,
Ни дип миңа кизәнә?

**Күәстә камыр әчетү**

Мич башында бичура
Билен буып утыра;
Башы ләмгә тыгылган,
Алалмыйча утыра.

Аяксыз-кулсыз агачка менә.

**Ипи әвәләү**

Ары да лап-лап,
Бире дә лап-лап,
Киндер каплап,
Көрәк саплап,
Мендәр каплап,
Әтү-ти!

**Мичтә икмәк пешерү**

Эче куыш, тышы таш,
Юеш салдым, коры алдым,
Аннан яхшы табылмас.

**Икмәк**

Үзе түгәрәк,
Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк;
Әчкелтем дә төчкелтем,
Бар нәрсәдән дә кадерлерәк.

Мине таяк белән кыйныйлар,
Таш белән кысалар,
Пычак белән кисәләр;
Ни өчен болай җәзалыйлар?—
Чөнки мине бары да ярата.

**Коймак пешерү**

Тап табышмак:
Табага ябышмак.

Чыш-пыш, җәел, пеш,
Татарский атна кич.

**Якмыш (кыстыбый)**

Өсте такта, асты такта,
Уртасында майлы турта.

**Бәлеш**

Ахактан, бохактан,
Тар — авыздан, киң — төптән,

Эче өрелгән,
Якасы бөрелгән,
Сырлы кәпәчен* кигән,
Табын түренә үрелгән.

**Токмач**

Әгәри,
Әгәри дә тәгәри,
Тәгәри дә суга төшә,
Күңелем шуны ярата.

Минем ялгызымны
ашамыйлар,
Әмма миннән башка татарга
аш булмый.

**Токмач яки салма салу**

Түгәрәк кенә күлгә яфрак ява.

Йөз елкы суга төште,
Сөләйман куа төште.

**Токмач ашау**

Кашык өстендә аягын
салындырып утыра.

**Чумар салу**

Бер бәкегә кырык тәкә сикерә.

**Пилмән ясау**

Кайчысыз киселә,
Җепсез тегелә.

**Пилмән пешерү**

Ак алаша батты,
Колаклары калыкты.

**Бавырсак**

Сары куйлар суга батты,
Шешенде дә өскә калыкты.

**Шулпага салынган май**

Шапылт итеп суга чума,
Күзе әйләнеп, су өстенә чыга.

**Ит**

Ашасаң, тешкә керә,
Ашамасаң, төшкә керә.

**Сөяктән җилек чыгару**

Зур ук башын ярдым,
Солтан кызын алдым.

**Казылык**

Кызыл камыт эчендә
Кыз ризыгы ятадыр.

**Кабыклап пешерелгән бәрәңге**

Җир астында тун тышладым,
Өстәлгә мендем — туным
ташладым.

**Тоз**

Суда туа,
Суга керсә үлә.

Ак көчегем аштан калмый.

Мине тотып ашамыйлар,
Миннән башка туй да
ясамыйлар.

**Ашка тоз салу**

Идел төбенә таш салдым.

**Борыч тарту**

Зер-зер, зертеки,
Зертеки дә пертеки,
Әпечтеки-печтеки,
Аннан туган кечтеки.

**Борычны ашка салу**

Ашка салсаң — тәм кертә,
Борынга салсаң — төчкертә.

**Лавр яфрагы**

Пешермәсәң — ашарга
ярамый,
Пешерсәң — ташларга туры
килә.

**Шикәр**

Читтән карасам — аклы,
Татып карасам — татлы.

Кар түгел — ак,
Боз түгел — каты,
Тоз түгел — эри.

**Шикәр комы һәм тоз**

Икесе дә — ак,
Икесе дә — вак,
Аерыйм дисәң — кап!

**Гөбедә май язу**

Баз эчендә аю улый.

Тирән баз,
Баз эчендә саз,
Саз эчендә сары таз.

**Сепаратта сөт аерту**

Ак сыерым — куш имчәк,
Бер имчәгеннән сөт бирә,
Икенчесеннән — каймак.

**Гөбедә кымыз шапыру**

Әби акыра,
Бабай шапыра.

**Кымыз**

Пешәләр, пешәләр,*
Аннан коеп эчәләр.

**Көрәгәдә бал әчү**

Базда сары айгырым кешни.

Сары-сары балавыз,
Балавызның каны бар,
Усал дигән даны бар.

**Аракы**

Кеше нәфсен алдаткыч,
Алданганны көлдергеч,
Кесәләрне бөлдергеч.

Тышы — пыяла,
Эче — дивана.

Башта бармак чирттерә,
Аннан артка типтерә.

**Ашамлык, ашау**

Чолт итә дә чалт итә,
Соңга таба ялт итә.

**Ашау**

Утыз кеше арыш суга,
Сөләйман көлтә әйләндерә.

Ак тунлылар арыш суга,
Кызыл тунлы көлтә ташый.

Аппак-аппак әбкәйләр
Тезелеп әвен сугалар,
Әндәр карт көлтә әйләндерә.

Ун утызга бирер,
Утыз Тәлпәчкә бирер,
Тәлпәч ярга бирер,
Яр шудыра бирер.

Ләбәтәй, ләбәтәй,
Тау астына тәгрәтәй.

Әскәтердән алдым,
Тегермәнгә салдым,
Капчыгымны тутырдым,
Капчыгымны тутыргачтын
Ах-вах килеп утырдым.

**Тәмәке тарту**

Авыздан керә, борыннан чыга.

Мунча мичемнең өч моржасы
бар,
Икесе төтен кайтара.

**Челем**

Агач казанда боткам көя,
Эткә куйсам, эт җими*.

## ЭЛЕККЕ КУЛ ЭШЛӘРЕ: ТАЛКУ, ЭРЛӘҮ, ТУКУ, ТЕГҮ-ЧИГҮ, КИЕМ-САЛЫМ, БИЗӘНҮ-ТӨЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕ

**Киндер, җитен талку**

Ак көчегем нак-нак итә,
Колаклары шак-шак итә.

Авылдагы карт әби
Тай сөяге сындыра.

Читән артыннан эт сөяк тарта.

**Сүс төю**

Дөп-дөп, дөп әңгели-мәңгели,
Көш-көш, көшәңгели-мәңгели,
Указ-муказ, торна-каз,
Сиксән җиде бармагы,
Утыз ике тырнагы.

**Каба***

Юкәгә утырдым,
Өрәңгегә карадым.

Әби тарагы — илле теш.

**Каба һәм көнҗәлә***

Кырык киртә арасына
Эт эчәге кысылган.

Әбием башында — ак төенчек.

**Кабада сүс яки йон эрләү**

Утыртма читән арасыннан
Кәҗә печән суыра.

Зур ак төен эченнән,
Тартсаң, сансыз кыл чыга.

Иртән тора да әби бабайның
сакалына ябыша.

**Орчык белән йон эрләү**

Утырдым төпкә,
Карадым мүккә,
Тоттым ак каен,
Яладым маен.

Берәү сава,
Берәү имә,
Идән буйлап йөгерә,
Имә-имә симерә.

**Орчык**

Бәләкәй генә әби
Йөгерә-йөгерә йон җыяр.

Зыр-зыр әйләнә,
Үзе килеп бәйләнә.

Кечкенә генә таем бар,
Бәйдә торып симерә.

**Орчыкбаш**

Бәләкәй генә йомры баш,
Эче куыш, тышы таш.

**Йомгак**

Әйләнгән саен калыная.

Койрыгыннан тартсаң,
эчәгесе чыгып бетә.

**Оек-бияләй бәйләү**

Дүрт татар читән үрә,
Берсе арада йөри.

Дүрт агай кое казый,
Берсе бура меңгерә.

Аркан урадым,
Бура бурадым,
Җылысына куандым.

**Калдырча***

Кылдыр-кылдыр кодача,
Бармагына җеп аса.

Дүрт кодача куыша,
Берсен-берсе тоталмый.

**Тәбәлдерек***

Бассам, барыклы,
Тисәм, тырыклы.

Салдым-салдым салакка,
Салып элдем беләккә;
Тәкә мөгезенә урый-урый,
Янә салдым беләккә.

**Киндер сугу**

Чытырманның арасына
Шома таяк ташладым.

Чүрәкәй үрдәк чума бара,
Артыннан боз туңа бара.

Такыр-токыр тыкырдар,
Баскан саен шыкырдар,
Яссы ятыр, йомры атыр,
Сыерчыклар чыкырдар.

**Туку станогында аю башы***

Бер аюның дүрт күзе.

**Туку станогындагы соса**

Сукыр тәкә текмә үтәли
сикерә.

**Энә**

Бер кечкенә бизәр*
Дөньяны бизәр,
Үзе ялангач гизәр.

Бездә бер кеше бар,
Маңгаенда бер күзе бар.

**Энә белән җеп**

Күк тәкәмнең койрыгы
кырык колач.

Башы — тимер, сакалы — сүс.

Күк бия аркан сөйри.

**Уймак**

Үзе бер, күзе мең.

Бер ишеге,
Кырык тишеге.

**Уймак кию**

Уртанчы улым сугышка
барса,
Тимер бүреген онытмый.

**Кайчы**

Ике оч, ике балдак,
Уртасында бер кадак.

Җиңги куш бармагын ачса,
Абзый авызын ача,
Җиңги йомса — йома.

**Кайчы һәм энә**

Агасы кыя торыр,
Энесе җыя торыр.

**Тегү машинасы**

Тек-тек итәр,
Текмештән китәр.

**Тегү**

Ай киттем, ел киттем,
Энә буе җир киттем.

Тимер чыпчык, сүс койрык,
Әйләнә дә боз тишә.

**Чигү, каю**

Чытыр-мытыр өстеннән
Тимер таяк ыргыттым.

Яшь киленнең мендәрендә
Яшел-ала корт йөри.

**Кәрҗин үрү**

Алам-салам өздем,
Чытыр-мытыр үрдем.

**Чабата ясау, шөшле**

Бабай сыңар тырнагы белән
кашый,
Кашый да йодрыгы белән
шакый,

Бер көн, бер төн утырдым,
Шакмаклы киндер тукыдым.

**Кием**

Үңәче бар, муены юк,
Гәүдәсе бар, буе юк,
Җиңнәре бар, кулы юк.

**Кием, гәүдә**

Бурасы туза,
Баганасы кала.

**Тун**

Бер ягы кыр, бер ягы урман.

**Камзул**

Биле бормалы,
Чите укалы,
Үзе бәһале.

**Халат**

Җиңе бар — күлмәк түгел,
Бавы бар — алъяпкыч түгел.

**Күлмәк кию**

Бер ишектән керәсең,
Өч ишектән чыгасың.

**Чалбар**

Ике тавык бер төптә,
Аерылмыйлар бөртек тә.

**Чалбар кию**

Юлга чыктым,
Ике юл чатына җиттем,
Берьюлы икесе буйлап киттем.

**Төймә**

Түгәрәк күлдә дүрт бәке.

**Каптырма**

Эләктерде, каптырды,
Чабуымны тарттырды.

**Булавка**

Башында мие булмаса да,
кешегә кирәк.

**Шарф**

Алды да койрык,
Арты да койрык.

**Калфак**

Өй түбәсендә — бозлы киле,
Аны белмәгән тиле.

**Колакчын бүрек**

Колаклы ябалак кыштан
саклый.

**Бүрек кигән кеше**

Кечкенә генә лапас астында

ике аяклы багана.

**Чалма**

Ул нидер, әйт: актан ак,
Казык башындагы кап.

**Зонтик**

Җәеп тотсаң — табактай,
Җыеп тотсаң — таяктай.

Өстән су ага,
Астан кеше бара.

**Чабата**

Бер тычканга ике койрык.

Башы бар — акылы юк,
Биле бар — карыны юк,
Койрыгы бар — йоны юк,
Үзе бара — җаны юк.

Җиз мыеклы җизнәм килгән,
Шакмаклы күлмәк кигән,
Үзе түргә узмый.

**Чабата эзе**

Әбиләргә барган чакта
Шакмак шәлем төшеп калды.

Юлдан барган апасы,
Тезеп шахмат тактасы.

**Киез ката, башмак, кәвеш**

Мич астында пар көчек.

Кара сарык,
Карыны ярык.

**Резин кәвеш**

Эче кызыл, тышы кара,
Ул ни булыр, атлап кара,
Табалмасаң, таптап кара.

**Киез итек**

Кара тавык кар ера.

Җәй көне чоланда ята,
Кыш көне бездән калмый.

**Итек**

Башы бар, авызы юк,
Җылысы бар, миче юк.

**Пар итек**

Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән.

**Итек һәм аяк**

Базы туза, баганасы кала.

**Итек үкчәсендәге кадак**

Йөрим мин яланаяк,
Йөрсәм дә итек белән.
Йөрим мин баш белән,
Йөрсәм дә аяк белән.

**Итек яки оек кию**

Берсе ашаганчы икенчесе
көтеп тора.

**Йон оек өстеннән**
**күн итек кию**

Сыер сарыкны йоткан.

**Аяк киенү һәм чишенү**

Иртән дә мыштыр,
Кич тә мыштыр,
Син дә мыштыр,
Мин дә мыштыр.

**Тире бияләй**

Эче мамык, тышы кабык.

**Йон бияләй**

Биш егеткә бер колакчын,
Аны белмәгән читкә олаксын.

**Бияләй кию**

Дүртәү өйгә уза,
Берәү чоланга керә.

**Пирчәткә**

Бер агачта биш тармак,
Тармагы саен бармак.

**Бәләк**

Чәп-чәп чәпим,
Тук-тук тукыйм,
Бер сүз әйтмим,
Син әйт, кем мин?

Шап-шап шапылдык,
Басма өстендә тапылдык.

**Сабын**

Ак ташым күбек коса.

**Сабын, балык**

Аттым таш,
Тоттым кош;
Атканым таш түгел,
Тотканым кош түгел:
Таш дигәнем күбек булды,
Кош дигәнем үлек булды.

**Үтүк**

Кораб йөзә килә,
Күлне көйдерә килә.

Кызу табанлы чана,
Ат җигелмәгән аңа,
Бер чигенә, бер бара,
Юлы шомарып кала.

**Чулпы, чәчтакма, сапма тәңкәләр**

Чук чукладым, тезгә җитми;
Тамчы тама, җиргә җитми.

**Чулпы, чәч толымы**

Күгәрчен кайда гөрлидер? —
Тау башында гөрлидер.
Очлап ишкән кыл аркан,
Очы анда борныйдыр.

**Чәчүргеч тасма**

Ике солдат бер билбау
бәйләгән.

Кара урманның очларын
Ефәк белән чукладым.

**Алка**

Тамчылары ялтырый,
Тамалмыйча калтырый.

**Алка һәм беләзек**

Тамчы тама, җиргә җитми,
Хан билбавы билгә җитми.

**Беләзек**

Ит бүкәндә җиз кыршавым,
Ул да булса өзелгән.

**Беләзек һәм чулпы**

Билбавы биленә җитми,
Койрыгы тезенә җитми.

**Балдак-йөзек һәм бармак**

Төпсез тәпәнгә ит тозладым.

Мәскәүдән килгән бүләк,
Ун өйгә кунак.

**Тарак**

Кечкенә генә тулпар,
Тауга менәр, таудан төшәр,
Урман эчләп юртар.

Дөньяда бар бер малай,
Тырнагы мең — ергалай;
Тау башына менә дә,
Сөрмәгән җир тырмалай.

**Агач тарак**

Эреле-ваклы,
Дүрт яңаклы.

**Иннек-кершән ягыну**

Акка кызыл тама.

Багана башына кар яуган,
Кар өстенә кан тамган.

## РУХИ ТОРМЫШ: ДИН, ӘДӘБИЯТ, УКУ-ЯЗУ, КУЛЬТУРА-КӨНКҮРЕШ ӘЙБЕРЛӘРЕ, УЕН КОРАЛЛАРЫ

**Адәм пәйгамбәр**

Тумады, үлде.*

**Мөхәммәд пәйгамбәр, аның дүрт юлдашы***

Бар икән, ди, дөньяда бер

байтирәк,
Гәүһәрдән дүрт ботагы аңа
терәк;
Табышмагым уйла да тап,
уйна да тап,
Моны тапкан кешенең акылы
зирәк.

**Коръән**

Алтын белән уралган,
Көмеш белән чорналган,
Күп илләрдә йөрегән,
Күп кешегә тимәгән.

**Кәүсәр сүрәсе һәм инҗир җимеше**

Сүрәдә — «мим»сез*,
Мивәдә — гөлсез*.

**Биш вакыт намаз**

Бар, имеш, ди, биш җимеш:
Икесе — төн йөзе күрмеш,
Өчесе — көн йөзе күрмеш.

**Мәчет**

Биек-биек диярләр,
Габделваһап диярләр;
Моны белгән кешеләргә
Бик күп савап диярләр.

Алтын ияр — башы,
Көмеш йөзек — кашы;
Аны белгән кеше —
Йөз илледә яше.

**Мәчет, мулла**

Бура-бура диярләр,
Бура эчендә Габдрахман
диярләр,
Габдрахманны белгән кеше —
Нәселе яхшы диярләр.

**Мәчет манарасы**

Биек-биек кыялар,
Анда кошлар оялар.

**Әүлия**

Кайда сөйләшсәң дә ишетә.

**Шайтан**

Исеме бар, үзе юк.

**Аждаһа**

Авызын ачар,
Утлар чәчәр,
Күргән һәркем аннан качар.

**Мәкаль**

Утыз тештән чыккан — утыз
адәмгә җәелә.

**Җыр**

Күңелсезгә — юаныч,
Күңеллегә — куаныч.

**Әкият**

Ишеттем бер чын ялган,
Ата-бабадан калган,
Шундый кызык ул ялган —
Төбен белмисең алдан,
Мин сөйләсәм, син ышан,
Ышанмасаң, үзең карган.

**Табышмак**

Акыллыга әйттем,—
Уйлады да белде;
Акылсызга әйттем,—
Тыңлады да көлде.

Әйткәч, beләсегез килә,
Белгәч, көләсегез килә.

**Каләм**

Җаны юк, үзе кырык төрле
тел белә.

Үзе укый белмәсә дә,
Гомер буе язына.

Кәгазь өстен карайта,
Дөнья йөзен агарта.

Авызы бер-бер башланыр,
Теле ике ташланыр,
Аны белмәгән кешенең
Ике күзе яшьләнер.

**Каурый каләм**

Каз канаты кавырсын,
Тотсаң, акыл алырсың.

Бер кош бар — телен телгән,
Кулга алып сөйләштерсәң,
Җитмеш төрле тел белгән.

**Камыш каләм**

Озындыр, камыштыр,
карыштыр башы,
Керәдер, чыгадыр, агадыр
яше.

**Авторучка**

Берьюлы эчәм,
Тамчылап бирәм.

**Каләм белән кара**

Ак казым пыяла коедан су
эчә.

**Каләм, язу**

Алдан таяк йөгерә,
Арттан елан йөгерә.

**Кара һәм кара савыты**

Менә табышмак, уйлап кара:
Суы тәмсез, йөзе кара,
Чиләгенең төбе юк,
Файдасының чиге юк.

**Язу**

Ак ялан үттем,
Кара ефәк сүттем.

**Зәгъфран кара* белән язу**

Ак кар өстенә сары солы
чәчтем.

**Язу, уку**

Иген чәчте биш малай,
Урдылар ике агай.

**Кәгазь, язу, уку**

Җире ак, орлыгы кара,
Кул белән чәчәләр,
Авыз белән җыялар.

Ак җир, кара тары,
Кем чәчсә, шул урыр.

**Китап**

Агач түгел — яфраклы,
Тун түгел — тегелгән.

Кечкенә генә сандыкка
бөтен дөнья сыйган.

Кат-кат катлама,
Акылың булса, ташлама.

Киштә башында төпле төргәк,
Аңа һәр өйдә хөрмәт,
Һәркемгә дә иң кирәк.

**Календарь**

Кабат-кабат,
Бер кошта өч йөз алтмыш
биш канат,
Мин торам аны санап,
Көн дә кими бер канат.

**Белем**

Бер байлык бар — янмый,
Карак та урлый алмый,
Төшеп тә югалмый.

**Кара такта, акбур**

Кара кыр буйлап ак куян
чаба.

**География картасы**

Диңгезе бар, суы юк,
Шәһәре бар, халкы юк.

**Глобус**

Бабай бүрегә йөз ямау.

**Циркуль (җәзбә)**

Әйләнеп чыкса, шар ясый.

**Хат**

Ак җир ачтым,
Кара бодай чәчтем,
Җаный белән сөйләштем.

Дүрт почмаклы келәтем,—
Аккошым бар эчендә;
Кеше алыр дип кайгым юк,—
Тамгасы бар түшендә.

**Сургуч**

Элек яна, пешерә,
Соңыннан бар серне яшерә.

Ул нидеркем, ал булыр,
Ал иреннән бал булыр,
Кулым сузсам алмага,
Кулым тулы кан булыр.

**Телеграмма**

Агач, ди, аты,
Тимер, ди, заты,
Эчендә бар, ди, хаты.

**Телеграмм баганасы**

Далада торган ку* агач
Яфрак ярса — ярамас,
Кылыч чапсаң — канамас;
Бер ботагын карасаң,—
Петербур белән чамалаш;
Бер ботагын карасаң,—
Казан белән аралаш.

**Телефон**

Үзе монда утыра,
Сүзне тегендә тутыра.

**Телефон һәм радио**

Колагы юк — ишетә,
Авызы юк — сөйли.

**Патефон**

Бик чибәр кыз Мәликә
Тоткан кара тәлинкә,—
Өсте тулы сыр икән,
Эче тулы җыр икән.

**Магнитофон**

Попугай түгел — җаны юк,
Әйткән сүзне кабатлый.

**Радиоалгыч**

Кечкенә генә өй,
Эче тулы көй.

Үзе сөйли, үзе җырлый,
Ә үзенең теле юк.

**Телевизор**

Бер көзгегә дөнья сыйган.

**Экран**

Ак ашъяулык яптык,
Эченә бактык,
Бер сәгатьтә кышын да
таптык, язын да таптык.

**Фотоаппарат**

Озын-озын өч аяк,
Өч аягы бер таяк;
Гармун күреге күк үзе,
Маңгаенда бер күзе.

Кечкенә генә үзе,
Маңгаенда бер күзе,
Күрсә, онытмый үзе.

**Фоторәсем**

Кешесе бар, җаны юк.

Үзе миңа карап тора,
Үзе мине күрми.

**Курчак**

Минем белән уйныйлар,
Кулларыннан куймыйлар,
Иркәлиләр, сөяләр,
Йокла, иркәм, дияләр.

**Уенчык туп**

Үзе кеп-кечкенә,
Үзе миннән биек сикерә.

**Бөтерчек**

Түм-түгәрәк, кып-кызыл,
Әйләнәдер зыр да зыр.

**Курай**

Аягын-башын кистем.
Корсагын тиштем,
Эченә өрдем,
Моңайганын күрдем.

**Агач кубыз**

Дыр-дыр, дыр имән,
Ник дырылдый бу имән,
Әллә бизгәк тотамы?

**Тимер кубыз**

Кәкре җадәч кире сикерә.

**Думбра**

Җебенә тисәң — җылаган,
Колагын тотсаң — чыңлаган;
Өстендә бар эчәге,
Астында бар түшәге.

**Скрипка**

Сары сандык сатып алдым,—
Үзе нәни генә,
Төрле тавышка җырлый белә.

Аста да түшәм,
Өстә дә түшәм,
Ә түшәмдә — җыр.

**Гармун**

Сырлы-сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул.

**Барабан**

Җанлы җансызны кыйный,
Җансыз кычкырып җылый.

**Быргы**

Авызы юк — кычкыра,
Теле юк — чакыра.

## ТӨРЛЕЛӘР: ДӨНЬЯ КӨТҮ, АКЧА, ИСӘП-ХИСАП, ҮЛЧӘҮ, ТРАНСПОРТ, СӘНӘГАТЬ, СУГЫШ КОРАЛЛАРЫ

**Дөнья**

Алдаштыра чытырман,
Адаштыра чытырман,
Юл таптыра чытырман.

Һәркем кичкән бер күпер:
Берәүләргә киң күпер,
Берәүләргә тар күпер.

**Дөнья көтүнең авырлыгы**

Ике уникегә җитми,

Унике утыз икегә җитми.*

**Байлык һәм фәкыйрьлек**

Чакырсаң да килми,
Кусаң да китми.

Берсе — бер айлык,
Берсе — саклап тотсаң
гомерлек.

**Акча**

Ансыз дөнья сансыз.

Син аны тота барасың,
Ул синнән кача бара.

Үзе шәпле,
Үзе пичәтле,
Үзе синнән тоттырмаска
исәпли.

Табышмагым тавышлы,
Таба белсәң табышлы,
Тапмаганнар сагышлы.

Янчыкка салсаң — чыга,
Кесәгә салсаң — шуа.

**Көмеш акча**

Түгәрәк кенә ак нәрсә,—
Халык сөюе хак нәрсә.

**Алтын акча**

Сары-сары, сап-сары,
Сагышла да тап аны.

Җир астында тилмертә,
Җиргә чыккач тилертә.

**Янчык**

Чибәр кызыйның авызы
бөрешкән.

**Үлчәү**

Үзе күрми, кешегә күрсәтә,
Үзе өйрәнми, кешегә өйрәтә.

Күрергә күзе юк,
Сөйләргә теле юк,
Үзе саный.

**Ике табаклы үлчәү**

Алты аяк, ике тояк, бер тел;
Тел тибрәнми аяк йөрми,
Ул ни нәрсә, аны бел.

Алты аягы бар,
Талдан таягы бар,
Аркасыннан койрыгы бар,
Хөкемнән бойрыгы бар.

Ике таба талаша,
Берсе: «Минәм»,— ди,
Берсе: «Төшәм»,— ди;
Телләре сөйли,
Үзләре күрми.

**Сыңар табаклы үлчәү**

Күр, Ходайның бойрыгы,—
Түбәсендә койрыгы;
Өч аягы бар,
Сыңар табаны бар.

**Гер (пот, кадак, мыскал*)**

Бер байның кырык баласы,
Һәр баласының туксан алты
баласы.

**Юл**

Җирдә киң тасма ята.

Юзи абый дилбегәсен
Йөз кеше дә җыялмый.

Барасың, барасың,
Башына чыгалмыйсың.

Үзе аранда,
Койрыгы яланда.

**Юл, күбәләк**

Озын-озын очкалак,
Очына-башына кем чыгар?
Чуар-ала кигәннең
Йомыркасын кем табар?

**Юл, тояк эзе**

И уламы, уламы,
Очына җитеп буламы;
Юлда яткан табакны
Алып китеп буламы?

**Юл, чокыр**

Озын арканны җыялмадым,
Зур казанны аударалмадым.

**Чакрым баганасы**

Үзе күрмәсә дә, бүтәннәргә
күрсәтә,
Телсез, колаксыз булса да,
санарга өйрәтә.

**Компас**

Үзе сукыр, кешегә юл
күрсәтергә оста.

**Таяк**

Үзе бара бикәдәй,
Эзе кала тәңкәдәй.

Күзе дә юк, колагы да юк,
Үзе сукырны җитәкли.

**Чаңгы**

Ике тәкә тек итәр,
Этәреп җибәрсәң, китәр.

Чаба килдем, чаба килдем,
Аягыма чана кидем.

Җәй буе ял итәрләр,
Кыш тәпиләп китәрләр.

**Тимераяк**

Иң килә, зиң килә,
Ике тәкә тиң килә;
Берсен-берсе куа килә,
Тояклары шуа килә.

**Авызлык**

Ит казанда тимер кайный.

**Ияр, ыңгырчак**

Аттан биек,
Эттән тәбәнәк.

**Ияр, өзәңге, тезген, камчы**

Утырган җирем — уй чокыр,
Баскан җирем — бай чокыр,
Бер кулымда — каптырым,
Бер кулымда — сыптырым.

**Өзәңге, ияр**

Типтем — тимер,
Утырдым — уек.

**Камчы**

Беләгемә елан ябышкан,
Койрыгы белән атымны чага.

**Атка атланган кеше**

Алты аяклы, ике куллы,
Ике башлы, бер койрыклы.

**Камыт**

Чөй-чөй, чөйдем кош,
Чөй башына кунды кош.

**Дуга**

Ат башында кара көянтә.

**Кыңгырау**

Җиз сарайның эчендә
Җизнәм аты кешнидер.

Тиллим-тиллим көйлимен,
Җиз сарайда биимен.

Атым аранда,
Тавышы яланда.

Җыен-сабан туенда
Көйли киртә буенда.

**Арба**

Ике күчәр —
Дөнья кичәр.

Армый, талмый,
Ат артыннан калмый.

**Арба, чана, ат**

Очырмада өч кошым бар,
Берсе: «Җәйне яратам»,— ди,
Берсе: «Кышны яратам»,— ди,
Берсенә җәй дә бер, кыш та
бер.

**Арба күчәре**

Җәен май эчәр,
Җирне-суны кичәр,
Кышын ял итәр.

**Арба тәгәрмәчләре**

Дүрт туган ике юлда,
Берсен-берсе куып
җиталмыйлар.

Дөбер-дөбер дүртәү,
Агай-эне икәү,
Шабан агай шып-ялгыз.

**Чана**

«На!» — дисәң, бармый,
«Тпру!» — дисәң, туктамый,
Печән салсаң, ашамый.

Арбасы бар, аты юк,
Тәртә-мазар заты юк;
Тоткасына кулың тисә,
Атны да узып китә.

**Велосипед**

Ике аяклы үгез,
Маңгаенда куш мөгез.

**Велосипедта бару**

Үзе атта бара,
Үзе атлап бара.

**Паровоз, поезд**

Хәйран аның йөрүе,
Бик ерактан килүе,
Ай-һай, аның кешнәве,
Аягында тимере,
Тамагында күмере,
Җирне ярып килүе.

Айгыр җиктем камытсыз,
Дилбегәсез, каешсыз;
Шәмәрдәннән киләбез,
Мәскәүгә дә керәбез.

**Паровоз, рельслар**

Кара казанны күтәралмадым,
Тимер дилбегәне җыялмадым.

**Трамвай**

Кылга асылына,
Тимергә таяна.
Утыртып чаба
Теләсәң кая.

**Көймә**

Сукыр дөя суда йөзә.

Үзе бара, эзе юк,
Маңгаенда күзе юк.

**Көймә, ишкәк ишү**

Бара-бара, эзе юк,
Кисә-кисә, каны юк.

Чабам-чабам, йомычкасы юк.

**Җилкәнле көймә**

Җил өрә — үзе бара.

**Пароход**

Агачтыр аты,
Тимердер арты,
Ходайның кодрәте,
Су өстендә миннәте*.

Адәм шулкадәрлегә җитә —
Самавырны да суда йөртә.

**Якорь**

Кирәк чакта ташлыйлар,
Кирәкмәгәндә алалар.

**Самолет**

Канаты бар, йоны юк,
Үзе бара, юлы юк.

Үзе җансыз булса да,
Сәмер кошны* җиткерми.

**Парашют**

Баш очымда чатырым,
Очтым алты чакырым,
Очып төшкәч кайтырым.

**Завод гудогы**

Аю бабай акыра,
Дус-ишләрен чакыра.

**Магнит**

Җаны юк, каны юк,
Үзе тимерне тарта.

**Электр агымы, ток**

Абыйсы булмаса — апасы да юк.
Апасы булмаса — абыйсы да юк,
Икесе бергә — була яшен, ут.

Нечкә-нечкә баулардан
Бик күп атлар чабыша.

**Корыч кою**

Адәм шул хәтлегә җитә:
Ташны ут итә,
Утны су итә,
Ул суны тагын таш итә,
Итә дә өстенә утырып китә.

**Атом энергиясе**

Күрер күзгә күренми,
Капшыйм дисәң, беленми;
Тузан хәтле үзе юк;
Гайрәтенең чиге юк,
Куәтенең тиңе юк.

**Җәя, ук**

Киереп торган нисе икән?
Очып киткән нисе икән?
Барып тигән нисе икән?
Кан чыгарган нисе икән?

**Ук**

Аккош оча,
Аны күргән поса,
Тигәне кара кан коса.

Яртысының яртысы —
Каен агач яртысы;
Яртысының яртысы —
Туң тимернең яртысы;
Яртысының яртысы —
Очкан кошның яртысы.

**Сөңге**

Озын-озын, очлыдыр,
Очлы тимер башлыдыр.

**Чукмар**

Йомры баш,
Җанга кас*.

**Богау**

Челдер-челдер челәктин,
«Челдерт» итә беләктин.

**Мылтык, пуля**

Ашаганы — тимер,
Төкергәне — ут.

Тимер келәт эчендә
Бер котырган эт ята.

**Мылтык төзәү**

Астында беләк була,
Кабыргасында ияк була,
Өстендә күз була,
Үзе төз була.

**Мылтык ату**

Күк көянтәм күкрәде,
Бөтен халык тетрәде.

Алты егет төкерә,
Төкерегә саен кеше үтерә.

**Автомат**

Иртән уемда,
Көндез муенда,
Төнлә куенда.

**Туп-пушка**

Дөбер-дөбер, дөбермән,
Яккан уты күмердән;
Йомыркасы тимердән,
Күкәй сала мөгездән.

**Зенитка**

Бер мөгери,
Мөгезен күккә тери.

## АВАЗ-ХӘРЕФ, СҮЗ-ИҖЕК, МЕТАГРАММАЛАР, ШАРАДАЛАР

**«А» хәрефе**

Мәскәүдә бер дә юк, Казанда
икәү.

**«Б» хәрефе**

Әбидә бер, бабайда ике.

**«З» хәрефе**

Диңгездә бар, суда юк,
Абзарда бар, өйдә юк.

Бездә бар,
Сездә бар,
Илдә юк.

Яз белән көз нәрсә белән тәмамлана?

Казанның уртасында ни бар?

**«Е» хәрефе**

Кое төбендә нәрсә бар?

**«И» хәрефе**

Җирнең уртасында ни бар?

**«К» хәрефе**

Кәҗәнең башында нәрсә бар?

**«Л» хәрефе**

Балда бар, нанда юк,
Алмада бар, ханда юк.

**«М» хәрефе**

Урманда бар, кырда юк,
Мунчада бар, өйдә юк.

**«Н» хәрефе**

Синдә бар, миндә бар —
кешедә юк,
Казанда бар, өйдә юк;
Урманда бар — бер генә,
Җирдә-суда бер дә юк.

**«Р» хәрефе**

Мәскәү илә Казанда юк,
Питербур илә Оренбурда бар;
Ташкент илә Уфада юк,
Әстерхан илә Самарда бар.

**«С» хәрефе**

Сыерда бар, атта юк,
Сарыкта бар, эттә юк.

**«Т» хәрефе**

Тыкрык башында ни бар?

**«Ч» хәрефе**

Чигәдә бар, кашта юк,
Чирәмдә бар, ташта юк.

**«Ш» хәрефе**

Шәһәрдә бар, авылда юк,
Кешедә бар, адәмдә юк.

**«Ю» хәрефе**

Барда юк, юкта бар.

**«Ә» хәрефе**

Тәрәзә төбендә нәрсә бар?
Шуны тап.

**«Ө» хәрефе**

Көн белән төн уртасында
нәрсә бар?

**«Ү» хәрефе**

Күлдә бар, елгада юк,
Үрдәктә бар, казда юк.

**Айдар**

(«ай» һәм «дар»)

Беренче кисәге — җирнең
иярчене;
Икенче кисәге — җәзалау
урыны;
Кушып укыганда — кеше
исеме.

**Аксубай**

(«ак», «су» һәм «бай»)

Бер иҗегем — төс минем;
Икенчесе — сыеклык;
Өченчесе болай ди:
— Безнең авыл бик бай,— ди.

**Акка буягач**

(акчарлак)

Чарлак кайчан кош була?

**Алабуга**

(шәһәр һәм балык исеме)

Нинди шәһәр суда йөзә?

**Алма**

(боерык фигыль һәм җимеш)

Алма дисәң дә алалар,
Нәрсә соң ул, балалар?

**Алтай**

(«ал» һәм «тай»)

Азиядәге бер тауның исемен
алам:
беренче иҗеге — әйбернең
төсен белдерә,
икенче иҗеге —
йорт хайванының исеме.

**Алтын**

(«ал» һәм «тын»)

Беренче иҗеге — боерык
фигыль;
Икенче иҗеге — атау җөмлә;
Икесе бергә — кыйммәтле
металл исеме.

Нинди сүздә алты «н» бар?

**Анам**

(юл башы хәрефләреннән укыла)

Ансыз миңа бу киң дөнья
булды тар,
Насыйп микән миңа аны
күрергә?
Аның хәрефе бу язылган
җирдә бар,
Миңа кирәк шул кемлеген
белергә.

**Аю**

(«а» һәм «ю»)

Һәр хәрефе бер иҗек,
Исеме була ничек?

**Бал, сал, кал**

«Б» белән башласаң — бик
тәмле әйбер;
«С» белән башласаң —
бүрәнәләр бәйләме;
«К» белән башласаң — боерык
фигыль.

**Балта**

(«бал» һәм «та»)

Бер иҗеген ал умартадан,
Икенчесен эзлә партадан;
Бергә кушкач, кем була
дисәң? —
Уйлап кара: мин ярам, кисәм.

**Бал тасына**

(«балтасына»)

Бабай урманга барган,
Бабай балтасын алган.
Бабай урманда бал тапкан,
Аны кая салып кайткан?

**Балык**

(«бал» һәм «Ык»)

Үзе биш хәрефтән тора торган сүз. Баштагы өч хәрефен генә укысаң — татлы әйбер исеме килеп чыга, соңгы ике хәрефе — Татарстандагы елга исеме. Барысы бергә — суда яшәүче, бик тиз йөзүче.

**Без**

(алмашлык һәм тегү коралы)

Без безгә без дибез,
Сез безгә ни дисез?

**«Белән» бәйлеге**

Урман белән тау арасында
нәрсә бар?

**Елга суын эчеп бетереп булмый**

(юнәлеш килештәге «ел» сүзе һәм «елга»)

Ат бер елга өч таз суны
эчеп бетерә аламы?

**Зәй, Хәй, чәй, җәй**

«З» белән башлап —
Татарстандагы елга;
«Х» белән башлап — кеше
исеме;
«Ч» белән башлап — үсемлек;
«Җ» белән башлап — елның
бер вакыты.

**Йозак, тозак**

«Й» белән башласаң —
әйберләрне саклый,
«Т» белән башласаң —
җәнлек ауларга ярый.

**Казан**

(шәһәр һәм савыт)

Бөтен татар өендә бар,
Үзе дөньяда бер генә.

**Камыш, камыт, камыр, камыл**

Күл буенда шаулармын,

«Ш» белән мине язсаң;
Ат муенында булырмын,
«Т» белән алыштырсаң;
Ул урынга «Р» куйсаң,
Кисә аласың токмач;
«Л» белән кырда калам,
Игенне урып-җыйгач.

**Каптырма**

(«кап» һәм «тырма»)

Берсе иген игүчеләргә, икенчесе печән җыючыларга кирәкле ике нәрсәнең исемен бергә кушсак, җиңгиләргә кирәкле бер нәрсәнең исеме килеп чыгар.

**Кара**

(кара төс һәм боерык фигыль)

Кара дисәң, карамый,
Ак дияргә ярамый.

**Карбыз**

(«кар» һәм «боз»)

Кыш көнендә күп була торган ике нәрсәнең исемен бергә тезеп языгыз да, җәй көне күп була торган бер җимеш исеме чыксын.

**Көл, гөл**

«К»дан башлап укысагыз,
Җир ашларга китә,
«Г»дан башлап укысагыз,
Чәчәк атып үсә.

**Күл һәм мәк**

Күлмәкне икегә аерсаң, нәрсә
килеп чыга?

**Май**

Минем белән ул адаш:
Мин — яз ае, ә ул — аш.

**Суд, Чуд**

«С» белән — хөкем итү урыны,
«Ч» белән — күл исеме.

**Суык**

(«су» һәм «Ык»)

Беренче кисәге — сыеклык, икенче кисәге — Татарстандагы елга, кушып укыганда — табигать күренеше.

**Сыерчык**

(«сыер» һәм «чык»)

Беренче иҗеге — хайван,
Икенче иҗеге — боерык фигыль,
Икесе бергә — кош исеме.

**Тапкыр**

(«тап» һәм «кыр»)

Беренче кисәге — боерык фигыль, икенче кисәге — иген үсә торган җир, кушып укыганда — зирәк кеше.

**Ташбака**

(«таш» һәм «бака»)

Исеме ике сүздән кушылган. Беренчесе — җир йөзендә иң күп бер нәрсә, икенчесе — кечкенә бер хайван; икесен бергә җыйганда, өен үзе белән йөртә торган бер хайванның исеме чыксын.

**«Р» хәрефе өстәгәч**

(«тургай»)

Тугай кайчан сайрый?

**Тырнак**

(«тыр-р» һәм «на-а»)

Атлар аңлый торган ике сүзнең ахырына «к» хәрефен кушсаң, адәмнең киссәң дә авыртмый торган бер әгъзасының исеме чыгар. Ул нәрсә?

**Тычкан**

Башы — «т», койрыгы — «н»,
дошманы — «м». Ул нәрсә?

**Урал, Арал**

«У» белән язсаң, тау була,
«А» белән язсаң, диңгез була.

**Фасоль**

(«фа» һәм «соль»)

Түтәлдә нинди ике нота үсә?

**Беренче хәрефләре белән**

Көн белән төн бер-берсеннән
нәрсә белән аерылалар?

**«Өч» һәм «ике» сүзләрендәге хәрефләр саны**

«Өч» дигәндә — ике була,
«Ике» дигәндә — өч була.

**Рәттән ике көн булмый**

(арада төн бар)

Ике көн рәттән яңгыр явамы?

**СОРАУ-ТАБЫШМАКЛАР**

— Нәрсә өстәл янында бигрәк кирәк?
— *Авыз.*

— Нинди савыттан эчеп булмый?
— *Буш савыттан.*

— Кай вакытта куян ите тәмле була?
— *Ашаганда.*

— Бернәрсә дә ашамыйча, ничә йомырка ашап була?
— *Берне.*

— Нәрсә соң ул? Беркемнең дә аны булдырасы килми, Беркемнең дә аннан аерыласы килми.
— *Пеләш баш.*

— Кайчан бернинди тавыш та ишетеп булмый?
— *Тып-тын вакытта.*

— Кайсы ай календарьда юк?
— *Һавадагы ай.*

— Бер якта — поп өе, икенче якта — чәчтарашханәсе. Арада чыга алмаслык сазлык. Поп чәчен алдырырга аръякка ничек чыга?
— *Поп чәчен алдырмый.*

— Патша кемгә баш ия?
— *Чәчтарашка.*

— Бер авыл кешесе ат җигеп калага барган. Барып җиткәч, иң башлап ни дигән?
— *«Тпру!» — дигән.*

— Адәм башына нәрсә куна?
— *Бүрек.*

— Кешегә иң якын әйбер нәрсә?
— *Күлмәк.*

— Кайсы елда кешеләр күбрәк ашый?
— *Кәбисә елда.* (Чөнки бер көне артык.)

— Нәрсәне йомык күз белән дә күреп була?
— *Төшне.*

— Нәрсәне күрү иң җиңел?
— *Кеше гаебен.*

— Аучы мылтык атканда ни өчен бер күзен йома?
— *Икесен дә йомса, бернәрсә дә күрә алмый.*

— Юләр кайчан акыллы була?
— *Тик торганда.*

— Баш чаклы таш белән тәрәзә ватып буламы?
— *Юк.* (Таш чебен башы кадәр генә булырга мөмкин.)

— Ул минем аяк астында, үзе миннән өстә; мин аның аяк астында, мин дә аннан өстә. Бу ничек була?
— *Җир шарының капма-каршы нокталарында торучы ике кеше.*

— Кем үзенең туган көнен дүрт елга бер генә мәртәбә уздыра?
— *29 февральдә туган кеше.*

— Бер кеше утырып тора, ди. Ул торып китсә дә, син аның урынына утыра алмыйсың. Ул кеше

кайда утыра?

— *Синең тезеңдә.*

— Кеше йоклый, төш күрә: бер ягында юлбарыс, икенче ягында текә яр, өченче ягында диңгез, дүртенче ягында куе урман. Бу кеше ничек котыла?

— *Уянып.*

— Рәмзия җиде яше тулгач нишли?

— *Сигезгә чыга.*

— Куян чаба-чаба да, ник артына әйләнеп карый?

— *Артында күзе булмаганга.*

— Ат ни өчен улак янына килә?

— *Улак аның янына килмәгәнгә.*

— Сыер ни өчен ята?

— *Утыра алмаганга.*

— Сыер судан чыккач нишли?

— *Коры җиргә баса.*

— Кәҗә судан ничек чыга?

— *Юешләнеп.*

— Кунган кошны куркытмыйча гына ничек итеп агач ботагын кисеп ташларга?

— *Кош үзе очып киткәч.*

— Нәрсә өстән аска таба үсә?

— *Сакал.*

— Кем ике мәртәбә дөньяга туа?

— *Чебеш.*

— Бүрегенә чыпчык кунганда каравылчы нишли?

— *Йоклый.*

— Кемнең сакалын кырдырырлык та акчасы юк?

— *Кәҗәнең.*

— Яңгыр яуганда куян нинди куак астында утыра?

— *Юеш куак астында.*

— Кара мәче нинди ишектән керә?

— *Ачык ишектән.*

— Каз нигә йөзә?

— *Аягы су төбенә тимәгәнгә.*

— Ат чаба-чаба да, нәрсәдән ары китә алмый?

— *Койрыгыннан.*

— Куянның арт аягы нигә озын?

— *Ал аягы кыска булганга.*

— Алманың яртысы нәрсәгә охшаган?

— *Икенче яртысына.*

— Нинди сорауга бервакытта да «әйе» дип җавап биреп булмый?

— *«Йоклыйсыңмы?» дигән сорауга.* (Йокламаса — «юк» дип җавап бирә, йокласа — җавап бирми.)

— Җир өстендә кешеләр нинди авыру белән бер дә авырмыйлар?

— *Диңгез авыруы белән.*

— Иң җиңелне капка аркылы ыргытып булмый. Нәрсәне?

— *Йонны.*

— Машинаның кайсы тәгәрмәче әйләнми?

— *Запас тәгәрмәче.*

— Көнчыгыш белән көнбатыш арасы ни чаклы?
— *Кояш йөреше белән бер көнлек юл.*

— Суны кайчан иләк белән ташыйлар?
— *Карга әйләнгәч.*

— Су кайда коры була?
— *География картасында.*

— Суда нинди таш булмый?
— *Коры таш.*

— Кара диңгезгә төшкән таш нишли?
— *Юешләнә.*

— Иң әүвәлге чүлмәкне кем яндырган?
— *Ут.*

— Урта урамнан берәү барган. Кибеткә кереп, бер эшләпә сатып алган. Нигә сатып алган?
— *Бушлай бирмәгәнгә.*

— Урманга нәрсә белән баралар?
— *Юл белән.*

— Нинди сәгать тәүлеккә ике генә мәртәбә вакытны дөрес күрсәтә?
— *Туктаган сәгать.*

— Бер имәндә өч ботак, ботак саен өчәр алма. Барысы ничә алма?
— *Имәндә алма булмый.*

— Нинди агач утта янмый?
— *Табагач.*

— Нинди ут яндырмый?
— *Рәсемдәге ут.*

## АРИФМЕТИК ТАБЫШМАКЛАР

Ике кеше, кырдан сарыкларын куып кайтып килгәндә, бер су янында очраштылар. Боларның берсе карт, берсе яшь иде. Карты яшенең сарыкларына карап торды да әйтте: «Ишетәмсең, чибәр егет, әгәр син миңа бер сарыгыңны бирсәң, минем сарыкларым синеке чаклы ике була»,— диде. Егет, башын кашып, азрак уйлап торды да әйтте: «Юк, бабай, болай гаделсезлек булыр. Син үзең миңа бер сарыгыңны бир, ул чагында, икебезнең дә тигез булып, арабызда көнчелек калмас»,— диде.
Минем беләсем килә: боларның ничәшәр сарыгы бар иде?

*(Картның — җиде, егетнең биш сарыгы бар.)*

Бер кеше бер җиргә барырга сәфәргә чыкты. Үзе белән бер бүресе, бер кәҗәсе, янә бер кәбестәсе бар иде. Бара торгач, бер елга аркылы кичәргә кирәк булды. Кичү өчен бер кечкенә көймә генә бар, әлеге нәрсәләрнең барысын бер юлы төяп чыгар хәл юк, берәм-берәм чыгармак кирәк. Әгәр әүвәл бүре-не икенче якка чыгарып куйса, кәҗә белән кәбестә бу якта кала да, кәҗә кәбестәне ашый. Әгәр кәбестәне элгәре чыгарып куйса, бүре белән кәҗә бергә калып, кәҗәне бүре ашый. Әгәр кәҗәне элгәре чыгарып куйса, икенчесен чыгарганда, кәҗә катына йә бүрене, йә кәбестәне чыгарырга кирәк була. Кәбестәне чыгарса — кәҗә кәбестәне ашый; бүрене чыгарса — бүре кәҗәне ашый.
Минем беләсем килә: ул кеше елганы ничек итеп кичәр?

*(Теге якка башта кәҗәне чыгара. Бу ярда бүре белән кәбестә кала. Аннары бүрене алып чыга да кәҗәне кире үзе белән ала. Бүре теге ярда үзе генә кала. Шуннан соң, кәҗәне бу якта калдырып, бүре янына кәбестәне чыгарып куя. Ахырдан кәҗәне алырга чыга.)*

Ике бик шәп атның хуҗалары чабышмакчы булганнар. Бу чабышның кызыгы шул: кемнең аты соңрак килсә, шул атка ун мең сум акча бирергә булганнар. Икесе дә, атларына менеп, чабып китә торган урынга килгәннәр. Чабышырга әмер булган, әмма чабышучылар урыннарыннан кузгалмыйлар да икән.
Бераз торгач, тамаша күрергә килгән кешеләрдән берсе, яннарына барып, чапмауларының сәбәбен сораган. Тегеләр эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлатканнар. Сораучы кеше бары ике генә сүз әйткән. Шуннан соң чабышучылар, атларын бөтен көчләренә кыйный-кыйный, чабып та киткәннәр. Берсенең

аты артта калган, шуңа ун мең сум акча биргәннәр. Әлеге кеше ат хуҗаларына нинди сүзләр әйткән?

*— Атларыгызны алыштырыгыз! — дигән. (Кеше атына күчеп атлангач, һәр хуҗа аны беренче китерергә, шулай итеп, үз атын артта калдырырга тырыша.)*

Бер кеше мең сумга йөз баш мал алган. Ат — илле сум, сыер — утыз сум, сарык биш сум тора. Бу кеше ничә баш ат, ничә баш сыер һәм ничә баш сарык алган?

*(Ун ат, ике сыер, сиксән сигез сарык алган.)*

Бер укучы зоология бакчасына барып кайткан. Иптәшләре аңардан: «Бакчада нәрсәләр күрдең?» — дип сораганнар. Бу укучы:

— Попугайлар, антилопалар, мөгезборыннар күрдем. Ә күпме икәнен үзегез исәпләп белегез. Мин барысы уналты баш, унсигез мөгез һәм илле ике аяк күрдем,— дип җавап кайтарган.

Ул ничә попугай, ничә антилопа һәм ничә мөгезборын күргән?

*(Алты попугай, сигез антилопа, ике мөгезборын күргән.)*

Авылдан килгән бер укучы, шәһәрдә фатир эзләп, бер кешегә кергән. Фатир хуҗасы аңа болай дигән:

— Әүвәлге айда бер сум, икенче айда ике сум, өченче айда өч сум, шулай уникенче айда унике сум түләрсең,— дигән.

Укучы шуңа риза булган, ләкин ул да бер шарт куйган:

— Син,— дигән укучы,— әүвәлге айда миңа ике тиен, икенче айда дүрт тиен, өченче айда сигез тиен, шул рәвешчә һәр ай саен алдагы айдан ике мәртәбә арттырып кайтарып бирерсең,— дигән.

Фатир хуҗасы, моны бик юк кына акчага хисаплап, шуңар риза булган. Бер елдан соң исәпләшкәндә, кемнән күпме акча чыгарга тиеш булыр?

*(Укучыдан — 78 сум, фатир хуҗасыннан 81 сум 90 тиен тиеш була.)*

Берәү улын базарга бер кәрҗин йомырка сатарга җибәрде. Аңар сатарга насыйп булмады: бер исерек, бәрелеп, йомыркаларын ватты. Бала елап, тавыш купты, казыйга хөкемгә килделәр. Казый баладан:

— Кәрҗинеңдә ничә йомырка бар иде? — дип сорады.

Бала әйтте:

— Мин ничә булганын белмим, анам кәрҗингә салганда икешәр-икешәр санады — берәү артты; өчәр-өчәр санады — берәү артты; дүртәр-дүртәр санады — берәү артты; бишәр-бишәр санады — берәү артты; алтышар-алтышар санады — берәү артты; җидешәр-җидешәр санады — артмады, төгәл килде,— диде.

Казый, исәпләп, ничә йомырка икәнен белде дә исеректән түләтте.

Кәрҗиндә барлыгы ничә йомырка булган?

*(Өч йөз бер йомырка булган.)*

Диңгез уртасындагы кечкенә бер утрауда бер көтүче үзенең малларын көтеп йөргәндә, утрауның бер читеннән ут чыгып, җил уңаена иңләп, көтү өстенә килә башлады. Уттан котылырга әмәл юк икәнен белеп, көтүче бер хәйлә корды... Утрау бөтенләй янып бетте, әмма көтүче бөтен көтүне саклап калды.

Бу көтүче нинди хәйлә корган?

*(Алгарак барып, ут төрткән дә шул янып үткән урынга көтүне күчергән.)*

Агачка унике карга кунган. Аучы килеп икесен аткан. Агачта ничә карга калган?

*(Берәү дә калмаган. Икесе егылып төшкән, башкалары очып киткән.)*

Әгәр төнге сәгать уникедә яңгыр яуса, җитмеш ике сәгатьтән соң көн кояшлы булырмы?

*(Җитмеш ике сәгатьтән соң яңадан төнге унике була. Аяз булса да, кояш булмаячак.)*

Утыра, ди, дүрт мәче,
Һәр мәче алдында — өч мәче,

Һәр мәченең койрыгында — бер мәче,
Барысы ничә мәче булган?

*(Дүрт мәче булган. Алар өйнең дүрт почмагында утыралар. Һәр мәче үзенең койрыгында утыра.)*

Очкан өч карга,
Кунганнар талга,
Өчәү кунса, бер тал артып кала,
Берәмләп кунсалар, бер карга артып кала.
Ничә карга, ничә тал?—
Җавабын үзең табып ал.

*(Өч карга, ике тал.)*

Йөз аршинлык баганага таракан менә. Көн буена утыз аршин өскә күтәрелә, әмма төн буена егерме аршин аска төшә. Бу таракан багананың башына ничә көндә менеп җитәр?

*— Сигез көндә. (Баштагы җиде көн һәм җиде төндә җитмеш аршин юл үтә. Сигезенче көнне калган утыз аршинны күтәрелә дә багана башына менеп җитә.)*

Бер малай туган. Әтисе аның туган көне саен дүрт сум акча сала барган. Акча егерме сумга җиткәч, улы өйләнгән. Акча егерме сумга җиткән җитүен, улы ничә яшендә өйләнгән була соң?

*(Егерме яшендә. Ул кәбисә елда, 29 февральдә туган була.)*

Берәүдән: «Син ничә яшьтә?» — дип сораганнар. Ул: «Әгәр дә минем яшемнең яртысына биш саны кушылса, моннан унөч ел элек миңа ничә яшь булганын табарсыз»,— дигән.
Ул хәзер ничә яшьтә була?

*(Утыз алты яшьтә.)*

Бер кеше, сәгать магазинына кереп, сәгатьләр сайлый. Соңыннан, бер сәгатьне күрсәтеп, хуҗадан сорый:
— Кыйммәтме?
— Ике йөз сум.
— Ә монысы?
Монысы йөз генә сум.
— Төрегез алай булса шул йөз сумлыгын.
Ишектән чыгып барганда туктый да яңадан хуҗага әйтә:
— Юк, мин монысын алмыйм, миңа менә бу зуры ошый. Күпме дигән идегез әле?
— Ике йөз сум.
— Мин сезгә бит йөз сум биргән идем.
— Әйе, тагын бер йөз сум тиеш.
— Аның урынына алыгыз бу сәгатьне. Ул да бит йөз сум тора,— ди дә, баштагы сәгатен биреп, икенче сәгатьне алып чыгып китә.
Зур сәгать өчен ул күпме акча түләгән?

*(Йөз сум түләгән.)*

Бер малай велосипедта шәһәргә бара икән. Аңа каршы машина очраган. Анда алты хатын утыра икән. Бер хатынның кәрҗинендә ике тавык, ә икенчесенең бер пар киез итеге бар икән. Барлыгы ничә җан иясе шәһәргә бара?

*(Шәһәргә малай үзе генә бара.
Машинадагылар шәһәрдән кайта.)*

Кышларга киткән казлардан бер төркем каз очып килгәндә, ул казларга каршы бер каз очрап аларга әйтте:
— Әссәләмәгаләйкем, йөз каз! — диде.
Ул төркем казларның берсе җавап биреп әйтте:
— Юк, без йөз каз түгел, без булыр идек йөз каз шул чагында: әгәр дә безнең чаклы тагы да бер булса, тагы да безнең яртыбыз чаклы булса, тагы да безнең чирегебез чаклы булса, аның өстенә син бер каз килеп кушылсаң, йөз каз булырбыз! — диде.
Инде белергә кирәк: ул төркем казлар эчендә ничә каз бар иде.

*(36 каз.)*

Өч сәүдәгәр бик күп мал белән бик ерак шәһәргә ярминкәгә барырга чыктылар, үзләре белән бергә өч хезмәтчеләре бар иде. Аларның хезмәтчеләре, юлга чыккач байларын таламакчы булып, үз араларында сүз куештылар. Ләкин өч бай өч хезмәтче, ике бай ике хезмәтче, бер бай бер хезмәтче бергә булсалар, таларга мөмкин түгел, шулай ук ике бай бер хезмәтче бергә булганда, талар хәл юк. Әмма ул хезмәтчеләр талар шул вакытта: әгәр ике бай өч хезмәтче яки бер бай ике хезмәтче белән бергә ялгыз калсалар... Аннан соң бара торгач, байлары бу хезмәтчеләренең бозык ниятләрен белделәр дә бик саклана башладылар. Алар барып җиттеләр бер иделгә. Кирәк булды иделне кимә белән кичәргә. Бары бер кечкенә кимә бар, ике кешедән артык утырыр хәл юк. Инде ни эшләргә? Иделдән дә кичәргә кирәк, хезмәтчеләргә дә талатмаска кирәк. Әмма көймәче юк, үзләре ишеп чыкмак кирәк.

Идел аркылы ничек кичкәннәр болар? Икәү утырып чыккач, шуларның берсе кире кайтырга тиеш була икенчеләрен алырга.

*(Башта теге якка ике хезмәтче чыгып китә, аннан берсе кире кайта да өченче хезмәтчене дә алып китә, ә үзе бу якка әйләнеп кайта. Шуннан соң монда өч бай, бер хезмәтче, ә аргы якта ике хезмәтче була. Ике бай бергә теге яктагы ике хезмәтче янына чыгалар да, бер бай, бер хезмәтче кире кайталар. Бу якта ике бай, ике хезмәтче була. Аннан ике бай елганы кичеп, теге якта өч бай, бер хезмәтче була. Ул хезмәтче берәм-берәм бу ярда калган ике хезмәтчене күчерә.)*

## ТАБЫШМАК-ӘКИЯТЛӘР
## ҺӘМ ТАБЫШМАК-МӘЗӘКЛӘР

Әүвәл заманда, имеш, иске Казанда, Алтынбәк дигән бер хан булган. Аның өч улы булган, ди. Беркөнне бу хан, диван корып вәзирләре белән утырганда, олы улын каршысына китереп әйткән: «Угылым, сине өйләндермәкче булам, син кем кызын, кайсы кызны аласың килә?» — дип сораган. Олы улы: «Сез кайсы кызны муафикъ күрсәгез, мин дә шул кызны яхшы күрәм»,— дип, җиргә караган. Алтынбәк хан әйткән: «Әй, балам, сүзең дөрес, алай да кыз алырга ихтыярны сиңа бирәм, син кемне теләсәң, мин сиңа шуны алып бирәм»,— дигән. Улы шунда әйткән: «Безнең Казанда Хәсәнбәк морза бар, аның Айсылу атлы бер кызы бар. Минем аласым килгән кыз шушы булыр»,— дигән. Хан: «Яхшы, алып бирермен»,— дип вәгъдә биргән. Олы улы чыгып киткәч, уртанчы улын чакырткан. Хан аңардан: «Нинди кыз аласың килә?» — дип

сорагач, ул да: «Хәсәнбәк морза кызын»,— дип җавап биргән. Хан аңа да шул кызны алып бирергә вәгъдә иткән. Кече улын чакыртып сораса, анысы да: «Айсылуны сөям»,— дип җавап биргәч, хан аңа да шул кызны вәгъдә иткән. Диван таралган. Вәзирләр: «Һай, бу ханыбыз ничек бер кызны өч улына да алып бирмәкче була?» — дип, гаҗәпкә калганнар.

Әмма Алтынбәк хан бик акыллы кеше булган. Хатыны янына кайткан: «Мин,— дигән,— Хәсәнбәк морзаның бердәнбер кызын өч улыма да алып бирергә вәгъдә иттем, син ул кызны күргәнең бармы, шулай ук матурмы, акыллымы?» — дип сораган. Ханбикә: «Күргәнем бар, аның кебек матур, тәрбияле кыз дөньяда булмас»,— дигәч, хан иртәгесен яңадан уллары янына чакырткан. «И улларым, Хәсәнбәк морзаның кызы бер генә. Инде ул кызны берегезгә алып бирсәм, калган икегезгә золым иткән булыр идем. Шуның өчен сезгә миннән хөкем шул: менә сезгә өчегезгә дә берәр мең алтын акча. Өчегез дә хәзер сәфәргә чыгып китегез. Йөргән җирләрегездә һәркайсыгыз дөньяда мин күрмәгән иң гаҗәп ни әйбер тапсагыз, аны шул мең тәңкәгезне биреп сатып алып кайтыгыз. Без монда вәзирләр белән карарбыз, кайсыгызның алып кайтканын иң гаҗәп әйбер итеп тапсак, Хәсәнбәк кызын шуңа алып бирербез»,— дигән.

Ханның уллары: «Яхшы»,— дип, берәр мең алтын, тагын юллык акчалар алып, Казаннан чыгып киткәннәр. Бер ай йөргәч, болар бер җирдә өч юл чатына килеп туктаганнар. Әйткәннәр: «Өчебез өч юлдан өч якка китик. Өч айдан соң әйләнеп килеп, өчебез дә тагын шушы җирдә очрашырбыз»,— дип, билгегә зур гына бер кара таш утыртканнар да саубуллашып өчесе өч якка киткәннәр.

Өч ай үткән. Бер заман бу өч туган, әлеге өч юл чатына әйләнеп кайтып, тагын бер-берсе белән күрешкәннәр. Һәрберсенең кулында үзләре тапкан, дөньяда иң гаҗәп берәр әйбер бар. Шулай болар хәл-әхвәл сорашкач, куанышкач-көлешкәч: «Әйдә, һәркайсыбыз тапкан нәрсәләребезне бер-беребезгә күрсәтешик, кече энебез, иң элек син башла»,— дигәннәр.

Кече энеләре бик матур бер алма чыгарып кулында сикерткән һәм: «Бу гаҗәп хасиятле, тылсымлы асыл алманы мин Алма-Ата базарында бер карт кулында күреп, мең тәңкә биреп сатып алдым. Аның хасияте шул: бер кеше әҗәле җитеп үлсә, ул кешене туфракка куйганчы бу алмадан кисеп ирененә тидерсәләр, ул мәет, яңадан терелеп, тагын гомер итәчәк»,— дигән.

Шунда уртанчы туганнары: «Ул гаҗәп гаҗәпмени, менә гаҗәп кайда! — дип, аркасыннан

капчыгын алып ачып, кош мамыгыннан тукылган гаҗәп матур бер юка келәм чыгарып сүтеп җибәргән.— Менә бу гаҗәп хасиятле, тылсымлы келәм. Мин аны, Ашхабад базарында бер төрекмән карты кулында күреп, көчкә мең тәңкәгә сатулашып алдым. Хасиятлеге шул: бу келәмнең өстенә утырып кая барырга теләсәң, күз ачып йомганчы шунда очыртып илтеп җиткерә»,— дигән.

Шуннан олы агалары торган да: «Ул гаҗәп гаҗәпмени, менә гаҗәп монда,— дип, капчыгыннан бер карыш буйлыгы, көмеш кәлфәрәле, дүрт кырлы бер көзге чыгарган һәм: —Мин Әстерханнан ары Кызлар шәһәренә барып, базарда бер бабай кулында шушы әкәмәт көзгене күргәч, бик нык сатулашып, кулымдагы мең тәңкәмне биреп, көчкә-көчкә генә шуңа күндереп, сатып алдым. Хасияте шул булыр: бу көзгегә кем турында булса да ниятләнеп уйлап карасаң, ул кешең хәзер шушы мәлдә үзе нинди хәлдә булса — көзгедән шул хәлендә күренер»,— дигән.

Шулай дигәч, ике энесе бердән: «Әй, абзый, алай булгач, син хәзер Хәсәнбәк морза кызы Айсылуны күрергә ният ит, без аны шул көзгедән күрик, ни хәлдә икән»,— диешкәннәр. Шулай итеп болар бер заман көзгедән карап җибәрсәләр, Хәсәнбәк морза йорты күренгән. Өй эченә баксалар, ни күзләре белән күрсеннәр, болар сөйгән Айсылу үлеп ята. Кәфенләп тә куйганнар. Әнә боларның атасы Алтынбәк хан да, вәзирләр дә шунда. Бары да кызның җеназасын озатышырга төшкәннәр.

Бу өч туган, бу хәлне күргәч, аһ та ваһ кылә башлаганнар. Олы агалары: «Ичмасам җеназасына да кайтып җитә алмадык!» — дип әйтеп үкенергә дә өлгермәгән, уртанчылары үзенең келәмен сүтеп җәеп җибәргән дә: «Утырыгыз, туганнар, очтык, әле җеназасына кайтып җитәбез!» — дигән. Шулай диюгә, бу өч туган бергәләшеп келәмгә утырып алганнар да: «Их, йә әле, кайда икән син безнең алтын башкалабыз Казан!» — дип, күтәрелеп очып та киткәннәр. Өермә белән очып, давыл белән Казан өстендә ду итеп бер әйләнеп чыгып, Хәсәнбәк морзаның өй алдына килеп төшкәннәр. Күрәләр, Айсылуның җеназасын алып чыгып киләләр. Ханның кече улы, кычкырып: «Әй, җәмәгать, мәетне туфракка куйганчы, тиз генә өйгә алып кертегез»,— дигән. Шулай дигәч, кызны күтәргән кешеләр: «Күрәсең, бу хан уллары үзләре сөйгән Айсылуның йөзен актык мәртәбә күреп каласылары килә торгандыр»,— дип, аны киредән өйгә керткәннәр. Ханның өченче улы, әлеге тылсымлы алманы чыгарып, пычак белән бер матур телем кисеп алып, Айсылуның иренenә тидергән генә икән, кызга шундук җан кереп, күз кабакларын ачып җибәрмәсенме. «Фу, озак йоклаганмын ич!» — дип, урынына торып та утырган. Алтынбәк хан, вәзирләр, моны күреп, бары да гаҗәп-хәйранга калганнар.

Шуннан патшаның олы улы: «Әй, хөрмәтле атабыз, бу кызның терелүенә минем көзгем сәбәпче булды, без аннан караганда, кыз юылып, кәфенләп куелган иде инде. Без, моны күрү белән, тиз генә кайту җаен карадык. Югыйсә бу көзге булмаса, без бу хәлне белмичә, бәлки, әле үз көебезгә берәр ай үткәч кенә кайтып җиткән булыр идек. Ул вакытта бу кыз кабергә күмелү генә түгел, сез инде кырыгын уздыру хәстәрен күрә башлаган булыр идегез. Шулай булгач, үзең хәзер хөкем ит, Айсылу миңа тиеш!» — дигән.

Ул шулай диюгә, уртанчы улы ханга караган: «Әй, хөрмәтле атабыз,— дигән,— дөрес, без кызның үлгәнен абзыйның көзгесеннән күреп белдек, алай да минем тылсымлы келәмем булмаса, без әле ул юл чатлыгыннан бер айсыз монда кайта алмаган булыр идек. Ул чагында кече энебез алманы кыз авызына тидерә алмас, тидерсә дә бер туфракка күмелгән кыз яңадан терелмәс иде. Шулай булгач, үзең күрәсең, кызның терелүенә бары тик минем келәмем сәбәп булды. Хөкем ит, кыз — минеке!» — дигән.

Шуннан ханның кече улы, торып: «Әй, безнең гадел атабыз, олы агамның әйткәне дөрес. Әгәр көзгедән карамасак, без әле кайтырга ашыкмас идек, кыз барыбер күмелгән булыр иде. Тиз кайтырга ул сәбәп булды. Икенче агамның әйткәне дә дөрес. Аның ул хасиятле келәме булмаса, без тагы бер айсыз кайтмас идек, кайтсак та, әгәр дә миндә бу гаҗәп тылсымлы алма булмаса, кыз барыбер терелмәс иде. Шулай булгач, үзең хөкем ит, кыз миңа тиеш!» — дигән. Алтынбәк хан вәзирләренә караган. «Йә, әйтегез: бу өч улымның кайсысының алып кайткан нәрсәсе иң гаҗәп? Хәсәнбәк кызы Айсылуны кайсысына бирик?» — дигән. Вәзирләр, кайсы олы улына, кайсы уртанчыга, кайсы кече улына тиеш дип, өчкә бүленеп, һәркайсы үз сүзен дәлилләргә, исбат итәргә керешкәннәр. Ахырында Алтынбәк хан әйткән: «Дөрес, бу кызга көзгенең дә, келәмнең дә, алманың да файдасы тигән. Ләкин кайсысының файдасы күбрәк тигән, сез миңа шунысын әйтегез: кызны шуңа бирербез»,— дигән.

Йә, әйтегез: кыз кайсына тиеш?

* * *

Урмамбит ханның вәзире аның алдында артыграк акыллы булып кылана башлаган. Хан моны эченә генә салып йөри икән. Беркөнне алар икәү йөрергә чыкканнар. Буа яныннан үткәндә, хан тегерменче картка очрап, араларында шундый сөйләшү булган:

— Әллә-мәллә?

Тегерменче:

— Кәллә-мәллә.

Алты уникегә җитәме?

— Утыз икедән артмый.

— Каз җибәрәм, йолкырсыңмы?

— Мамыгын да калдырмам.

Патша шунда саубуллашып әйткән:

— Әлтер-мелтер.

Тегермәнче аңа:

— Шалтыр-шолтыр,— дип калган. Хан юлда вәзиреннән бу сөйләшү хакында сорагач, вәзир берни дә аңламавын әйткән. Хан, бик кәефе киткәнен белдереп:

— Иртәгә иртәнгә чаклы белеп килсәң — киләсең, белмәсәң — астырам,— дигән. Вәзир өенә кайтып уйлап-уйлап караса да, берни дә чыгаралмаган. Бик кайгыга калган. Бер янчык алтын алып, төнлә тегермәнче карт янына төшкән дә бу сүзләрнең мәгънәсен әйтеп бирүне үтенгән. Тегермәнче аңардан йөз алтын сораган. Вәзир чыгарып бирмичә чарасы юк. Шунда тегермәнче болай аңлаткан: «Хан миңа «әллә-мәллә» диде. Бу аның сәлам бирүе иде, мин «кәллә-мәллә» дидем, сәлам кайтарып алдым».

Икенче сүзне сораганда, тегермәнче вәзирдән тагы йөз алтын алгач әйткән: «Ул сүзнең мәгънәсе шул иде: ул
миннән «алты уникегә җитәме?», ягъни «алты ай эшләгә-
нең уникe ай яшәргә җитәме?» дип сорады, мин «утыз икедән артмый», ягъни «утыз ике тештән — ашаудан артмый» дидем».

— Инде патшаның «каз җибәрәм, йолкырсыңмы» дигәне, аңа каршы синең «мамыгын да калдырмам» дигәнең ни?

Тегермәнче тагын аңардан йөз алтын сораган, вәзир, нихәл итсен, актык йөз тәңкәсен дә чыгарып биргәч, тегермәнче алтынны кулына алып әйткән:

— Әле дә аңламадыгызмыни?

— Юк.

Тегермәнче көлгән дә әйткән:

— Каз дигәне ул сез үзегез буласыз инде, алтыныгыз — мамыгыгыз иде; күрәсез, мин аны сездән берәм-берәм йолкам.

Вәзир, бик кызарып:

— Инде булган эш булган, ахыргы сүзегезне дә әйтеп бирегез, ул «әлтер-мелтер» дигәнгә, сез «шалтыр-шолтыр» дип нәрсә әйттегез?

— Тагын йөз алтын бирегез, әйтермен.

Вәзир, янчыгын кагып:

— Күрәсең ич, бер алтыным да калмады, анысын болай әйт,— дигән.

Тегермәнче риза булмаган:

— Өстегездәге киемнәрегезне салып бирегез, әйтермен.

Вәзир, бичара, бөтен киемнәрен чишенеп тегермәнчегә салып бирмичә булдыра алмаган. Шунда гына тегермәнче әйткән, имеш:

— Хәзер караңгы төште, әлтер-мелтер вакыт, кайтып китәсез, шул.

— Әле бит «шалтыр-шолтырын» әйтмәдең. Анысы нәрсә?

Тегермәнче көлгән дә әйткән:

— Аңламадыгызмыни? Менә хәзер шалтыр-шолтыр кайтып китәсез инде,— дигән.

* * *

Бер көн бер адәм кулына бер йомырка учлады да Хуҗа Насретдин янына килеп әйтте:

— Хуҗа әфәнде, сиңа бер табышмак әйтәм, җавабын белсәң, үзеңә тәбә куырып ашатырмын,— диде.

Хуҗа:

— Сыйфатларын сөйлә, белермен,— дигәч, әлеге адәм әйтте: «Аның эче сары, тышы ак»,— диде.

— Ә-ә, белдем, белдем,— диде Хуҗа, шатланып.— Шалканны уйганнар да эченә зәгъфрән орлыгы тутырып куйганнар.

* * *

Бер патша, йөрергә чыкканда, карт бер игенченең учлап-учлап иген чәчкәнен күргән дә аңардан сораган:

— Ни өчен син бер учны — уңга, бер учны — сулга, берсен алга җибәреп чәчәсең?

Карт аңа җавабында:

— Бер учым — бурыч түлим, икенче учым — әҗәткә бирәм, өченчесе — җилгә,— дигән.

Шул вакыт патша янында вәзире дә булган. Патша юлда кайтканда вәзиреннән картның ник алай җавап бирүен сораса да, ул аңлатып бирә алмаган. Патша алдында бу хурлыгын юар өчен, ул, шул төнне үк карт янына килеп, зур акчалар биреп, теге сүзләрнең җавабын өйрәнгән. Карт аңа әйткән:

— Бурыч түлим дигәнем — хәзер эшкә яраксыз атам-анам бар, алар өлеше өчен чәчәм. Миңа йәш чагымда иткән яхшылыкларын кайтарам. Әҗәткә бирәм дигәнем — улларым ташламаслар, бурычларын үтәп мине карарлар. Җилгә дигәнем — кызларым өчен чәчәм, алар миндә үскәнче генә торырлар да китәрләр,— дигән.

* * *

Берәүнең атасы үләр алдыннан, васыять итеп, аңа болай әйткән, имеш:

— Менә, улым, сиңа йөз тәңкә акча. Шушы байлыгың белән тор, берәүгә дә сәлам бирмә, сиңа үзләре сәлам бирсен; ашаганда бал белән калач кына аша. Шушылай торсаң, шул акчадан йөзгә йөз табышың булыр,— дигән, ди.

Ярый, атасы үлгән моның. Малай хәзер: «Атай шулай кушты»,— дип, берәүгә дә сәлам бирмәгән. Тик гаҗәп, ул сәлам бирмәгәч, кешеләр дә моңа сәлам бирми башлаганнар. Бу һаман бал белән калач кына ашый, эшләр әйбәттән, тик шунысы гаҗәп, бер ел да үтмәгән, атадан калган йөз тәңкә бик тиз бетеп киткән, малай бөлгән.

Инде тәмам фәкыйрьлеккә төшеп аптырагач, малай авылның теге башындагы агасына барып елаган.

Агасы, уйлап торгач:

— Әй, акылсыз баш, син атаңның сүзен аңламагансың, ул сиңа: «Син сабанга бар кешедән дә алда торып чыксаң, берәүгә дә сәлам бирмәссең, синнән соң чыкканнар үзләре сиңа сәлам бирерләр; эшләп, өйгә соңрак кайтып ашасаң, сиңа арыш икмәге дә бал яккан калач кебек тоелыр, алты ай эшләгәнең алты ай ятып ашарга җитсә, йөзгә йөз табышың булыр»,— дип әйткән.

## ИСКӘРМӘЛӘР

5 биткә

*Аман* — имин.

7 биткә

*Җау (йау)* — май.

*Мал бассын* — яшь киленгә әйтелә.

— *Сары май тешләгез!* — «Армый эшләгез!» дигән теләккә җавап итеп әйтәләр.

*Тару булу* — очрау, юлыгу.

*Яшен Алла бирсен!* — Балага исем кушучы теләге.

*Төкле* — төк чыккан, йон баскан. Татарларда бәхет билгесе булып саналган.

*Бер башың мең булгыры!* — Игенчеләр теләге.

8 биткә

*Гомер итегез!* — Яңа өйләнешүчеләргә әйтелә.

*Аягыңа чолганса иде!* — Ягъни бәхете югалмаса иде.

*Гаип* — яшерен, билгесез, күтелмәгән.

*Хозыр ата* — яки Хозыр бабай: легендар пәйгамбәр Хозыр-Ильяс. Ул, имеш, тереклек суы эчеп, мәңге яшәү хәленә ирешкән һәм, хәерче, көтүче, юлчы кыяфәтләренә кереп, изгелекләр эшләп йөри, авыр хәлгә төшкән ялгыз кешеләргә ярдәм күрсәтә.

9 биткә

*Мәзәк* — биредә: яшьләр кичәсе, уен.

*Үзе калыксын* — бала коендырганда әйтелә.

*Кану* — канәгатьләнү.

*Таш булсын* — «каты, нык булсын» мәгънәсендә.

*Тамырына ныклык!* — Чәчкән игеннәргә карата әйтелә.

*Утның күңеле көр булсын!* — Яңа мичне беренче кат кабызганда әйткәннәр. Элек утка табынудан калган теләк.

10 биткә

*Төш булу* — туры килү, тап булу.

*Юсыклы* — тәртипле, әдәпле.

*Борының белән тарт* — «үз каргышың үзеңә» мәгънәсендә.

*Алты өйгә калса иде* — янәсе берәр авыл кешеләре Шүрәлене тотып рәнҗетсәләр, ул аларның авылын шундый сүзләр әйтеп каргый икән. Янгын, су басу, ачлык кебек афәт-казалардан айный алмаучы ярлы, кечкенә авылларны элек «Шүрәле карганган авыл» дип йөрткәннәр.

*Атавыңа чыксын* — Н. Исәнбәт аңлатканча, атау — мәет исеменә атап пешерелгән аш. Кеше кешегә йомыш белән кереп тә, аңа юк кына берәр нәрсәне бирергә кызганганда, шулай әйтеп каргап китәләр. Ягъни ул кызганган нәрсәңне үлгәч мәет ашыңа бирсеннәр.

11 биткә

*Кырык чөй* — тегермәндә су яки җил көчен тегермән ташына тапшыра торган тешле тәгәрмәч. Димәк, ул кырылса, тегермән эшли алмый.

*Күрмәгере* — күрмәсә иде.

12 биткә

*Мур* — үләт чире, эпидемия.

*Чәй орсын* — сый-хөрмәткә начарлык белән җавап кайтаручыга әйтелә. Чәйне олылауны, аны кадерле ризык санауны күрсәтә.

*Кура* — биредә: балчык белән сыланган читән абзар. «Пычрак, кадерсез урын» мәгънәсендә.

*Үзе дә бала күрмәсен* — күгәрчен йомыркаларын алган (йә ваткан) кешене шулай каргый, ди.

*Чыңрак* — күчмә киез өйнең (тирмәнең) түбә тишеге (төнлеге). «Янып, төтенгә әйләнеп күккә оч» мәгънәсендәге каргыш.

13 биткә

*Сәгатьсез китим* — хәзер үк, бер сәгать тә тормыйча.

*Җөда булыйм* — аерылу, мәхрүм булу.

16 биткә

*Елкы елы, Елан елы* һ. б. — элек төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда, киң кулланылган 12 еллык хайван календаре белән бәйле атама. Унике еллык цикл (мөсәл) түбәндәге елларны эченә алган:

*1. Тычкан (Күсе) елы; 2. Сыер (Үгез) елы; 3. Барс елы; 4. Куян елы; 5. Ләү (Аждаһа, Кәлтә, Балык) елы; 6. Елан елы; 7. Ат (Елкы) елы; 8. Куй (Сарык) елы; 9. Маймыл (Мичин, Керпе) елы; 10. Тавык (Әтәч) елы; 11. Эт елы; 12. Дуңгыз елы.*

Бер цикл тәмамлангач, нәкъ шушы тәртиптә яңа цикл башланган. Биш цикл (мөсәл), ягъни 60 ел бер буат (гасыр) тәшкил иткән. Халык һәр елның үзенә бер хикмәте бар дип ышанган һәм бу календарьны үзенең юрауларында киң файдаланган.

*Күк кабагы (капусы)* — дини карашлар буенча, ураза бәйрәменнән бер көн элек — «кадер киче»ндә күк йөзе бик нык актырып китү (зур метеор атылу белән бәйле күренеш). Бу вакытта кеше нинди теләк теләсә, шул кабул була, имеш.

17 биткә

*Шүрәле судан шүрли* — шуңа күрә, шүрәле куа башласа, тиз генә берәр елга аша кичәргә кирәк, ди. Шүрәле, суга керергә куркып, ярда торып кала, ди.

*Давыл чәчәге* — сары чәчәк ата торган бер үлән.

*Ут чәчәге* — вак яфраклы, сары чәчәкле сазлык үсемлеге.

*Елан аягы* — еланның аягы юк.

*Тик ята* — шуңа күрә елан очраганда, аңа «елан» дип түгел,
ә «камчы» дип әйтергә кирәк, ди.

18 биткә

*Карындык* — бала сүрүе.

20 биткә

*Авызлану* — яңа туган баланың беренче тапкыр ризык (бал, май) кабуы.

*Нәзер* — үз өстеңә алган эш, шартлы вәгъдә.

*Эт имчәге* — култык астына чыга торган чуан.

*Җиле* — элмәкле, муенчаклы бау.

*Кыярак* — култык астына яки ботка чыга торган авыртулы шеш, биз.

*Тип* — зур түгәрәк агач яки сөяк кысага тартылган күннән гыйбарәт музыка коралы.

21 биткә

*Айгыр тимрәве* — тирегә кутырлар чыгу белән характерлы булган кычулы авыру.

*Арпа* — биредә: күз кабагындагы май бизләренең эренле ялкынсынуы. Имештер, исемен атасаң, бу авыру тагын да ныграк аза икән.

*Бүре уты* — бүре уы, кычыткан бизгәге.

*Елан карагы* — бармакларга, бигрәк тә күз тирәсенә чыга торган каты шеш.

*Ипи шынасы* — рахит авыруы.

*Суык тоту* — бизгәк.

*Бәхерниса* — бака.

*Теш бакасы* — флюс (бозык теш төбе үлекләп, яңак шешү).

22 биткә

*Сары май күрсәң* — сары төс авыру билгесе дип шомлануга бәйле юрау.

*Сәмруг кош* — бик тиз оча торган куәтле мифик кош, кошлар патшасы. Татар халкы экиятләрендә еш очрый. Сәмер кош дип тә атала.

27 биткә

*Елан елы, Сыер елы* һ. б. 16 биттәге искәрмәне карагыз.

*Илҗен (элҗен) көн* — яңа стиль белән 2 август. Русчасы — Ильин день.

29 биткә

*Рашкы* — ап-ак төстә, бозга охшаш бик вак ярмасыман кар.

31 биткә

*Барс елы, Тычкан елы* һ. б. 16 биткә бирелгән искәрмәне карагыз.

*Йотлык* — кышын, бозлавык вакытта, мал-туарның далада туклана алмау сәбәпле күпләп кырылуы. Афәт, һәлакәт.

33 биткә

*Әчмуха (осьмушка)* — кадакның (400 граммның) сигездән бер өлеше (50 грамм).

35 биткә

*Мәкәрҗә* — Түбән Новгород шәһәре янындагы Макарьевода элек ел саен булып торган ярминкә. Татар сәүдәгәрләре анда бик актив катнашкан.

36 биткә

*Кадер кичәсе* — Рамазан (ураза) аеның 27 кичендә үткәрелә торган дини бәйрәм.

*Дәлеше (дальше)* — аннары, шуннан соң.

39 биткә

*Ясин чыгу* — үлем түшәгендә яткан кешенең гөнаһларын кичерүне сорап дога уку.

*Бишни* — шәмәхә төс.

40 биткә

*Аякчу* — аяк чолгавы, ыштыр.

42 биткә

*Мәкәрҗә* — 35 биттәге искәрмәне карагыз.

48 биткә

*Тирмә* — борынгы күчмә халыкларның җыелма киез өе.

*Кирәгә* — тирмәнең каркасы, аның киезләрен тотып торучы агач челтәре.

*Төнлек* — тирмәнең түбәсендә һава һәм яктылык керү өчен ясалган тишек.

50 биткә

*Кану* — сусау басылу.

*Кодык* — кое.

*Тустак* — кечкенә табак.

*Бу* — биредә: пар, томан күздә тотыла.

51 биткә

*Көпе* — бишмәт.

53 биткә

*Инә* — әни, ана.

*Чарык* — биредә: кул белән әйләндерелә торган түгәрәк ташлы кайрак.

56 биткә

*Куашна (квашня)* — күәс чиләге, әче камыр.

58 биткә

*Тупару* — үтмәсләнү.

63 биткә

*Вәл бәдри, вәл челтәр* — Н. Исәнбәт күрсәтеп үткәнчә, татар теленең диалектларында «бәйләнгән шәл» мәгънәсендәге «вәл» һәм «җәймә» мәгънәсендәге «бәдрига» сүзләре бар.

64 биткә

*Әлиф-лям* — гарәп әлифбасындагы «әлиф» һәм «ләм» хәрефләре. Язуда шуларны белдергән сызыклар күбәләк канатындагы бизәкләргә охшатылган

*Җию* — ашау.

65 биткә

*Тархан* — борынгы Болгар һәм Казан ханлыкларында эре феодаллар йөрткән титул, дәрәҗә. Аны хан алдында аеруча хезмәт күрсәткән өчен биргәннәр. Тарханнарга уңдырышлы туфраклы, урман-суларга бай булган иң яхшы җирләр бүләк ителгән, алар күптөрле өстенлекләр, льготалар белән файдаланганнар. Мәсәлән, тархан бик зур тугыз җинаяте өчен җаваплылыкка тартылмаган. Аның нәселе тугыз буынга кадәр дәүләт налогыннан азат ителгән.

Табышмакта тараканны «тархан» дип атау бу сүзләрнең әйтелешендәге якынлыкка нигезләнгән. Монда шулай ук нечкә юмор да сизелә. Таракан мич башында — (тархан кебек!) иң әйбәт, җылы, аш-суга якын урында яши. Тарханнарның зур байлык белән, күп кешеләр катнашында узган туйларындагы шикелле, тараканнар да мич башында мыж килеп торалар.

66 биткә

*Чирү* — гаскәр.

67 биткә

*Сөләйман* — сөлекне бу исем белән атау алар арасындагы аһәңдәшлек белән аклана. Кайбер легендаларда Сөләйман патшаның (пәйгамбәрнең) тәхете су өстендә эленеп торган булуы хакында да әйтелә.

*Ганбәр ана* — XII гасырда Урта Азиядә яшәгән суфый шагыйрь Сөләйман Бакырганыйның (Хәким атаның) хатыны. 1846 елда Казанда «Хикәйәи Хәким ата» исемле китап дөньяга чыга. Аның эчтәлеге тулысы белән дини легендалар рухында язылган. Ихтимал, башка берәр легендада Ганбәр ананың җәяүләп хаҗга баруы турында да сөйләнәдер. Яки карышлавыкның кайчан да булса изге бөҗәк саналган булуы мөмкин.

*Әфәләм* — әлиф-лям. 64 биттәге искәрмәне карагыз.

68 биткә

*Тисничә* — юнылган юка такта (русча «тес» сүзеннән).

71 биткә

*Талайман* — «талау» сүзеннән исемгә охшатып ясалган.

*Шеш* — «төз, туры» мәгънәсендә. Ит кисәкләрен кидереп утта кыздыру (шашлык ясау) өчен кулланыла торган калын тимер чыбык та «шеш» дип атала. Куян колаклары шуңа охшатылган.

72 биткә

*Җек* — җык, җәфа.

*Тек* — текә.

73 биткә

*Кыйгыр* — карчыганың бер төре. Лачынны шулай атау да очрый.

76 биткә

*Тырантай* — лачынның бер төре. Элек ау кошы буларак файдаланылган.

77 биткә

*Күсә* — сакал-мыек үсми торган ир кеше.

*Йөзлек* — бирендә: сәке кырыен тәшкил иткән такта.

84 биткә

*Тирмә, кирәгә* — 48 биттәге искәрмәләрне карагыз.

86 биткә

*Ишек бавы* — борынгырак заманнарда ишек тоткасы урынына бау файдаланылган. Ул, ишекне тишеп, шуның аркылы үткәрелгән һәм ике башы төенләп куела торган булган. Ишекне ачканда-япканда бау эчкә-тышка шуып йөргән.

87 биткә

*Өстәлгә җәелдем* — бу табышмакта җәймәнең ничек әзерләнү процессы тасвирлана (киндерне йолку, талку, эрләү, туку һ. б.)

89 биткә

*Чырак* — элекке заманда, лампалар һәм шәмдәлләр киң таралганга кадәр, өйләрне чыра яндырып яктырткannар. Янгын чыгу куркынычы булмасын өчен, озын итеп теленгән чыраның бер башын тимер кыстыргычка беркеткәннәр, ә аска зур савыт белән су куйганнар. Табышмакта әнә шундый җайланма сурәтләнә.

92 биткә

*Ялбыр* — йөнтәс, сәләмә.

95 биткә

*Уртасы — иһа-һайлы* — бу табышмакта һөнәрченең иләкне ничек ясавы тасвирланган. Башта ул урманга барып агачтан юкә төшерә, өенә кайткач, шул юкәдән иләкнең кысасын тегә. Ә уртадагы челтәрен ат кылыннан ясый. Соңгысы кыл дип турыдан-туры әйтелмәгән, ә материалның атка бәйләнешле икәненә ишарәләп, кешнәү авазы (иһа-һай) телгә алынган.

*Кисап* — «киле» һәм «сап» сүзләреннән ясалган; төйгеч.

96 биткә

*Кәпәч* — түбәтәй, кәләпүш.

98 биткә

*Пешү* — туглау, шапыру, атлау.

99 биткә

*Каба* — җеп эрләү өчен йон, сүс, мамыкны беркетә торган тараклы такта җайланма. Аның утыра торган җирен — йомшак агачтан (юкәдән), тарагын каты агачтан (өрәңгедән) ясаганнар.

*Көнҗәлә* — бирендә: эрләү өчен кабага беркетелгән йон бәйләме.

100 биткә

*Калдырча* — киндер сугу өчен шүрегә җеп чорный торган җайланма.

*Тәбәлдерек* — туку станогының аяк белән басып көреләрне хәрәкәткә китерә торган кечерәк тактасы.

*Аю башы* — туку станогында буй җепне нигытып кую һәм сугылган киндерне урау өчен кечкенә вал.

*Бизәр* — бизәүче.

104 биткә

*Тумады, үлде* — дини легендалар буенча, җирдәге беренче кешене — Адәм пәйгамбәрне — Аллаһ балчыктан яраткан.

*Дүрт юлдаш* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүрт көрәштәше (сәхабәләре): Әбүбәкер, Госман, Гомәр, Гали.

*«Мим»сез, гөлсез* — Коръәндәге Кәүсәр сүрәсе текстында «м» хәрефе юк, ягъни, ул «мим»сез, ә җимешләр арасында гөлсез үсә торганы — инҗир җимеше.

105 биткә

*Туфанда Нух кимәсе* — дини мифологиядә: кешеләрнең гөнаһлары өчен ачуланып, Аллаһ җир йөзенә туфан (зур су баскыны) җибәргән. Нух пәйгамбәр, зур көймә ясап, үзенең гаиләсе һәм хайваннары белән котылып калган. Билгеле инде, балыкка туфан куркыныч түгел, аны көймәгә алу кирәк булмаган.

106 биткә

*Зәгъфран кара* — зәгъфран үсемлеге порошогыннан ясалган кызгылт-сары төстәге язу карасы. Борынгы заманда язуда киң кулланылган.

107 биткә

*Ку* — корыган.

109 биткә

*Утыз икегә җитми* — игенченең җәйге ике айда эшләгәне ел буе ашарга (утыз ике тешкә) җитмәве күздә тотыла.

110 биткә

*Мыскал* — авырлык үлчәве (4,25 грамм).

112 биткә

*Миннәт* — рәхмәт. Биредә: рәхәт, файда мәгънәсендә.

*Сәмер кош* — Сәмруг кош. 22 биткә бирелгән искәрмәне карагыз.

113 биткә

*Кас (касд)* — каныгу, үчегү, явыз ниятлелек.

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге.— Казан, 1989.— Т.1; Казан, 1990.— Т. 2.

*Мәхмүтов Х. Ш.* Ел тәүлеге — 12 ай.— Казан, 1991.

Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре/ Төз. Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова.— Казан, 1957.

Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр/ Төз. Х. Ш. Мәхмүтов.— Казан, 1987.

Татар халык иҗаты: Табышмаклар/ Төз. Х. Ш. Мәхмүтов.— Казан, 1977.

Татар халык мәкальләре/ Җыючысы һәм төз. Н. Исәнбәт.— Казан, 1959.— Т. 1; Казан, 1963.— Т. 2; Казан, 1967.— Т. 3.

Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре/ Төз. Х. Ярми.— Казан, 1960.

Татар халык табышмаклары/ Җыючысы һәм төз. Н. Исәнбәт.— Казан, 1970.

Төш юрау китабы/ Төз. М. Әхмәтҗанов.— Казан, 1991.

# Эчтәлек

*Кереш* ..............................................................

***I бүлек***

**Сөйгәнгә — алкыш, сөймәгәнгә — каргыш**

Изге теләкләр ..................................................

Яман теләкләр .................................................

Антлар .........................................................

***II бүлек***

**Юраганың юш булсын, курыкканың буш булсын**

Мифик затларга, табигать көчләренә, аерым ел, ай, көннәргә кагылышлы юрау-ышанулар .................................

Төрле агачлар, үләннәр белән бәйле юрау-ышанулар ........

Хайваннар, кошлар, бөҗәкләр белән бәйле юрау-ышанулар

Кешенең тән төзелеше һәм физик халәтенә кагылышлы юрау-ышанулар ................................................

Тормыш-көнкүреш фактларына нигезләнгән юрау-ышанулар

Халык медицинасына кергән кайбер юрау-ышанулар ......

Төш юрау үрнәкләре ..........................................

***III бүлек***

**Ай колакланса — аязга**

Һава торышы ничек булачагын сынау .........................
Күк җисемнәре, табигать күренешләре буенча ...........
Еллар, ел фасыллары, айлар, көннәр, тәүлекнең төрле вакытлары буенча ...........................................
Ут-су, табигатьтәге һәм көнкүрештәге әйберләр буенча ..
Үләннәр, куаклар, агачлар буенча ..........................
Хайваннар, кошлар, бөҗәкләр буенча ......................
Кеше әгъзалары буенча .....................................
Ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышы ничек булачагын сынау ...........................................................
Күк җисемнәре, табигать күренешләре буенча ...........
Еллар, ел фасыллары, айлар, көннәр буенча ...............
Үләннәр, куаклар, агачлар буенча ..........................
Хайваннар, кошлар, бөҗәкләр буенча ......................

***IV бүлек***

**Әзер җаваплар**

Сорауның асылыннан читкә китү .............................
Урынсыз тәкъдим, үпкә-дәгъваларны кире кагу .............

***V бүлек***

**Тапкырларга — табышмак**

Күк җисемнәре; җир, су, казылмалар; ел тәүлеге, табигать күренешләре .....................................................
Агачлар, җиләк-җимешләр, урман эше; үсемлекләр, печән эше; игенчелек, яшелчәләр ....................................
Бөҗәкләр, сөйрәлүчеләр, җир-су хайваннары, кош-корт, җәнлекләр, йорт хайваннары .................................
Кеше: аның тән төзелеше; гаилә, туганлык ................
Авыл, каралты: өй, җиһазлар, яктырту һәм җылыту әйберләре .......................................................
Савыт-саба, ризык әзерләү, ашау-эчү .........................
Элекке кул эшләре: талку, эрләү, туку, тегү-чигү, кием-салым, бизәнү-төзәнү әйберләре .......................................
Рухи тормыш: дин, әдәбият, уку-язу, культура-көнкүреш әйберләре, уен кораллары ...................................
Төрлеләр: дөнья көтү, акча, исәп-хисап, үлчәү, транспорт, сәнәгать, сугыш кораллары ...................................
Авыз-хәреф, сүз-иҗек, метаграммалар, шарадалар ..........
Сорау-табышмаклар .............................................
Арифметик табышмаклар .....................................
*Искәрмәләр* .........................................................
*Файдаланылган чыганаклар* ......................................

**Ай** колакланса, ни була? Халык афоризмнары. Берен-че китап.— Казан: Мәгариф, 2002.— 143 б.
ISBN 5-7761-0829-4

«Мәгариф» нәшрияты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге белән берлектә, «Энҗе чәчтем — энҗе җыям» дигән гомуми исем астында, татар фольклорының иң гүзәл җәүһәрләрен туплап, мәктәпләр һәм гимназияләр өчен уку ярдәмлеге сыйфатында китаплар чыгара.

Татар халык афоризмнарына багышланган китапларның беренчесендә алкышлар, каргышлар, антлар, әзер җаваплар, юрау-ышанулар, сынамышлар, табышмакларның иң яхшы үрнәкләре урын алды.

**Б3—8(67)—109—2001/2002**

Учебное издание

**НАРОДНЫЕ ЖЕМЧУЖИНЫ**

Афористические жанры

КНИГА ПЕРВАЯ

*(на татарском языке)*

Составитель

**Махмутов Хузиахмет Шагиахметович**

Редакторы *Л. Г. Шәрифуллина*
Техник редакторы *Л. И. Фокейчева, Ә. С. Трофимова*
Корректоры *А. А. Халитова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.03.2002.
Форматы 60ә90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 9,0 + форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 8,02 + форз. 0,39.
Тиражы 4 000 д. Заказ Б-32.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
E-mail: magarif@mail.ru
Http://magarif.kazan.ru/

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.